Гашләһәм мәктәп

МӘГАРИФ education

МӘКТӘП БӘЙРӘМНӘРЕ ҖЫЕНТЫГЫ



БӘЙРӘМ ЖЫЕНТЫГЫ

Проектның җитәкчесе һәм фәнни редакторы социология фәннәре кандидаты	**Сөмбел Нурислам кызы Таишева**
Төзүчеләре:	**Алсу Җиһаншина, Сиринә Мөхәммәтҗанова, Илсөяр Газизова, Рифат Каюмов.**
Корректор:	**Ландыш Нәсыйхова**
Дизайн-верстка:	**Илдар Гатауллин**
Руководитель и науный редактор проекта кандидат социологических наук:	**Сюмбель Нурисламовна Таишева**
Составители:	**Алсу Зиганшина, Сирина Мухаметзанова, Ильсияр Газизова, Рифат Каюмов.**
Корректор:	**Ландыш Насыйхова**

I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

«ХӘРЕФСТАН»Г

Гөлнара ӘСХӘДУЛЛИНА,
Арча районы Казанбаш төп мәктәбенең югары квалификация категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы

Бәйрәм барышы

(«Өйрәтәләр мәктәпләрдә» җыры яңгырый.)

Укытучы. Кадерле укучылар! Сезне мәктәп дигән белем йортындагы беренче җиңүегез – «Әлифба»ны өйрәнеп чыгуыгыз белән чын күңелдән котлыйм. Хәрефләр белән танышу, алардан иҗекләр, сүзләр төзү җиңел булмады. Әмма сез тырышып белем алдыгыз: укырга, язарга өйрәндегез. Әлифба сезне дус, тату булырга, укучылар өчен кагыйдәләрне үтәргә өйрәтте.

Хөрмәтле әти-әниләр! Балаларның «Әлифба»ны яхшы үзләштерүендә сезнең дә өлешегез бик зур! Хәзер балаларыгыз чын мәгънәсендә укучылар булды. Бүген без сезнең белән «Хәрефстан» дигән илгә сәяхәткә чыгарбыз. Анда сезгә инде таныш булган 39 бертуган хәреф яши. Алар барысы да матур, акыллы һәм бик эшчән.

Без поездга утырасы станциянең исеме әлегә билгеле түгел. Аны белмичә кузгалып китә алмыйбыз. Ләкин борчылмагыз, табышмакның җавабын әйтә алсагыз, станциянең исеме шул булыр.

Аз да түгел, күп тә түгел –
Утыз тугыз төп-төгәл.
Тәртип белән тезегез,
Рәттән әйтеп бирегез.
Аны белә һәр бала,
Ул рәт ни дип атала? *(Алфавит.)*

– Станциядә безне поезд көтә. Вагонга кереп утыру өчен билетларыбыз да бар. Ә алар чын булсын өчен хәрефләрдән сүз төзергә кирәк.

(Һәр билетка хәрефләр язылган: кәмпәт (мәктәп), фәтдрә (дәфтәр), тпаик (китап). Укучылар билет ала. Кем сүзне укып күрсәтә, шул урынына кереп утыра. Урындыклар «поезд» итеп тезелгән.)

Укытучы. Менә хәзер юлга кузгала алабыз.

Беренче тукталыш – «Таныш булыйк» станциясе.

– Безнең 1 нче сыйныфта 13 бала. Хәзер балалар мин укыган шигырь юллары аша үзләрен танырга тиеш. Таный алмаганнарга әти-әниләр булышса да ярый.

1 нче укучы.
Сыйныфта иң кечкенәсе мин,
Шуңа бар бер теләгем:
Куып җитәрмен сезне дә,
Көтегез, иптәшләрем.

2 нче укучы.
Мин гаиләдә кече малай,
Булышам бөтен эштә.
Бик тырышам мәктәптә дә,
Укыймын бөтен көчкә.

3 нче укучы.
Мин – тырыш кыз,
Барысына да өлгерәм:
Җырлыйм, биим, дәресемне
Бик оста сөйләп бирәм.
Апаларымнан калышмыйм,
Тырышам бар көчемә.
«Тәртипле бул, күпне бел» – ди,
Максат куйдым үземә.

4 нче укучы.
Исемем матур минем,
Йөземдә балкый кояш.
Сөйләшергә яратам,
Барын үземә каратам.

5 нче укучы.
Русча дөрес, матур сөйлим,
Яратам исәпләргә,

ГА СӘЯХӘТ

Матур-матур сүзләр тезеп,
Әкиятләр сөйләргә.
6 нчы укучы.
Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле яхшы тел.
7 нче укучы.
Китаплар да бар минем,
Машинам да бар минем.
Сезнең белән сөйләшергә
Вакытларым тар минем.
8 нче укучы.
Мин гаиләдә олы кыз,
Булышам бөтен эштә.
Энемне карау да
Әле бит минем өстә.
Бик тырышам мәктәптә дә,
Җавап бирәм дәрестә.
9 нчы укучы.
Ике абыем да минем
Үсте инде, зур хәзер.
Апам, әти-әнигә
Булышырга мин әзер.
Исемем дә бик матур,
Йөземдә балкый гел нур.
Иркәләнергә яратам,
Барын үземә каратам.
10 нчы укучы.
Гаиләдә мин бер генә,
Булышам бөтен эштә.
Бик тырышам мәктәптә дә,
Укыймын бөтен көчкә.
Барлык хәрефне беләм,
Алардан сүзләр тезәм.
Тукталып уйлап куям,
Бик шәп өйрәндем диям.
11 нче укучы.
Сеңлем өчен иң кадерле
Апа булам – беләмсез,
Бар әтием,әнием,
Бәхетле мин, сизәмсез?
Бердә генә укысам да,
Әниемә булышам,
Әти эштән кайткан җиргә
Аш пешсен дип тырышам.
12 нче укучы.
«Әлифба»ны укый-укый
А дан Я га җиткәнмен.
Каләм чәйнәлеп беткән,
Онытылып киткәнмен.
Мин бик уңган – мактанмыйм,
Савыт юам, идән себерәм.
Кирәк икән, һич иренмим,
Әни, апам белән бергә
Пилмән дә бөгеп куям.
13 нче укучы.
Гаиләмдә алты кеше,
Бишенчесе – мин булам.
Бәби карыйм, йорт җыям,
Һәр эшне дә булдырам.
Менә шундый тырыш кыз мин,
Барысына өлгерәм.
Җырлыйм, биим, дәресне дә
Бик оста сөйләп бирәм.
(Экранда укучыларның фотосурәтләре күрсәтелә.)
Бергә.
Әгәр ничәү дисәгез?
Без класста унөч бөртек.
Аерылмас дус булып,
Тату булып беректек.

Икенче тукталыш – «Тапкырлык» станциясе

Балалар өчен табышмаклар

1) Утыра бер ак чүлмәк –
Өстенә кигән йөз күлмәк. (*Кәбестә*)
2) Бернәрсә тегә белми,
Энәләр тагып йөри. *(Керпе)*
3) Җәен соры, кышын ак,
Кылый күз, озын колак. *(Куян)*
4) Үскәндә яфрагын ашыйлар,
Үсеп җиткәч үзен ашыйлар. *(Суган)*
5) Үзе ул бал ярата,
Кыш буе йоклап ята. (*Аю)*
6) Тышы яшел, эче кызыл,
Көньяк тарафта үсә.
Бигрәк баллы, бигрәк сусыл!
Кайсыгыз аны белә? (*Карбыз)*

Укытучы. Балаларыбызны сынадык. Хәзер инде тапкырлык күрсәтүдә әниләр чираты. (Әниләр өчен табышмаклар)

Берсе көнне ярата,
Берсе төнне ярата.
Икесе дә дөньяга
Якты нурлар тарата. *(Ай һәм Кояш)*
Алмаш-тилмәш өч күз яна:
Яшел, сары һәм кызыл.
Урамда исән йөрергә
Булыша ул көнозын. (*Светофор)*
Агач түгел – яфраклы,
Тун түгел – тегелгән. (*Китап)*
Утырабыз урманда,
Ап-ак эшләпә киеп.
Киптерә дә, кыздыра да
Кешеләр безне җыеп. (*Гөмбә)*

Өченче тукталыш – «Хәрефстан иле»

Укытучы. Балалар! Игътибар! Игътибар! Алдыбызда «Хәрефстан иле». Монда безнең «Әлифба» һәм без яратып укыган башка китаплар яши.

(Балалары каршысына «Әлифба» килеп чыга.)

Әлифба. Исәнмесез, балалар! «Хәрефстан иле»нә рәхим итегез! Бу илдә мин сезгә өйрәткән бик шук, бик наян хәрефләр яши. Әгәр алар сезнең гомерлек юлдашыгыз булсын дисәгез, үз һөнәрләрегезне күрсәтегез әле.

Ә хәрефе.
Әтәч бии әрҗәдә, ди.
«Әкәмәт!» – дип көләсезме?
«Әтәч», «Әрҗә» сүзләрендә
Ничә «Ә» бар, беләсезме?

Л хәрефе.
Лимон үскән җылы якта
Бигрәкләр ямьле диләр,
«Л» хәрефен яхшы белсәң,
Лимон да тәмле диләр.

И хәрефе.
Икмәк илдә иң кадерле,
Ипине ипләп кап син.
Икмәк сүзендәге «И»не
Теләгән кеше тапсын!

Ф хәрефе.
Фил китергәннәр циркка,
Йөз кешелек ашый, ди.
Һәр көнне борыны белән
Физзарядка ясый, ди.

Б хәрефе.
Бакалар җырлый буада,
Отып калырга уйлыйм.
«Б» хәрефен яхшы белеп,
«Бишле» алырга телим.

А хәрефе.
Алма бакчасында – алма,
Әтием алма ташый.
«А» хәрефен өйрәнәм мин,
Алмалар ашый-ашый.

(«Әлифба» җыры (Р.Абдуллин көе, Р.Вәлиев сүзләре) башкарыла.)

1 нче укучы.
«Әлифба»да утыз тугыз
Хәрефне без өйрәндек,
Җырлар итеп җырладык та
Шигырь итеп сөйләдек.

2 нче укучы.
Өйрәтте «Әлифба» безне
Табигатьне сөяргә.
Кече дусларыбызга,
Бул син дустым, дияргә.

3 нче укучы.
Малайларны «Әлифба»
Өйрәтте җитез булырга.
Батыр, кыю кешеләрдән
Үрнәк алып торырга.

4 нче укучы.
Сәнгатьле итеп сөйләргә,
Аңлаешлы укырга,
Табышмаклар чишәргә
Өйрәттең син, «Әлифба».

5 нче укучы.
Кызларны ул зур ярдәмче,
Булышчы булсын диде.
Эшләгән һәрбер эшләре
Елмаеп торсын диде.

6 нчы укучы.
Хәреф безгә юлны ачты
Әкиятләр иленә.
Шигырьләр һәм хикәяләр
Өйрәндек без тиз генә.

7 нче укучы.
Курыкмаска салкыннан,
Яңгыр, яшен, карыннан.
Дус булсагыз, яратсагыз,
Файда тияр барыннан.

Өйрәтте чиста булырга,
Пөхтәлекне сакларга,
Усал, ямьсезләрдән безгә
Нәниләрне якларга.

Бергә. Рәхмәт сиңа, «Әлифба»!

Әлифба. Мине зурлавыгыз өчен рәхмәт, балалар. Ярдәм-челәрем-хәрефләрем сезне укырга өйрәтергә бик тырыштылар. Хәрефләрне сезгә тагын нинди китап өйрәтте?

Бергә. Азбука!

1 нче укучы.
«А». Аист с нами прожил лето,
А зимой гостил он где-то.

2 нче укучы.
«З». Звёзды видели мы днём,
За рекою над Кремлём.

3 нче укучы.
«Б». Бегемот разинул рот,
Булки просит бегемот.

4 нче укучы.
«У». Ученик учил уроки
У него в чернилах щёки.

5 нче укучы.
«К». Кот ловил мышей и крыс,
Кролик лист капустный грыз.

Азбука.
Вы прочли «Азбуку» до корки,
Вам по чтению – пятёрка!
Позади нелегкий труд
Слогового чтения…
И теперь без передышки,
Вы прочтите любые книжки…
Так что в путь, дружок! Не робей!
Не грусти! Не жалей,
Что закончил «Азбуку».
Я желаю всем вам
Унестись в эту неведомую даль,
Научиться дружить
И в беде помогать,
И решительными быть.

Укытучы. Укучылар һәм әти-әниләр, «Азбука»ның сезгә бераз сынаулары бар икән. Әйдәгез, шуларны үтәп карыйк.

Составь слова.

Отгадай ребусы.

Математика. Исәнмесез, дуслар. Минем дә сезне сынап карыйсым килә. Без сезнең белән бик күп мисал, мәсьәләләр чиштек. Әйдәгез, кем җитезрәк икән?

Керпе гөмбәгә барды,
9 ак гөмбә тапты.
3 не куйды энәсенә,
Калганын – кәрзиненә.
Керпе ничә гөмбәне
Салды кәрзин төбенә?

***

Айдар китте урманга,
Җир җиләге җыярга.
Тиз генә 10 җиләк тапты
5 не авызга капты.
Ничә калыр чиләктә?
Уйла тизрәк, исәплә.

***

7 малай урамга
Чыкты футбол уйнарга.
Өчәү килде тагын да,
Исәплә син барын да.

***

Ак каенда 3 чыпчык
Түбәдә 5 сыерчык.
Әйтмәс микән берегез:
Барысы ничә кошчык?

Алып баручы. «Әлифба» сезне туган илне сөяргә, туган телне яратырга өйрәтте. Безнең алга таба куллана торган китапларыбыз – «Татар теле» һәм «Әдәби уку».

Туган тел.
Исәнмесез, дусларым!
Мин Туган тел буламын.
Күрәм, «Әлифба»ны өйрәнгәнсез,
Матур итеп сөйлисез.
Туган телне яратсагыз,
Тагы да күп белерсез.
Туган тел – иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип телең йотма,
Туган телне онытма!
Туган тел ул бездән соң
Яшәр өчен туган тел.
Бүгенгедән киләчәккә
Дәшәр өчен туган тел.

Минем дә сезне сынап карыйсым килә, балалар!

1. Аз да түгел, күп тә түгел,
39 төп-төгәл.
Аны белә һәр бала
Ул рәт ни дип атала? (*Алфавит)*

Баш хәрефебез юк безнең
Аваз да белдермибез.
Шуның өчен дә сүзләрдә
Бик парлашып йөрмибез. *(ь, ъ хәрефләре)*

3. Алфавитта 6 хәреф:
Чын дуслар һәм туганнар.
Татар сүзләрендә генә
Кулланыла торганнар. *(Ә, Ү, Ө, Ң, Җ, һ)*

4. Безне татар сүзләреннән
Эзләп таба алмассыз.
Дөрес әйтеп бирсәгез,
Оятка да калмассыз. *(Ц, Щ, В, Ё хәрефләре)*

5. Без бары тик дүртәү генә
Койрык тагып йөрүче.
Нинди хәрефләр икән –
Бармы берәр белүче? *(Ж, Ң, Ц, Щ хәрефләре)*

6.Томау төшкән кешеләр
Хәлебезне аңлыйлар,
Чөнки безне дөрес итеп
Алар әйтә алмыйлар. *(М, Н, Ң хәрефләре)*

Укытучы. Бүген сезне котларга әти-әниләрегез дә килде. Без аларга зур рәхмәт әйтәбез. Чөнки аларның ихлас ярдәме белән сез укырга, язарга өйрәндегез.

Әткәй-әнкәй, газизләрем, Сезгә зур рәхмәтебезне
Гомер биргәнсез безгә. Җиткерәбез һәммәбез,
Тырыш итеп үстерәсез – Олы ярдәмегез өчен
Мең рәхмәтебез сезгә. Башыбызны иябез.

(Балалар әти-әниләргә үз куллары белән әзерләгән бүләкләрне тапшыра. Әти-әниләрнең котлавы.)

Укучылар.
Сезнең алда без
Вәгъдә бирәбез:
Ялкауланмаска,
«2»ле алмаска,
Тырыш булырга,
«5»кә укырга.

I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

ХУШ, ӘЛИФБА

Фәүзия РАМАЗАНОВА,
Арча районы Казанбаш төп мәктәбенең
башлангыч сыйныфлар укытучысы

Бәйрәм барышы

(Зал бәйрәмчә бизәлгән. Күңелле музыка яңгырый. Сәхнә түрендә «Әлифба» китабы рәсеме эленгән һәм «Рәхмәт, сиңа, «Әлифбам!», «Сау бул, «Әлифбам!» дип язылган. Тактага, тәрәзә рамнарына шарлар эленгән, кисмә хәрефләр беркетелгән.)

Укытучы.

Күчкәнме бу залга
Дөньяның бар яме?!
Күңелләр түрендә –
«Әлифба» бәйрәме!
Бу матур бәйрәмгә
Кушыл, дус, әйдәле!
Мәктәпне гөрләтсен
«Әлифба» бәйрәме!

(Җил. Ямьсез тавышлар чыгарып, себеркесенә утырып, артына куллары бәйләнгән балаларны иярткән, Убырлы карчык керә.)

Убырлы. Туктагыз әле, туктагыз! Үзләре бәйрәм итәләр дә бәйрәм итәләр. Ник миңа дәшсеннәр. Миңа чакыру җибәрсәгез, кәгазь бетәр идемени? Менә кызык итәм әле үзегезне. Тылсым белән бәйрәмегезне өзәм дә китәм.

Укытучы. Убырлы карчык, нишләп болай ямьсезләнеп килеп кердең әле? Бездә бүген «Әлифба» бәйрәме. Ә син бәйрәмебезне бозарга йөрисең.

Убырлы. Менә шуңа күрә килдем дә мин. Бу балаларны Шүрәле алып китеп адаштырган. Ярый минем йортыма килеп чыктылар. Карап-карап торам да болардан башка бәйрәмегез барып чыкмас төсле. Тик кулларын чишә алмадым. Табышмакларның җавапларын белсәгез, иптәшләрегезне коткарырсыз.

Авырып киттең исә,
Эзләргә кирәк дәва.
Тәннәрне чыныктыра
Салкын су, кояш, … . *(һава).*

Йокласын ул, еламасын!
Тынычлансын ничек тә.
Шунда салып йоклаталар,
Әй, рәхәт соң … . *(бишектә).*

Тычканнарга тынгы бирми,
Битен дә сусыз юа.
Аның белән уйнасагыз,
Сезгә рәхмәтле була. *(мәче)*

«Аның куллары да йомшак! –
Шулай диде бер нәни.
Мин аны бик тә яратам,
Чөнки ул – минем … !» *(әни)*

5.Теремкәйне кайсы хайван җимерә? *(Аю)*

Укытучы . Рәхмәт сиңа, Убырлы карчык! Без сине бик явыз дип йөри

идек, син мәрхәмәтле дә була беләсең икән. Теләсәң, бәйрәмебездә кал!

Убырлы. Афәрин, балалар, бар табышмакларга да дөрес җавап бирдегез.

Бергә. Сау бул, әбекәй!

(Балалар, Убырлы карчыкны озатып, сәхнәдән чыгып китәләр.)



Укытучы. Кадерле укучыларым, хөрмәтле ата-аналар, укытучылар һәм кунаклар! Без зур бәйрәмгә җыелдык. Бүген бездә «Әлифба» бәйрәме!

1 сентябрь иртәсендә мәктәп бусагасын беренче тапкыр атлап кергән нәни дусларыбыз бүген беренче җиңүләрен бәйрәм итә.

Әйе, хәрефләрне тану, иҗекләр, сүзләр төзү, укырга өйрәнү җиңел булмады. Әмма тырыштыгыз, өйрәндегез. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» диләр. Булдырдыгыз! Хәзер безнең сыйныфтагы һәрбер бала укый, яза, саный белә. Чын күңелдән котлыйм сезне, укучылар! Бүген кабатланмас балачак иленең иң зур бәйрәмнәреннән берсе – «Әлифба» җыены. Җир йөзендә кем генә булмасын, кайда гына эшләмәсен, һәр кеше үзенең нәни кулларына тәүге тапкыр «Әлифба» алган чагын дулкынланып искә төшерә. Чөнки һәркемнең дә белем дөньясына беренче адымы «Әлифба»дан башлана. Бүген 1 нче сыйныф укучылары үзләре яратып укыган беренче дәреслекләре – «Әлифба» белән саубуллаша. Әйдәгез, сүзне аларга бирик.

(Музыка астында балалар, кулга-кул тотынып, җырлап залга керәләр.)

1 нче укучы.
Бүген бездә зур бәйрәм,
Һәммәбез дә шат безнең.
Соңгы битен укыдык
Кичә «Әлифба»бызның!

2 нче укучы.
Без бит хәзер һәммәбез дә
Укый-яза беләбез.
Моның өчен «Әлифба»га:
«Бик зур рәхмәт», – диябез!

3 нче укучы.
«Әлифба»м өйрәтте
Хәрефләр танырга,
Тукталып тормыйча,
Гел алга барырга.

4 нче укучы.
Хәрефләр диңгезе
Чайкалды каршымда.
Хәрефләр бер төсле
Тоелды барысы да.

5 нче укучы.
Аларны танырга
«Әлифба»м булышты.
Шәп укый алырлар
Диеп ул тырышты.

(Белмәмеш керә.)

Белмәмеш*:* Ә мин – Белмәмеш. Исемемә карамагыз, мин сезнең хакта күп беләм. Монда иң зирәк, иң акыллы

балалар җыелган, үзләре укый да, яза да беләләр дип ишеттем. Күп белсәгез, әйтегез әле, «Әлифба»да ничә хәреф бар?

Укытучы. Белмәмеш, син сорауны ачык итеп бир әле, сүз «Әлифба» сүзендәге хәрефләр хакындамы, әллә татар алфавитындагы хәрефләр турындамы?

Белмәмеш *(иңбашларын җыерып)*. Менә инде тагын! Ничә хәреф беләсез дип сорыйм ич мин!

1нче Укучы. «Әлифба»дагы хәрефләрне рәттән беләбез без.

2нче Укучы. Ул алфавит дип атала.

3нче Укучы. Татар алфавитында 39 хәреф бар: сузыклар һәм тартыклар.

Укытучы. Сузыклар – нинди була соң алар?

4нче Укучы.

Сузык булгач ул сузыла, җырлый ул.
Тавышы көр, күпме генә җырласа да, туймый ул.

Укытучы. Ә тартыклар сузыклардан нәрсә белән аерыла, балалар?

Укучы.

Ә тартыклар – тартыналар,
Тартыналар җырларга.
Йомык авыз. Йомык ирен.
Шунда сузылып кара!

Укытучы. Тавышсыз хәрефләр дә килеп җиткән. Рәхим итегез!

(ъ,ь хәрефләрен күкрәкләренә беркеткән 2 укучы тавышсыз гына чыгып баса.)

Укучы. *(ъ билгесе)*

Калындыр минем тавышым,
Катыдыр минем сөйләм.
Күп сөйләмим. Мин, ахрысы,
Батырлар нәселеннән.

Укучы *(ь билгесе)*

Әби әйтә, бик тирән, ди,
Кешенең күңел күзе.
Яхшы сүздән нечкәрә, ди,
Кешеләрнең күңеле.

Укучы. (*ң хәрефе) алар янына чыгып баса.*

Бу хәрефләр баш хәрефсез –
Истә тотыйк шул хакта.
Шуңар аннан башланмый
Бер сүз дә язган чакта.

Укытучы. Әйтегез әле, укучыларны мәктәптә нәрсәгә өйрәтәләр?

Укучылар.

– Укырга.
– Язарга.
– Санарга.
– Тәртипле булырга.
– Җырларга, биергә.
– Дус, тату яшәргә.

Укытучы. Әйтегез әле, укучылар, «Әлифба» сүзе үзе нинди хәрефләрдән төзелгән?

(«Әлифба» сүзендәге хәрефләр булып киенгән укучылар сөйли.)

Ә хәрефе.

«Әни» дип телем ачылган,
Әни сөйгән, назлаган.
Кайсыбыз соң дәфтәренә
Ә хәрефен язмаган.

Л хәрефе

Күзләремнән яшьләр чыкты,
Капкан идем лимонны.
Сары булгач, бик тәмле дип
Белгән идем мин аны.

И хәрефе

И хәрефе ипидә бар,
Бар ул ил һәм иректә.
И хәрефе «икеле»гә
Укымаска өйрәтә.

Ф хәрефе

Фил бүрәнә ташып йөри
Кара урман эчендә.
Һаман тора күз алдымда,
Күрсәм дә тик төшемдә.

Б хәрефе

«Бөрлегәнем, җиләгем», – дип,
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни.

А хәрефе

А хәрефе алмада,
А хәрефе агачта.
А хәрефен яратабыз,
Өйрәнәбез иң башта.

Укучы.

Һәммәсенең – үз урыны
Барысы да кирәкле,
Безне «Әлифба» китабы
Дус булырга өйрәтте.

Укытучы. Укучылар, сез «Әлифба»ны өйрәнүне тәмамладыгыз. Ул сезне бик күп нәрсәгә өйрәтте. Әйдәгез, «Әлифба»ны бәйрәмгә чакырыйк.

Бергә. Кадерле «Әлифба»! Бәйрәмгә рәхим ит!

(Әлифба керә.)

Әлифба. Исәнмесез, дусларым һәм хөрмәтле кунаклар!

Бергә. Исәнме, «Әлифба»!

Укучы

«Әлифба», син алып кердең
Безне Белем иленә.
Ялкаулык та, тырышлык та
Шушы илдә беленә.

Әлифба

Нәни дусларым,
Рәхмәт сезгә дә,
«Әлифба»ны тиз
Үзләштергәнгә.
Белем сараен
Керергә ачып,
Сезнең кулларда
Хәзер бар ачкыч.
Һәрбер укучы
Бик күп укысын!
Китап иң якын
Дустыгыз булсын!

Укытучы. Укучылар, хәзер дустыбыз «Әлифба»га олы рәхмәтебезне җыр белән җиткерик.

(«Хәрефле шакмаклар» җыры. Л.Батыр-Болгари көе, Г. Садә сүзләре башкарыла)

Хат ташучы. Дуслар, телеграмма, сезгә телеграмма бар!

Бергә. Кемнән?

Хат ташучы. «Туган тел»дән. Юлга чыктым, тиздән килеп җитәм дигән.

Укучы.

«Туган тел» ул – иң изге тел,
Шуны белегез!
Ишек ачык, кил, рәхим ит,
«Туган тел»ебез.

(«Туган тел» керә.)

Туган тел.

Исәнмесез, шаяннар,
Минем нәни наяннар,
Уйнап туймый торганнар,
Сикергәләк куяннар,
Сез көткәнне белдем мин.
Ерак-ерак илләрдән
Алып килдем сезгә мин.
Кызык-кызык әкиятләр,
Төрле-төрле хикәяләр,
Матур-матур шигырьләр,
Күңелле, дәртле җырлар.
Килдем мин никадәр
Җыр, шигырь, хикәя,
Мәкальләр күтәреп.
Май айлары беткәнче
Укырга ул җитәрлек.
Тап кына җавабын –
Табышмак ничаклы.
Сиңа бер үтенеч –
Таплама китапны!

Укучы.

Рәхмәт, «Туган тел», сиңа
Бәйрәмгә килгән өчен,
Киңәшләр биргән өчен.
Дуслашырбыз, серләшербез.
Белем алып үтәр безнең
Туачак һәр көнебез.

Әлифба.

Кадерле балалар,
Мин китәм, хушыгыз.
Акыллы булыгыз!
Гел «биш»кә укыгыз!

Бергә.

Рәхмәт сиңа, «Әлифба»!
Сау бул, «Әлифба»!

(Әлифба чыгып китә. «5ле» керә.)

«5ле».

Исәнмесез, саумысез,
Минем нәни дусларым!
Кемнәр авырлыктан качмый,
Кемнәр белем ярата,
Кемнәр тырышып укый,
Дөрес һәм матур яза,
Тәртипле һәм эштә җитез –
Шулар минем дусларым.

Бергә.

Укыгач – укы,
Алгач – «5ле» ал.
Әйдә, «5ле» дус,
Бөтенләй бездә кал.

(«5ле» балалар янында кала. «4ле» керә.)

«4ле».

Мин дә «5ле» белән
Гел янәшә йөрим.
Һәр эшнең яхшы
Булуын телим.

Бергә.

Әйдәгез, «4ле» дус,
Түрдән узыгыз!
Бездән китмәгез!
Бездә торыгыз!

(«4ле» балалар янында кала. «3ле» керә.)

«3»ле.

Мин дә «4» белән
Янәшә торам.
Ләкин «2ле»гә
Карабрак барам.
Әгәр бар көчем
Биреп тырышсам,
Мин дә «4 ле»гә
Тиңләшә алам.

Бергә.

Укучы булгач,
«3ле» алмыйбыз.
Без синең белән
Алга бармыйбыз.

(«3ле» чыгып китә. «2ле» һәм «1ле» керә.)

«2ле» һәм «1ле» бергә.

Без нәрсә әйтик
Сезгә, иптәшләр,
Берни белмибез –
Авыр безнең хәл.
Укыйсы килми,
Язасы килми,
Өй эшләрен дә
Үтисе килми.
Уйнап йөрибез,
Гел эштән качып,
Ә ашаганда
Кирәк зур кашык.

Бергә.

Хәзер үк моннан
Чыгып китегез!
«2»ле, «1ле»гә
Иптәш түгел без!

(«2»ле һәм «1»ле чыгып китә. Кызыл Калфак керә.)

Кызыл Калфак. Укучылар, мине таныйсызмы?

Бергә. Таныйбыз. Син – Кызыл Калфак.

Кызыл Калфак. Әйе, мин – бүредән качкан Кызыл Калфак. «Әлифба»дан сез зирәк, тапкыр булыр- га өйрәндегез. Шуңа күрә, мин сезгә берничә мәсьәлә алып килдем. Алар белән таныштырыйм әле. Сез аларның җавапларын әйтерсез.

Керпе гөмбәгә барды,
9 ак гөмбә тапты.
3 не куйды энәсенә,
Калганын – кәрзиненә.
Керпе ничә гөмбәне
Куйды икән кәрзиненә? (9-3=6)

7 малай урамга
Чыкты футбол уйнарга.
3 әү килде тагын да,
Исәплә син барын да. (7+3=10)

Ак каенда 3 чыпчык,
Түбәдә 5 сыерчык.
Әйтмәс микән берегез,
Барысы ничә кошчык? (3+5=8)

Айдар китте урманга,
Җир җиләге җыярга.
Шунда 10 җиләк тапты,
5 не авызга капты.
Ничә калыр чиләктә?
Уйла, тизрәк исәплә! (10-5=5)

Бергә

Сезнең алда без
Вәгъдә бирәбез!
Ялкауланмаска,
«Ике»ле алмаска,
Тырыш булырга,
«Биш»кә укырга!

Математика. Исәнмесез, нәни дусларым. Сезне иң беренче җиңүегез – «Әлифба»ны уңышлы тәмамлавыгыз белән котлыйм. Менә минем китабымда кызыклы мәсьәләләр бар. Хәзер сезгә шуларны укырмын, сез җавап бирерсез.

Алмагачта 5 алма.
Алар пешкән, алланган.
Берсен алды Әнисә.
Агачта калды ничә? (5-1=4)

Әминәнең тубы икәү,
Сәлимәнең тубы икәү.
Әйт әле син, сабыем,
Ничә туп дип саныем? (2+2=4)

Бер күлмәктә 3 төймә,
Бер күлмәктә 5 төймә.
3 төймә дә, 5 төймә,
Барысы ничә була?
Я, уйлап кара, бала! (3+5=8)



Укытучы. Балалар, «Туган тел» сезгә бик күп хикәя, шигырь, табышмак һәм әкиятләр өйрәтер. Аның белән якыннан дуслашырсыз дип ышанам. Тырыш, акыллы, гыйлемле булып үсегез.

Әйдәгез, балалар, алга таба киттек.

(Күл. Бабай балык тотып утыра.)

Балалар, нинди матур күренеш. Бу күренеш нинди әкиятне хәтерләтә?

(Җаваплары тыңлана.)

Балалар, бабайга якынрак килик әле, аңа ярдәм кирәк түгелме икән?

Укучылар. Исәнме, бабай!

Бабай. Исәнмесез, балалар. Мин күлгә балык тотарга килгән идем. Мондагы балыклар тылсымлы икән. Аларның аркаларына мисаллар язылган. Мин картайдым, күзләрем начар күрә. Шуңа күрә анда язылганнарны укый алмыйм. Сез миңа булышырсызмы икән?

Укучылар. Бик рәхәтләнеп булышабыз, бабакай.

Укучылар балыкларны алып, мисалларны чишеп, бабайның чиләгенә салалар. Алтын балыкны укытучы ала. Анда: ***«Зинһар, мине җибәрегез. Мине җибәрсәгез, класска кайтуыгызга сезгә «Туган тел» китаплары бүләк итәр идем», –*** *диеп язылган.*

Бабай. Рәхмәт сезгә, балалар. Сез миңа никадәр балык тотып бирдегез.

Укучылар. Сау бул, бабакай.

(Залга Шүрәле килеп керә.)

Шүрәле. Ә-ә-ә! Менә кайда икән болар! Мин мең бәлаләргә очрый-очрый аларны урлап йөрим, ә Убырлы минем үземне алдап киткән. У-у, мин аны тотып алсам-мы?! Кытыклап көлдерәм, хәлдән тайдырам! *(Кытыклаган кыяфәт чыгара.)* Кая әле, бармакларым да кычытып тора, сезне дә кытыклап алыйм бераз.

Укытучы. Чү, чү, Шүрәле абзый! Тынычлан инде бераз! Балалар бит сине бик яраталар. Синең турында әкиятләрне дә беләләр алар. Әйдә, болай килешәбез. Хәзер мин сиңа сораулар бирәм, әгәр шул сорауларга җавап бирә алсаң, син – җиңүче. Әгәр җавап бирә алмасаң, тынычлап кына безнең бәйрәмнең дәвамын карап китәсең. Ризамы?

Шүрәле. Риза! Һи, мин белмәгән нәрсә юк бит ул дөньяда. Мин бит урмандагы һәр агачны беләм. Я, бир соравыңны!

Укытучы. Беренче сорау: Билгеле бер тәртиптә тезелгән хәрефләр җыелмасы ничек дип атала?

Шүрәле. Беләм, беләм, күргәнем дә бар. Солдатлар!

Укытучы. Белмәдең шул, Шүрәле! Әйтегез әле, балалар!

Балалар. Алфавит.

Укытучы. Икенче сорау: Ни өчен ъ (калынлык билгесе) һәм ь (нечкәлек билгесе) тавышсыз хәрефләр дип атала?

Шүрәле. Алар кыш көне кар ашаганнар, тамаклары беткән, шуңа күрә тавышлары чыкмый.

Укытучы.Тагын белмәдең, Шүрәле. Балалар, кайсыгыз әйтә?

Укучы. ъ һәм ь билгеләре аваз белдермиләр. Шуңа күрә тавышсыз хәрефләр дип аталалар.

Шүрәле. Җитте, җитте, сез җиңдегез. Бәйрәмегездә калам, әле минем өйрәнәсе әйберләрем бик күп икән!

Укытучы. Балалар, ягез әле, Шүрәле абзагызга һөнәрләрегезне күрсәтегез!

«Лото» уены.

Хәрефләр өстенә балалар шул хәрефтән башланган рәсемнәрне куярга тиеш.

Ә И Б *(Рәсемнәр: агач, фил, әтәч, лимон, ипи)*

Л Ф А (*Балык, китап, сәгать, чана.)*

«Дәвам ит» уены.

(Укытучы сүзнең беренче иҗеген әйтә, укучылар сүзне дәвам итә. Мәсәлән: пар(та), өс(тәл), мәк(тәп), ки(тап), так(та), руч(ка), күл(мәк), көз(ге), ал(ма), биш(ле).)

Әти-әниләр һәм балалар белән уйнау өчен уеннар.

1. Начар укучыга эләккән китап һәм дәфтәр исеменнән сөйләргә.

2. Мәсәл яки әкиятләрне сәхнәләштерү. Мәсәлән,«Торна белән Төлке», «Төлке белән каз».

3. Сүзләрне аңлату.

4. «Әлифба» битләрендәге берәр шигырьне сөйләү.

5. Кисмә хәрефләрдән сүзләр төзергә *(Әти-әниләргә катлаулырак, ә балаларга гадирәк сүз бирелә, сүз әйтелми.)*

6. Укучылар өчен бирем: текстлар укыла, нинди хәреф битендә бу текстны укыганны әйтергә.

7. «Шигырьне дәвам ит!» уены. «Әлифба» битләрендәге шигырьләрдән өзек укыла, уенда катнашучылар аны дәвам итә.

8. «Сүзләрдән җөмлә төзү». Сүзләр язылган карточкалар таратыла. Уенда катнашучылар шул карточкаларны тотып, җөмлә барлыкка килерлек итеп тезелеп басалар.

9. «Мәсәл яки әкиятләрне сәхнәләштерү». Моның өчен кирәк-яраклар салынган тартмалар бирелә. Бу әйберләрнең кайсы әкият өчен кирәк икәнен әйтергә һәм өзеген уйнап күрсәтергә.

Укытучы. Менә, балалар, «Әлифба»ны тәмамлауга багышланган бәйрәмәбез ахырга якынлашты. Анда катнашкан һәм активлык күрсәткән өчен барыгызга да рәхмәт. Ә сезгә, ата-аналар, шулай ук рәхмәтемне белдерәм һәм киләчәктә дә белем үрләренә балаларыбыз белән бергә күтәрелербез дигән теләктә калам.

I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

САУ БУЛ, 1 НЧЕ СЫЙНЫФ!

АЛСУ РӘХМӘТУЛЛИНА,
Арча районы Мөндеш башлангыч мәктәбе укытучысы

Бәйрәм барышы

Укытучы.
Нинди матур бүген көн!
Йөгереп урамга чыктык.
Күңелле уйлар белән
Без мәктәпкә ашыктык.

Ямьле май иртәсен күреп,
Күңелләр канатланды.
Бүген бездә бәйрәм, дуслар,
Укулар тәмамланды.

Олы бәйрәм бүген бездә,
Зурлар инде үзебез.
Укый-язарга өйрәндек –
Белем ияләре без.

Әйе, бездә бүген зур бәйрәм. Бүген без 1 нче сыйныфта укучыларыбызны укырга, язарга, санарга өйрәткән «Әлифба», «Азбука», «Математика» дәреслекләре белән хушлашабыз.

(«Әлифба» җыры (Р.Абдуллин көе, Р.Вәлиев сүзләре) башкарыла.)

1 нче укучы.
«Әлифба»быз тәмам булды,
Без җыелдык бәйрәмгә.
Шатлыгыбыз эчкә сыймый,
Ничек сезгә сөйләргә?!

2 нче укучы.
«Әлифба», «Әлифба»,
Беренче битеңне
Ачкан көн хәтердә
Зур бәйрәм шикелле.

3 нче укучы.
Иң якын дустыбыз
Булдың син гел безнең.
Һәр хәреф елмаеп,
Әйтте үз исемен.

4 нче укучы.
Һәм алар бик матур
Сүзләргә әйләнде.
Сүз төзеп укуы
Кызыклы, күңелле.

Укытучы.
Кем кайсы хәрефне
Бигрәк ошатты?
Я, әйтеп бирегез,
Ачмыйча китапны.

7 нче укучы.
А тора «Әлифба»ның
Иң мактаулы җирендә.
Ансыз әйтеп булмый
«Ата-ана» сүзен дә.

8 нче укучы.
Уңган бул, улым, дип
Әйткәнне хәтерлә.
У кирәк һәрвакыт
Дус сүзен әйтергә.

Укытучы.
Инде без беләбез:
Һәр хәреф кирәкле.
Барысы да урынлы,
Барысы да кирәкле.
Безне «Әлифба» китабы
Дус яшәргә өйрәтте.

Без татар теленең 39 хәрефе белән таныштык. Хәрефләрдән – иҗекләр, иҗекләрдән – сүзләр, сүзләрдән – җөмләләр төзергә, хикәяләр укырга, сөйләргә өйрәдек.

(«Алфавит» җыры (В. Агапов) башкарыла.)

Укытучы. Без математика дәресләрендә санарга, кушарга, алырга, мәсьәләләр чишәргә өйрәндек. Хәзер математик табышмакларның җавапларын әйтербез.

1) Өстәлдә 7 шәм янып тора. 3 се

сүнде. Ничә шәм калды? (**7**)

2) Әтәч 3 йомырка салган. Берничә көннән тагын икене салган. Ул барлыгы ничә йомырка салган? (0)

3) Күктән 3 тавык очып бара. Аннан тагын 3 очты. Барысы ничә тавык очып китте. (0)

4) 8 үрдәк йөзә иде. Аучы мылтыктан атты. Күлдә ничә үрдәк калды?(0)

5) Каен агачында 7 алма бар иде. Саескан икесен алып китте. Ничә алма калды? (0)

6) Нинди фигураның башы да, ахыры да юк? (түгәрәк)

7) Бу гаҗәеп фигура, төнлә күкне яктырта. (йолдыз)

8) Атнаның 6 нчы көнен атагыз. (шимбә)

9) 1 дециметрда ничә сантиметр? (10)

Укытучы. Дәрес вакытында, укып аргач, без бераз ял итәбез. Хәзер сезгә дә шул күнегүләрнең берничәсен күрсәтербез.

Без яздык, яздык, яздык.
Безнең бармаклар арды.
Без бераз ял итәбез.
Аннан язып китәбез.
Җил чыкты, яңгыр яуды.
Кояш батты, төн җитте.
Торыгыз, торыгыз,
Нинди матур көн туды.

1 нче укучы.

Как хорошо уметь читать!
Не надо к маме приставать.
Не надо бабушку трясти:
«Прочти, пожалуйста! Прочти!»

2 нче укучы.

Не надо умолять сестрицу:
«Ну, почитай ещё страницу!»
Не надо звать, не надо ждать,
А можно взять и почитать.

Укытучы. Ягез әле, **«**Котёночка**»** дигән сүздән яңа сүзләр төзик. Кайсы командаңыкы күбрәк булыр икән?! (кот, он, ток, окно, оно, точка, ночка, очко, конёк)

3 нче укучы.

Татарча да яхшы бел, урысча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен иң кирәкле, затлы тел.

(«Пусть всегда будет солнце» җыры (А.Островский көе, Л.Ошанин сүзләре) башкарыла.)

Укытучы. Без, әле 1 нче сыйныфта гына укысак та, бәйгеләрдә дә катнаштык. Укучыларыбыз бик күп мактау кәгазьләренә лаек булды.

Сез хәзер бәби түгел,
Сез хәзер укучылар.
Дәрестә дә, өйдә дә
Зур хезмәт куючылар.

Карандашың, каләмең,
Матур портфелең дә бар.
«Әлифба», дәфтәр, пенал –
Бар да тәртиптә алар.

Алар безгә булыша,
Шуңа күрә карышма,
Биргән бар белемне ал,
Хәтер капчыгыңа сал.

1 нче укучы.

Тактага акбур белән дәрестә без язабыз.

Ә коймага язуны тәртипсезлек саныйбыз.

2 нче укучы.

Каләм тотарга өйрәндек, тырышабыз бозмаска,

Укытучы апа әйтә: «Дәфтәрне пычратмаска!»

3 нче укучы.

Укучы булгач, кирәк аңларга –
Укытучыны тиеш тыңларга.

Укытучы. Балалар, әйдәгез әле бергәләп Дуслык чәчәген ясыйк.

Дустыңның исемен әйтәсең дә аңа хас булган сыйфатны чәчәккә беркетәсең. Безнең сыйныфыбыз нинди икән?

… – зирәк
… – кайгыртучан
… – сабыр
… – акыллы
… – ихлас
… – сөйкемле
… – игелекле
… – тырыш
… – ягымлы
… – тыйнак

Менә нинди матур чәчәк килеп чыкты. Бу чәчәк тәҗларына язылган сыйфатлар үзебезгә туры килеп тора. Гел шундый акыллы, кайгыртучан, тыйнак булып үсеп җитегез. (*Чәчәк класс тактасына беркетелә.)*



I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

1 ИЮНЬ – БАЛАЛАРНЫ ЯКЛАУ КӨНЕ

(Башлангыч сыйныфларда дәрестән тыш чара)

Люция ЮНЫСОВА,
Буа районы Алших урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы

Бәйрәм барышы
Һәрвакыт булсын кояш!
Һәрвакыт булсын һава! (*Җыр яңгырый.)*

Укытучы. Дусларым! Без бүген Балаларны яклау көненә багышланган бәйрәмгә җыелдык. Барыгызны да шушы бәйрәм белән котлыйм. Җәйнең беренче көне – балачак иленең иң матур бәйрәме. Сез ел дәвамында төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда, спорт ярышларында, иҗади бәйгеләрдә көчегезне сыныйсыз, ә без мактаулы урын алган укучыларыбыз белән горурланабыз. Әйдәгез, саусәламәт яшик, белем алыйк, иҗат һәм спорт белән шөгыльләник.

Бүгенге бәйрәмебез ике өлештән тора. Беренче өлештә без иҗат итәрбез, ә икенче өлештә көчебезне уеннарда сынарбыз. Плакатларга игътибар итегез. Монда биремнәр тәртибе аңлатылган.

Беренче өлеш.

«Спорт утраучыгы» рәсем ясау бәйгесе.

(Спортка бәйле музыка яңгырый. Һәр балага альбом битләре, төсле карандашлар таратыла. Балалар үзләренең яраткан спорт уеннарын ясап күрсәтәләр. Иң яхшы рәсем ясаган һәм әлеге спорт төре турында матур итеп сөйләгән укучы җиңүче була.)

«Әхлакый мәсьәләләр чишү» уены.

(Шул ук төркемнәрдәге балаларга конверттта төрле ситуациягә караган сораулар бирелә. Аларны чишәргә 5 минут вакыт билгеләнә. Төркемдәгеләр әхлакый мәсьәләләр турында фикер алышалар.

Якынча шундый ситуацияләр булырга мөмкин:

- *дустың начар сүзләр һәм җөмләләр әйтә;*
- *дустың волейбол уйный белми, һәм төркемегез яңадан җиңелә;*
- *дустың сиңа начар эш эшләргә куша.)*

фото: http://superiorpaving.ca/wp-content/uploads/2016/03/bigstock-Kid-Boy-Having-Fun-With-Colorf-97405612.jpg

«Дуслык кагыйдәләре» уены.

(Һәр төркем үзенең дуслык кагыйдәсен төзи. Балалар төсле акбурлар ярдәмендә асфальтта рәсем ясый. Нәтиҗә чыгарыла.)

Икенче өлеш.

Укытучы.

Саулыгың бит үз кулыңда,
Чыгарма тик исеңнән.
Һәрчак хәрәкәттә булып
Яшә, эшлә бүгеннән.
Әле менә рәхәтләнеп
Туп тибәбез аланда.
Кемдер җиңә, кем җиңелә,
Үпкәләү юк алай да.
Сөенеп көтеп алабыз
Һәрчак физкультураны
Ныгытабыз сөякләрне,
Һәм мускулатураны. (*«Хәрәкәттә – бәрәкәт».)*

(Балалар ике төркемгә бүленеп, төрле әкият геройлары булып киенә.)

1) **«Аяклар – бәйдә, йөгерик, әйдә» уены.**

(Балалар парлашып баса. Берсенең уң аягы икенчесенең сул аягы белән бәйләнә. Аяклары бәйләнгән килеш ике пар билгеләнгән урынга кадәр йөгерергә һәм кире килергә тиеш. Бу уен барышында һәр баланың башында Буратино башлыгы була. Беренче килгән пар җиңүче дип билгеләнә.)

2) «Сукыр килеш тупка тип» уены.

(Тупны тирән булмаган чокырлырак җиргә куялар. Туптан өч адым чамасы ераклыкта сызык сызыла. Уйнаучы туп янына килә дә аңа арты белән баса. Аннан соң ул ничә адым үткәнен санап, сызык артына кадәр килә. Шуннан соң уйнаучының күзен бәйлиләр, йөз белән борылып туп янына килергә һәм тупка аяк белән тибәргә кушалар. Бу уенда һәр бала башына Белмәмеш башлыгын кия. Һәр төркемнең балларын санап, җиңүче төркемне ачыклыйлар.)

3) «Армрестлинг – акыл көрәше» уены.

(Һәр төркемнән берәр бала, кара-каршы утырып, кул көчендә сынаша. Бу уенда һәр баланың муенында – Леопольд банты. Һәр төркемгә баллар куела, ахырдан алар санала, һәм җиңүче төркем ачыклана.)

4) «Чаңгычылар» уены.

(Балаларга чаңгы таяклары бирелә. Һәр төркемнән берәр бала билгеләнгән җиргә кадәр чаңгы таяклары белән шуып-чабып барырга һәм, борылып, шул ук тәртиптә кире килергә тиеш була. Бу уенда һәр бала Тычкан колакларын киеп йөгерә.)

5) «Чирәмдә хоккей» уены.

(Балаларга хоккей кәшәкәләре бирелә. Һәр төркемнән берәр бала билгеләнгән җиргә кадәр кечкенә тупны кәшәкәләр белән куып бара һәм, борылып, шул ук тәртиптә кире килергә тиеш була. Бу уенда һәр баланың аркасында – Карлсон пропеллеры.)

Укытучы. Балалар, бәйрәмебез бик күңелле үтте. Килешәсезме? Нәтиҗәләрне дә тыңлап үтик әле. Барыгызны да тагын бер кат бәйрәм белән котлыйбыз!

(Соңыннан укучылар өчен татарча бию буенча флешмоб оештырыла.)

I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

БАТЫРЛЫК ЮЛЫ КАЙДАН БАШЛАНА?

(Урта сыйныфларда Җиңү бәйрәме алдыннан үткәрелә торган кичә)

Гүзәл САДИКОВА,
Балтач районы Норма гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучысы

Кичә барышы

Укытучы. Исәнмесез, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар! Бүгенге кичәбезнең темасын билгеләү өчен һәммәбезгә таныш бер шигырьдән өзек китерик.

«Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып,
Исмең калсын үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык».

(*Укучыларның җаваплары тыңланыла. Дүрт бала залга «Батыр – яуда, чәчән дауда беленер», «Батыр ярасыз булмас, ярасы дәвасыз булмас» дигән плакатлар алып кереп эләә.)*

Бөек шагыйребез Муса Җәлил башын палач балтасы салыр алдыннан язып калдырган әлеге шигырь юллары бүгенге кичәбезнең асылын билгели. Җәлил күтәргән темаңы дәвам итеп, без бүген батырлык-каһарманлык турында уртага салып сөйләшербез. Безнең арада да батырлык кылырга, үз иле, теле, халкы өчен җанын бирергә әзер торучылар күбрәк булсын өчен, сезне чын күңелдән фикер алышырга чакырам.

Укучылар әйтегез әле, батыр, батырлык сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Кемнәрне батыр дип атап була?

(Җаваплар тыңланыла.)

Ә менә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә батыр сүзенең мәгънәсе болай дип бирелгән:

1. Батыр – курыкмаучанлык, кыюлык, көчлелек, уңганлык сыйфатлары белән танылган шәхес.

2. Көрәштә барлык башка көрәшчеләрне җиңеп чыккан кеше.

Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, тыныч көннәрдә батырлык эшләп буламы?

(Балалар җавап бирә. Мисаллар китерелә.)

Әйе, тыныч көннәрдә дә үзләренең батырлыклары белән дөньяны сокландырган кешеләр бар. Мәсәлән, спортта җиңгән батырлар, хезмәт батырлары. Әйтик, 1961 елның 12 апрелендә Юрий Гагарин дөньяда беренче булып галәм киңлегенә чыкты. Галәмгә – энҗеләрдәй балкыган йолдызларга таба юл алды. Юрий Гагарин сезнең кебек үк гади бер малай булган, мәктәптә белем алган, спорт белән шөгыльләнгән, йолдызларга карап очарга хыялланган. Һәм менә ул көн килгән. Исән калу-калмавын белмәгән килеш билгесезлеккә ташланган батырның исеме ул чакта да, хәзер дә җир шарының барлык телләрендә яңгырый. Гагарин үзе исән булмаса да, галәм батырының исеме тарихка кереп калды. Укучылар аңа бервакыт: «Үзеңдә ихтыяр көчен ничек тәрбияләргә була?» – дип сорау биргәннәр. Ә ул: «Ихтыяр көченме? Сиңа нидер эшләргә кирәк, ә син теләмисең. Ул яхшы эшкә үзеңне мәҗбүр ит. Ихтыяр көче үзүзең белән идарә итә белү, кыланышларыңны контрольдә тоту һәм теләсә нинди кыенлыкларны да җиңәргә сәләтле булу дигән сүз бит ул...» – дип җавап кайтарган (Ю. Гагарин «Есть пламя»).

Ә сез ихтыяр көчен ничек тәрбиялисез? Бу хакта уйланганыгыз бармы? *(Җаваплар тыңлана.)*

Укучылар, хәтта үзләренең яшәүләре белән батырлык үрнәге күрсәткән шәхесләр байтак. Сез аларны яхшы беләсез, мәсәлән, Алексей Маресьев, фашист тоткынлыгыннан самолет алып качкан Михаил Девятаев, сөргендә дә рухы сынмаган шагыйрь Хәсән Туфан һ.б. Шушы шәхесләрнең кайсылары турында сөйләргә телисез?

Укучы. Бөек Ватан сугышы елларында очучы Алексей Маресьев, самолетына ут капкач, парашюттан карлы урманга сикерә. Аягына баса алмагач, шуышып, өстерәлеп бара-бара фронт сызыгын үтә. Аны партизаннар табып алганда, аяклары инде өшегән була. Чери башлаган аякларны кискәч тә очу хыялы егетнең күңелен җилкетеп тора. Маресьев протезлар белән биергә, хәтта самолет белән идарә итәргә өйрәнә һәм кабат һавага күтәрелә.

Укытучы. Инде тыныч көннәргә кайтыйк. Язмышларга буйсынмас шагыйрь Фәнис Яруллин турында ишеткәнегез, аның шигырь, хикәя, әкиятләрен укыганыгыз бардыр. *(Китапларын күрсәтә. Бер укучы «Туган ягы кирәк кешегә» шигырен укый.)*

Укытучы. Сез язучы Фәнис Яруллин турында ниләр беләсез?

1нче укучы.

1957 елда армия сафларына алынган егет анда җиңел атлетика белән ныклап шөгыльләнә башлый. Турникта күпләр булдыра алмаган «кояшны» ул гына ясый һәм шушы күнегүне ясаганда, куллары ычкынып китеп, «упкын»га оча. Еллар буена сузылган хастаханә, операция бүлмәләре, йокысыз төннәр. Ләкин канаты сынган бөркет төшенкелеккә бирелми, читтән торып урта мәктәптә белем ала. Балачактан килгән сәләтен үстереп, шигырь, хикәя, әкиятләр иҗат итә. Гел ятып, утырып кына торган хәлдә Казан дәүләт университетын тәмамлый. Аның сүзләренә язылган «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» җыры укытучыларына чиксез ихтирамын чагылдыра. *(Җыр башкарыла.)*

2нче укучы.

Ә менә шагыйрь һәм рәсемнәр остасы Гакыйль Сәгыйтовның хәтта куллары да йөрми. Ул гомере буе урын өстендә була. Ә шигырь һәм рәсемнәрне каләмен аяк бармакларына кыстырып ясый.

Укытучы. Укучылар, бәлки безнең тирә-ягыбызда да, физик газапларын җиңеп, һәр туган таңга сөенеп, иҗат итүчеләр, спортта, хезмәттә җиңү яулаучылар бардыр? *(Балаларның җаваплары тыңлана.)*

Укучылар, батырлыкның яше бармы? Балалар эшләгән батырлыклар турында нинди мисаллар беләсез?

1нче укучы.

Моннан күп еллар элек Мөслим районы авылларының берсендә мондый хәл була. Ике кыз бала болында уйнап йөргән чакта, шуларның берсе өзелеп төшкән электр чыбыгына абынып егыла, ә иптәше чыбыкны үзенә тартып ала. Шулай иптәшен үлемнән йолып кала, ә үзе мәңгелеккә күзләрен йома.

2нче укучы.

Бервакыт телевизордан 1 нче сыйныфта укучы нәни кыз баланы күрсәттеләр. Ул 3 сыйныфта укучы авылдашын судан ярга тартып чыгара, йөгереп өенә кайтып әнисен алып килә, бергәләп аңа беренче ярдәм күрсәтәләр, чанада тартып өйләренә алып кайталар. Кызга «Суга батучыны коткарган өчен» медале бирелә. Телевизор да янгында калган балалар һәм картларны коткаручылар, бәкегә, суга батучыларны өстерәп чыгаручылар турында хәбәрләр биреп тора. *(Үз тирәлекләреннән мисаллар китерелә.)*

Укытучы.

Инде мин дә бер мисал китерим, Америка белән Россия бер-берсенә каршы яшерен көрәш алып барган елларда бу илнең Манчестр шәһәрендә яшәүче Саманта Смит атлы 10 яшьлек кыз Мәскәүгә – коммунистлар партиясенең генераль секретарена хат яза.

(Бер укучы – әлеге хатны, икенче укучы Юрий Андроповның җавап хатын укый.)

Укытучы.

Саманта Мәскәүгә килә. Ленинград каласында, Артекта була. Музейда Таня Савичева исемле кызның Ленинград блокадасы вакытында бөтен гаилә әгъзаларының берәм-берәм ачлыктан үлүе турында язып барган көндәлекләре белән таныша. Американың бу кызы чын батыр. Ул үз халкының тыныч тормышта яшәве өчен көрәшә, ватандашларының атом сугышы корбаннары булуын теләми, ике илнең сугышларсыз дус яшәвен хуплый. Тик котырынып коралланудан күп акчалар эшләүче капиталистлар, үз иленә кайткач, Саманта гаиләсе утырган самолетны шартлату чарасын күрәләр. Саманта мисалы ул, балалар, безнең көннәр өчен дә мөһимлеген югалтмаган. Бүген дә сугыш карчыгасы күп илләр өстендә канат кага. Якын Көнчыгышта, гарәп илләрендә йөзләрчә балалар сугыш корбаннарын әйләнде.

(Укучылар М. Хөсәеннең «Иминлек карлыгачы» поэмасыннан үзәкләр укый.)

Самантаның язмышы да
Көрәш язмышы – ачы...
Күктә янды,
Күктә калды
Иминлек карлыгачы.

Укытучы.

Укучылар, мисаллардан күренгәнчә, батырлыкны олылар да, кечеләр дә эшли ала. Тыныч тормышта да батырлык өчен җай еш чыга.

Укучы:

Хәтердән уела күп нәрсә,
Онытыла иң гүзәл яз, кышлар.
Онытылмый үзенең иңендә
Ил данын күтәргән язмышлар.
Вакытлар үтүгә сүрелеп,
Сүнәләр иң якты балкышлар.
Сүнмиләр, яктылык сибәләр
Көрәштә кабынган язмышлар.
(Талгын гына көй ишетелә.)

Укытучы.

Илебез тарихында иң караңгы сәхифәләрнең берсе – Бөек Ватан сугышы. Миллионлаган солдатлар батырларча башын салган бу афәтнең сабагы, гасырлардан гасырларга күчеп хәтерләрдә мәңге саклансын дисәк, бездән бүген дә уяулык сорала. Ни өчен дигән сорауга җавапны Данис Гәрәйнең «Солдат кулындагы сабый» хикәясен тыңлагач табарсыз, бәлки.

(Бер укучы хикәяне укый.)

Укытучы.

Сугыш илебезгә күпме кайгы-хәсрәт, күпме күз яше китереп, сабыйларны ятим калдырды, бәхеттән мәхрүм итте. Сугыш утлары тынуга күп еллар үтсә дә, балачакларын усал аждаһа йоткан сабыйлар күңеле картлыкка кергәч тә туктаусыз сыкрап тора. Ватанга булган мәхәббәт, тыныч, бәхетле киләчәккә

ышаныч барысыннан көчле булып, Бөек Җиңүгә китерде. Бу бәхетле көннәрне якынайту өчен фронтта да, тылда да өлкәннәр янәшәсендә балалар булды.

Сугышта батырларча һәлак булган герой пионерларның берничәсе белән танышып китик. (слайд)

(Укучылар балаларның батырлыклары турында сөйли.)

Укытучы. Язучылар, шагыйрьләр, җырчылар, композиторлар сугышның беренче көннәреннән үк каләмне мылтыкка алыштырды. Аларның бик күпләре безгә таныш. Боларның яу кырында иҗат ителгән әсәрләреннән сугыш кайтавазы яңгырый. Берничәсенең исемнәрен искә төшерик әле.

(Укучыларны тыңлау.)

Укытучы. Яу кырында мәңгегә ятып калганнарны бер минут тынлык белән искә алыйк. (*Бөтен кеше торып баса.)*

Укытучы. «Үткәнен онытканның киләчәге юк» ди халык. Чынлап та, фронт сызыгы бездән ераста булса да, авылдагы һәр йортта аның кара шәүләсе йөргән. Кемнең әтисе, туганнары яу кырында ятып калган, кемнең якыннары үз авылларында ачлыктан, салкыннан, көч җитмәстән авыр эштән вакытсыз бакыйлыкка күчкән.

Сезнең әби-бабайларыгыз яки башка өлкән туганнарыгыз сугыш фаҗигаләрен ничек хәтерли икән? Алып килгән истәлекләрегез белән безне дә таныштырсагыз иде. *(Укучылар алдан бирелгән сораулар буенча сөйли. Сугыш чорыннан калган әйберләр – хатлар, медаль-орденнар, повестка, похоронка һәм башкалар күрсәтелә. Кәлҗемә, алабута коймагы, чабата күрсәтергә була.)*

Укытучы. Барыбыз да илебезнең күк йөзе һәрчак аяз булсын, илебездә сугыш җилләре беркайчан исмәсен, көннәребез тыныч булсын дигән теләктә яшибез. *(Галия Гайнетдинованың «Кеше булыйм дисәң» шигыре).*

Укучы.
Кыл яхшылык кешеләргә,
Кеше булыйм дисәң.
Авыр булыр, өсләреңә
Гөнаһ туны кисәң.

Кирәк булса, коткар
Батып баручыны,
Кулың суз да коткар сагыш-
Моңга таручыны.

Кеше булып яшим дисәң,
Бул син кешелекле.
Бәхетле көн итим дисәң,
Бул син игелекле.

Укытучы. Игътибарыгыз өчен рәхмәт, кичәбез тәмам.

I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

ЙОЛДЫЗЛЫ СӘГАТЬ

(Башлангыч сыйныф укучылары өчен юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү максатыннан оештырылган уен)

Фәүзия РАМАЗАНОВА,
Арча районы Казанбаш төп мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы

Уен барышы

Укытучы. Укучылар! Бүген без юлда йөрү кагыйдәләрен кабатларбыз. Имгәнмәү, сәламәтлекне саклау безнең үзебездән тора. Әйдәгез, бүген юл йөрү кагыйдәләре буенча белемнәребезнең ныклыгын ачыклау өчен «Йолдызлы сәгать» уенын уйнап алыйк. Һәр укучыга белемнәрен, тапкырлык һәм зирәклеген күрсәтү өчен тырышырга туры килер.

Юл йөрү кагыйдәләрен машина йөртүчеләр генә түгел, җәяүлеләр дә яхшы белергә һәм үтәргә тиеш, чөнки еш кына алар гаебе белән дә юлларда төрле фаҗигаләр була. Күп балалар: «Теге машина килеп җиткәнче, мин юл аша чыга алам әле, шәп йөгерәм бит», – дип уйлый. Ләкин никадәр генә яхшы чапсаң да, машина барыбер тизрәк йөри.

Уенда катнашу өчен без 3 нче сыйныф укучыларын бирегә чакырабыз. Уенның тәртибе түбәндәгечә: мин сезгә биремнәрне укыйм, ә сез шул биремгә туры килгән җавапны сайлап аласыз һәм аның номерын югарыга күтәреп күрсәтәсез. Дөрес җавап биргән укучыга йолдыз бирелачәк. Кем йолдызны күбрәк җыя, шул укучы уенның җиңүчесе була. Уен 4 турдан торачак.

I турны башлыйбыз.

I тур

II тур



I тур

Бу билгене күрсәләр,
Шофёрлар уйланалар.
Димәк, тиздән мәктәп бар,
Игътибарга алалар. (1)

Яратсам да чабарга сәпиттә,
Туктата бу билге, әлбәттә.
Аңлата ул миңа: ярамый
Бу юлда чабарга сәпиттә. (3)

– Тукта! – дип әйтә билге,
Хәвеф-хәтәрләр юкмы?
Әгәр инде булмаса,
Газга бас та бар алга! (2)

Әй, шофёр, уйла ачык:
Синең өчен юл ябык. (4)

Укытучы. I тур шуның белән тәмам. Ә хәзер велосипед йөртүче белергә тиешле кагыйдәләрне искә төшереп китик.

Велосипед йөртүче белергә тиешле кагыйдәләр:

1. Велосипедчының яше ундүрттән ким булса, аңа ишегалдында гына йөрергә рөхсәт ителә.

2. Ундүрт яше тулганнардан велосипедның махсус теркәү билгесе һәм кагыйдәләрне белүен раслаучы документы булуын таләп итәләр.

3. Велосипедчы юлны аркылы чыкканда, велосипедтан төшеп, аны җитәкләп барырга тиеш.

Велосипед йөртүчегә тыела:

1. Рульдән бер яки ике кулны ычкындырып бару.

2. Каты төпле өстәмә утыргычы булган очракта анда, җиде яше тулмаган баладан тыш, башка пассажир утыртып бару.

3. Янәшәдә велосипед юлы булган очракта җәяүлеләр юлыннан бару.

4. Озынлыгы һәм киңлеге 0,5 метрдан артыгракка чыгып торган яисә идарә итүгә комачаулык ясый торган йөк алып бару.

II турны башлыйбыз.
Барсаң да ярый алга.
Борылсаң ярый сулга.
Бу билге фәрман бирә:
Алга, уңга барырга. (1)

Бу билгене күргәч,
Барысы да шатлана.
«Тамак ялгап алырга!»
Дип күңел канатлана. (3)

Бу билге – шундый билге:
Сине саклый, җәяүле!
Чыгабыз бергә-бергә
Юлны тик шушы җирдә. (2)

Җәяүлеләрнең җир өстендәге күпердән юлны аркылы чыгу урыны. (4)

Укытучы. II тур шуның белән тәмам. Ә хәзер **пассажирлар белергә тиешле кагыйдәләрне** искә төшереп китик.

1. Куркынычсызлык каешлары булган транспорт чараларында барганда, аларны эләктерергә кирәк.

III тур

трамвай трактор велосипед мотоцикл

2. Транспортка утыру һәм төшү фәкать тротуар ягыннан яисә юл кырыеннан транспорт туктап беткәннән соң гына рөхсәт ителә.

Пассажирларга түбәндәгеләр тыела:

1. Хәрәкәт вакытында транспорт йөртүченең игътибарын транспорт белән идарә итүдән читкә җибәрү.
2. Хәрәкәт вакытында транспортның ишекләрен ачу.

III турны башлыйбыз.

Аяклары – тимердә,
Терсәкләре – чыбыкта.
Бик ашыктырсаң үзен,
Китәр кебек очып та. (*Трамвай)*

Кылга асылына, тимергә таяна,
Утыртып чаба теләсә кая. *(Трамвай*)

Ике аяклы үгез, маңгаенда куш мөгез. *(Велосипед*)

Тимер ат җир сөрә,
Ашарга сорамый. *(Трактор*)

Аяклары түгәрәк –
Куышалар тәгәрәп,
Үзем утырам, үзем чабам,
Әй, «очабыз» бергәләп. (*Велосипед)*

Яремә менәләр,
Өзәнгемә тибәләр,
Йөгертәләр, чаптыралар,
Кирәк җиргә илттерәләр. *(Мотоцикл)*

Укытучы. III тур шуның белән тәмам. Ә хәзер тагын берничә кагыйдәне искә төшереп үтик. Аларны белү һәркем өчен мөһим!

1. Туктап торган трамвайның алдыннан гына үт.
2. Юл аша чыкканда йөгермә.
3. Транспортта барганда, башыңны тәрәзәдән чыгарма.
4. Җәяүле тротуардан гына, анда да уң яклап кына барырга тиеш.
5. Юл аркылы бары тик рөхсәт ителгән җирдән генә чыгарга ярый. Җир асты юлы бар икән, шуннан үтәргә кирәк.
6. Урам аша чыгар алдыннан светофорга кара, әгәр яшел ут яна икән, димәк, юл ачык.
7. Юл аша чыкканда, башта сулга, аннан уңга кара.
8. Юл кырыенда уйнау куркыныч.
9. Юлның уң ягыннан гына йөр!
10. Тротуар булмаган урыннарда –

IV тур

җәяүле пассажир юл хәрәкәтендә катнашучы йөртүче

сул яктан, каршы килә торган транспортка карап бар!

11. Машина юлыннан йөрү, машина артына асылынып бару, транспорт юлында уеннар оештыру закон нигезендә тыела!

IV турны башлыйбыз.

Нинди дә булса транспорт чарасы белән идарә итүче кеше. (*Йөртүче)*

Юлда транспортка катнашы булмаган һәм анда эш башкармый торган кеше. (*Җәяүле)*

Өйдән урамга чыгуга син кем буласың? *(Юл хәрәкәтендә катнашучы*)

Йөртүчедән башка, транспорт чарасының эчендәге (өстендәге) кеше, шулай ук транспорт чарасына керүче (утыручы) яисә аннан чыгучы (төшүче) кеше. *(Пассажир)*

Укытучы. Афәрин, укучылар! Сез тапкырлыкта сынатмадыгыз, игътибарлы булдыгыз. Белемнәрегезне күрсәттегез. Хәзер уенның җиңүчесен билгеләрбез. *(Йолдызлар санала, җиңүче билгеләнә. Бүләкләр тапшырыла.)* Барыгызның да юлларда исән-имин йөрүен теләп калам. Юл йөрү кагыйдәләрен истән чыгармагыз.

Юлда йөрсәң, бул өлгер,
Юл кагыйдәсен нык бел.
Светофорның бел төсен,
Һәм дә юл билгеләрен.

Нәрсә өчен светофорның
Сиңа күзен кысканын;
Нәрсә өчен инспекторның
Өскә таяк сузганын;

Юл читендә ни өчен.
Рәсемле колга тора?
Дусларыңнан сораштыр.
Өлкәннәрдән караштыр
Барысын белергә тырыш,
Оештырма юлда ярыш.

Машина узганын көтми –
Йөгермә син тизрәк,
Моны белү һәр балага,
Кайда йөрсә дә, кирәк.

(Уен укучылар башкаруында «Юл хәрәкәте» җыры (Ф.Мортазин көе, А.Хәмзин сүзләре) белән тәмамлана.)

I БҮЛЕК. БЕЛЕМ. ТӘРБИЯ.

ЮЛЛАР ИМИН БУЛСЫН!

(Башлангыч сыйныф укучылары өчен юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү максатыннан оештырылган уен)

Фәридә КӘЛИМУЛЛИНА,
Түбән Кама шәһәренең 27 нче «Сандугач» балалар бакчасы тәрбиячесе

Уен барышы

(«Күңелле балачак» җыры (И.Шәмсетдинов көе, Т.Латыпов сүзләре) яңгырый, балалар залга керә һәм ярымтүгәрәккә баса.)

1 нче бала.
Кояшның шаян нурлары
Иркәли безне иртән,
Күңелле, тапкыр уеннар
Күптәннән безне көткән.

2 нче бала.
Юлны аркылы чыкканда
Карыйм уңга һәм сулга.
Күрсәм алдымда машина,
Ашыгып басмыйм юлга.

3 нче бала.
Урамда сак булыгыз,
Кагыйдәне белегез:
Онытмагыз беркайчан да,
Бәлага юлыкмагыз!

4 нче бала.
Без бәйрәмгә килдек бүген,
Бәйрәм күңелле узсын.
Җырлыйк, уйныйк,
Уйлыйк, дуслар,
Җаваплар дөрес булсын.

Алып баручы.
Чыннан да, балалар, җаваплар дөрес булсын. Табышмаклар әйтәм. Уйлап кына җавап бирегез әле.
Кылга асылына, тимергә таяна. *(Трамвай)*

Утырып чаба
Теләсә кая.
Ике аяклы үзе,
Маңгаенда куш мөгезе. *(Велосипед)*

Ура, суга, җилгәрә,
Үзе төяп җибәрә. *(Комбайн)*
Ул үзе шундый көчле,
Тешле-тешле чүмече.
Бер үзе эшли ала
Җиде кешелек эшне. *(Экскаватор)*
Канаты бар – йоны юк,
Үзе бара – юлы юк. *(Очкыч)*

Тәрбияче. Булдырдыгыз, афәрин! Балалар, сүз нәрсәләр турында барды? Әйе, транспорт чаралары

турында. Балалар, үсеп җиткәч, машина йөртә башлагач, сез кем буласыз? *(Шофер)*

(«Шофер булам» җыры (Ә.Хәйретдинов көе, Х.Халикова сүзләре). Ишектән, кызу-кызу атлап, Белмәмеш килеп керә.)

Белмәмеш. Соңга калам йөгерә-йөгерә арып беттем, әздән генә машина астына эләкмәдем.

Тәрбияче. Юлда йөргәндә сак булырга кирәк шул, Белмәмеш. Син балалар белән исәнләшмәдең бугай.

Белмәмеш. Әй, шулаймыни! Онытканмындыр инде, гафу итегез мине. Исәнмесез, балалар!

Балалар. Исәнмесез.

Тәрбияче. Белмәмеш, без балалар белән юл йөрү кагыйдәләрен өйрәндек. Ә син юлда йөри беләсеңме?

Белмәмеш. Беләм, беләм, барлык юл кагыйдәләрен дә беләм.

Тәрбияче. Бик яхшы. Алайса, син безне дә өйрәт. Әйт әле, юл аркылы чыкканда син нәрсәгә игътибар итәсең?

Белмәмеш. Әй, нәрсә карап торасың инде анда. Туп-туры урамның теге ягына карыйсың да рәхәтләнеп чабасың алга таба.

Тәрбияче. Балалар, Белмәмеш дөрес әйттеме? Урам аша ничек чыгарга кирәк?

Балалар. Башта сулга, юлның ярты-сына җиткәч, уңга карыйбыз. Юл буш булса, юл аркылы чыгабыз. Әгәр дә светофор булса, светофорга карап чыгабыз. Кызыл янса: көтәбез, сары янса – әзерләнәбез, яшел янса – чыгабыз.

Тәрбияче. Аңладыңмы, Белмәмеш? Тагын бер сорау бирим әле. Машиналар йөри торган юлда уйнарга буламы?

Белмәмеш. Була, була! Ник булмасын? Асфальт тип-тигез. Туп уйнасаң да, футбол уйнасаң да,

рәхәт. *(Белмәмеш туп атып уйный башлый.)*

Тәрбияче. Юк, юк, туп белән юлда беркайчан да уйнарга ярамый. Юлда уйнасаң, нәрсә булганын хәзер үзең дә аңларсың. *(Театраль күренеш.)*

Воспитатель. Ой, к нам ещё кто-то пришел? Ах, кажется, я знаю, кто это? Давайте сядем поудобнее на коврик и посмотрим, что будет дальше.

С левой стороны ширмы появляется котенок, он напевает веселую песенку.

Котенок. Ля-ля-ля, мяу-мяу, ля-ля-ля. Ой, здравствуйте, дети!

Дети. Здравствуй, котенок!

Котенок. Ребята, а вы не видели моего друга Тузика?

Дети. Нет, не видели.

Котенок. Куда же он сегодня запропастился. *(Зовет его.)* Тузик! Тузик!

(С правой стороны ширмы появляется Тузик.)

Тузик. Ав, гав, гав! Кто это меня звал?

Мурзик. Ой, это же я, Мурзик! Здравствуй, Тузик!

Тузик. Здравствуй, а зачем ты меня искал?

Мурзик. Что-то мне скучно стало. Давай, в догонялки играть.

Тузик. Давай, только здесь играть нельзя, здесь машины ездят. Играть нужно во дворе у дома.

Мурзик. Нет, Тузик, давай здесь играть. Дорога вон какая широкая и длинная. Места здесь много.

Тузик. Ну, давай здесь! Давай! *(Тузик разворачивается и пытается уйти, но Мурзик дергает его за хвост. Тузик сердится и тоже догоняет Мурзика, дергает за хвост. Начинается игра в «Догонялки», раздается сигнал автомобиля. Друзья не замечают машины, и котенок попадает под колеса.)*

Мурзик. Ой, ой, ой! Больно! Мне очень больно! Хвостик болит.

Тузик. (*Утешает его.*) Я ведь тебе говорил, нельзя играть на дороге, а ты… *(Котенок продолжает плакать.)*

Воспитатель. Ребята, с котенком беда! Как ему помочь?

Дети. Нужно позвать врача.

Воспитатель. *(Набирает номер телефона скорой помощи.)* Алло, алло, у нас беда. Котенок попал под машину. (*Входит медсестра.)*

Медсестра. Что случилось? Где больной? Сейчас я ему перебинтую хвостик! (*Бинтует хвостик котенку. Он перестает плакать.)*

Котенок. Спасибо, я больше не буду играть на дороге.

Воспитатель. Вот видите, ребята, что может случиться, если дети играют на дороге.

Ты, котенок, посиди,
На ребяток погляди.

Тәрбияче. Менә Мурзик белән нәрсә булганлыгын күрдегезме? Мондый хәлләр кабатланмасын өчен кайда уйнарга кирәклеген иптәшегез сөйләп күрсәтер.

Бала.
Юлда беркем уйнамый,
Анда уйнау ярамый.
Уйнагыз сез өй алдында
Һәм урман аланында.

Тәрбияче. Ә хәзер, әйдәгез, уйнап алабыз.

(«Туп белән уен». Балалар түгәрәккә баса һәм, тупны кулдан кулга җибәреп, сүзләр әйтә.)

Түгәрәк туп, күңелле туп,
Кулдан кулга тәгәрә.
Түгәрәк туп кемдә кала,
Шул хәзер җәза ала.

Сораулар:

Син урамга чыккач кем буласың? *(Җәяүле)*

Автобуска кергәч кем буласың? *(Пассажир)*

Светофорда ничә төс? *(Өч төс)*

Нинди транспорт төрләрен беләсең? *(Бала санап китә.)*

Автомобильләр тротуар буйлап йөри аламы? *(Юк, йөри алмый.)*

Махсус транспорт төрләре. *(Санап кителә.)*

Нәрсә ул зебра? *(Җәяүлеләр чыгу урыны)*

Светофорның нинди төсенә урам аша чыгасың? *(Яшел төскә)*

Машина, автобус көтү урыны ничек атала? *(Тукталыш)*

Җәяүле йөри торган юл. *(Тротуар)*

Һава транспортын әйтегез. *(Очкыч, вертолет)*

Светофорның кызыл төсе нәрсә аңлата? (*Чыгарга ярамый.)*

Нәрсә ул урам чаты? *(Ике урам кисешкән урын)*

Юлда машиналар юнәлешен кем күрсәтә? *(Көйләүче – юл инспекторы)*

Машина нәрсә белән йөри? *(Бензин, солярка, газ)*

Тәрбияче. Белмәмеш, әйт әле, урамның хуҗасы нәрсә дип уйлыйсың?

Белмәмеш. Әлбәттә, мин.

Тәрбияче. Дөресме? Ничек уйлыйсыз, балалар? *(Балалар җавап бирә.)* Дөрес, светофор.

1 нче бала.
Бездән бер дә көлмәгез,
Кызыл утка йөрмәгез.

2 нче бала.
Яшелләр һәрвакыт алда,
Алар тәртипле юлда.

3 нче бала.
Сары утка сабыр ит,
Яшел янгач, атлап кит

Тәрбияче. Балалар, сүз нәрсә турында барды бу шигырь юлларында?

Дөрес, юлның хуҗасы светофор турында. Һәрвакытта игътибарлы булып светофорга карарга кирәк.

(«Светофор» уены.)

Тәрбияче. Белмәмеш, ә син юл билгеләрен беләсеңме?

Белмәмеш. Беләм, беләм! Монда килгәндә дә әллә ничәне күрдем.

Тәрбияче. Әйдә, алайса, бер уен уйнап алыйк әле. Менә бу тактада юл билгеләре куелган. Син аларның нәрсә аңлатканын беләсеңме?

Шулар арасыннан безгә «автобус тукталышы» билгесен тап әле.

Белмәмеш. *(Эзли.)* Менә шушы инде. Үзе пычаклы, үзе чәнечкеле. Монда тагы тәлинкә белән бер тәмле әйбер дә булса… рәхәтләнеп автобус көтеп була.

Тәрбияче. Балалар, Белмәмеш дөрес күрсәттеме? Нинди билге алды ул? (Ашханә) Белмәмеш, тагын нинди билгеләрне беләсең соң?

Белмәмеш. Беләм мин, беләм. (*Карый, бер билгене дә әйтә алмый. Балалар барлык билгеләрне дә әйтеп чыга.)*

Тәрбияче. Туктале, Белмәмеш. Мин сиңа табышмак әйтәм, ягъни булышам. Бәлки искә төшәрерсең.

Бу билге кисәтүче –
Светофор командасын
Ул безгә күрсәтүче. *(«Игътибар: светофор»)*
Игътибарлы бул, шофер,
Билгеләр шуны әйтә –
Якын бакча, мәктәп тә. *(«Игътибар: балалар»)*
Монда юл эше бара.
Игътибарлы булсагызчы,
Зурлар һәм нәни бала. *(«Юл эшләре»)*

Дөрес, балалар. Болар безне кисәтүче билгеләр булды.

Белмәмеш. Рәхмәт сезгә, балалар. Менә хәзер мин юлларда курыкмыйча йөри алам инде. Чөнки сездән юл билгеләрен, кайсы нәрсә аңлатканын өйрәндем.

(«Дорожные знаки» җыры.)

Тәбияче. Син автобуста, трамвайда йөргәндә билет аласыңмы?

Белмәмеш.

Нигә билет алып торырга, куян кебек качып кына йөрим мин.

Тәрбияче. Белмәмеш, әйдә әле, безнең белән «Билетсызга урын юк» дигән уен уйнап алыйк. Аннан соң ни өчен билетсыз йөрергә ярамаганны аңларсың. (Бер баланың күзенә тасма бәйлиләр.)

Автобусны туктатып
Төшердек билетсызны.
Әйтче, дустым, ничек икән
Исеме билетсызның?

(Шул сүзләрне әйтәләр һәм бер баланы залдан чыгарып җибәрәләр. Тасмалы баланың күзен ачкач, ул кем юкка чыкканын белергә тиеш.)

Белмәмеш. Уен миңа бик ошады. Ни өчен билет алырга кирәклеген аңладым. Рәхмәт сезгә.

Тәрбияче. Балалар, юлда машиналар юнәлешен кем күрсәтә? (юл инспекторы, полиция, юл хәрәкәтен көйләүче) *(«Регулировщик» биюе башкарыла.)*

Тәрбияче. Әйе, алар юлда иң кирәкле кешеләр. Юл фаҗигасе булмасын өчен күп көч куялар. Ләкин безгә дә уяу булырга кирәк. Әйдәгез, сезнең белән шул хактагы мәкальләрне искә төшереп үтик.

Юлда булсаң, уяу бул.
Юлда акылыңны югалтма.
Ашыккан ашка пешкән
Юлда да акыл кирәк.

(Балалар шигырьләр сөйли. «Инспектор ГАИ» җыры башкарыла.)

Белмәмеш. Рәхмәт, дусларым. Юлга чыкканда да сезгә ышанырга була. Мин сездән күп нәрсәләр өйрәндем. Юлда йөрү кагыйдәләрен үземнең барлык дусларыма да өйрәтермен. Сау булыгыз.

1 нче бала.
Апалар безне өйрәтә –
Һәр бала белә торсын.
Без юкта әти-әниләр
Һәрвакыт тыныч торсын.

2 нче бала.
Рәхмәт инде апаларга
Безне өйрәткән өчен.
Рәхмәт сезнең барчагызга
Үз итеп килгән өчен.

3 нче бала.
Дуслар булгач, бик күңелле
Җырлыйсы килеп тора.
Күңелдә шатлык ургылып
Ташып мәйданга чыга.

4 нче бала.
Сез дә җырга кушылыгыз –
Яңа матур җыр тусын.
Еллар тыныч, юллар имин,
Барчабыз исән булсын.

II БҮЛЕК. ТАБИГАТЬ. ЭКОЛОГИЯ.

ХУШ КИЛӘСЕЗ, КОШКАЙЛАР!

(Мәктәпкә әзерлек төркемендә бәйрәм кичәсе)

Раушания НИГЪМӘТУЛЛИНА,
Балтач районы Карадуган
балалар бакчасы тәрбиячесе

Алып баручы. Балалар, кошлар бәйрәменә рәхим итегез. Тикмәгә генә кошларны канатлы дусларыбыз дип әйтмиләрдер. Җир шарында 10 меңнән артык, илебездә 700дән артык кош очрый. Безнең республикада исә җәй көннәрендә 200дән артыграк, ә кышын 40лап төр кош яши. Кошлар һавада очарга җайлашкан. Таулар, урманнар, диңгезләр аша очу кошлар өчен бик үк авыр түгел. Козен, суыклар башланып, ашарга азык калмагач, алар җылы якларга очып китә. Яз житкәч, кире туган якларына әйләнеп кайта. Яз билгеләре дип нәрсәләрне саный алабыз? *(Балалар җавабы тыңлана.)* Дөрес балалар. Түбәләрдән тамчы тама, кояш ныграк яктырта, кар эри.

(Ж.Фәйзи көе, Ф. Кәрим сүзләре) «Яз житә» жыры.

Алып баручы. Безнең якны сагынып кайтучы кошларның сез кайсыларын беләсез һәм күргәнегез бар*? (Кара карга, сыерчык, карлыгач, тургай, торна, кыр үрдәге, кыр казы, аккош, челән, сандугач һ.б. рәсемнәре күрсәтелә).*

Ә хәзер кошлар турында табышмаклар әйтик:

Агач башында йорты,
Эчендә яши җырчы. ***(Сыерчык)***
Канаты бар, оясы юк,
Ят ояда баласы тук. ***(Күке)***
Ерактан килгән кунак булса да,
Тәрәзә астында тора. ***(Карлыгач)***
Бер кошым бар: тынмый,
Агачка оя кормый,
Өе – җирдә, җыры – күктә. ***(Тургай)***
Борыны озын, аягы озын,
Камышлыкта көнозын.
Сазлык җирләрдә йөри,
«Торрыйк, торрыйк!» – дип сөйли. ***(Торна)***

1 нче бала.

Ачылды ак калын юрган,
Исте апрель җилләре.
Кошлар кайта: сагындырган
Туган- үскән жирләре.

2 нче бала.

Кайтыгыз инде, кошкайлар,
Сагындык үзегезне.
Кайтырлар дип, зәңгәр күктән
Алмыйбыз күзебезне.

3 нче бала.

Ярый әле киткән чакта
Бөтенләйгә китмисез.
Яз быел да бигрәк гүзәл –
Тик сез генә җитмисез!

Алып баручы. Иң беренче булып яз хәбәрчеләре – кара каргалар очып кайта.

(Каргалар булып киенгән балалар керә.)

Кара каргалар.
Кар, кар, кар! Тиздән эреп бетә кар.
Канатымда хатым бар –
Буең житсә, тартып ал! *(Хатны укыйлар.)*
Туган якка тиздән кайтырбыз.
Матур язны сагындык.
Сез дусларны сагындык.
4 нче бала.
Каршы алабыз сезне
Үз итеп, сөенеп
Диңгез, чүлләрне исән-сау
Кичеп кайткансыз диеп.
Алып баручы. Кара каргалар кешеләргә күп файда китерә. Җәен бер кара карга чама белән 8 меңгә кадәр бөҗәк чүпли. Рәхим итегез, каргалар, безнең бәйрәмебезгә.
Алып баручы.
Сыерчыктан Вилгә
Телеграмма килгән:
«Сезгә кунак булып киләм, – дигән, – тиздән…
Бик сагындым сезне,
Якты йөзегезне,
Каршы аласыз шул
Бик яратып безне», – дигән.
Әйе, сыерчык – безнең иң яраткан кошыбыз. Ул үзенең матур итеп сайравы белән безне сокландыра һәм корткыч бөҗәкләрне, лайлач әкәм-төкәмнәрне ашап зур файда китерә. Сыерчыклар кайтышына без нык әзерләндек, әти-әниләребез белән сыерчык ояларын ясап алып килдек. *(Сыерчык оялары күрсәтелә. Сыерчык керә.)*
Алып баручы.
Сөенче, сөенче!
Сыерчык, сыерчык!
Сөекле кошчыклар
Килгәннәр бит очып.
Ямьле яз җырчысы –
Сөйкемле сыерчык.
Әй, сайрый дәртләнеп,
Иңнәрен сикертеп.
Сыерчык.
Ак буяулы бер оя бар,
Бакчада зур агачта.
Очып киләм шул ояга
Ел саен яз булгач та.
Шунда торам, шунда йоклыйм,
Шунда бала үстерәм.
Матур итеп сузып сайрыйм,
Басып оя өстенә.
(«Сыерчык» җыры (Г.Лотфи сүзләре, И.Шәмсетдинов көе)
Алып баручы. Иртә язда басу һәм далалар өстендә – биектә бер кош оча. Ул нинди кош икән? *(Тургай.)* Тургай канат кага-кага өздереп сайравы белән һәркемне таң калдыра. Шулай итеп, ул игенчене кырга чакыра, язгы чәчүне башларга куша.
Тургай.
Исәнмесез, дусларым,
Мин дә сезне сагындым.
Туган як кырларына
Тизрәк очып кайттым.
5 нче бала.
Ай-һай, тургай, биек менгәнсең,
Югарыдан безне күрәмсең,
Без бит сине өзелеп сагындык,
Тавышыңны бик тиз танырбыз.
(«Тургайлар килде» җыры (Г.Латыйпов сүзләре, Ш.Мәҗитов һәм Ю.Виноградов көе)
Алып баручы. Яз житкәч, безнең якларга карлыгачлар очып кайта. Алар ару-талуны белмичә, көне буе ауда йөри, озынборын, чебен-черкиләрне аулый.
Карлыгач.
Сагынып кайттым авылымны,
Оя корган жиремне.
Балчык ташып, оя ясап,
Балалар чыгарырмын.
(«Карлыгач» җыры (Г.Тукай сүзләре, З.Хәбибуллин көе)
Алып баручы.
Кыр казлары җылы якта
Кайтып килә тезелеп,
Моң салалар: Су буйларын
Сагындык, – дип, – өзелеп.
Йөгерешеп, сәлам биреп,
Каршылыйбыз һәр казны,
Канатларында жилпетеп,
Китерә алар язны.
Кыр казлары.

Тезелешеп, гаскәр кебек
Ераклардан илләр гизеп,
Болын буйлап, кырлар буйлап
Кайтабыз без язны зурлап.
Кычкырабыз: «Кайттык урап,
Саулармысыз? Кыйгак -кыйгак».

Алып баручы. Рәхим итегез, кыр казлары. Су буйлары, күлләр көтә сезне.

Кыр казлары артыннан ук туган ягыбызга торналар да кайтып төште. (*Торна булып киенгән балалар керә.*)

Алып баручы. И, торналар, кайда булдыгыз?

Торналар. Бик ерак.

Алып баручы. Озын булдымы юлыгыз?

Торналар. Бик озак.

Ә шулай да калмадык без югалып,
Сезгә килдек, якын дуслар, яз алып.

Алып баручы. Рәхмәт сезгә, торналар, туган якны сагынып кайткан өчен. Сездән башка язлар күңелсез булыр иде.

Алып баручы. Менә күкеләр дә кайтып җиткән.

(Күке булып киенгән бала керә.)

Күке. Кәккүк-күккүк.

Алып баручы. Күке, син ник болай моңсу?

Күке. Башка кошлар күк
Мин оя кормыйм.
Мин ялгыз яшим.
Чыгармыйм бала.
Менә шунлыктан
Ямансу миңа.
Мин чит ояга
Күкәйләр салдым.
Эзлим шуларны
Кычкырып һаман:
Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!

Алып баручы. Моңсуланма инде, кәккүк! Эзләп табарсың балаларыңны, кайгырма. Балалар сиңа һәм башка кошларга бию бүләк итәр *(Бию.)*

Ә хәзер күке белән уйнап алыйк.

(«Күке» хәрәкәтле уены. Балалар түгәрәккә парлап басалар – кошлар (түгәрәк тышында) һәм оялар (түгәрәк эчендә) булалар. Күке түгәрәк буйлап йөгерә, түгәрәкнең тышкы ягында торган баланың җилкәсенә кагыла һәм «күү-күү» ди. Күке белән бала түгәрәк тышыннан кара-каршы якка йөгерәләр. Парның алдында торган бала кош булып түгәрәкнең тышкы ягына баса. Аның урыны, ягъни оя буш кала. Күке шул ояга беренче килеп җитсә, бала күкегә «әйләнә»; җитә алмаса, күке уенны дәвам итә.)

Алып баручы. Кошларның файдасы гаять зур: алар зарарлы бөҗәкләрне юк итә, үсемлек орлыкларын тарата, чәчәкләрне серкәләндерә.

Шуңа күрә канатлы дусларыбызны сакларга, ояларын туздырмаска, күкәйләрен ватмаска, яшелчә һәм җиләк- җимеш бакчаларына оялар ясап куярга кирәк.

6 нчы бала.

Хуш киләсез, кошкайлар,
Сайрагыз көнен-төнен.
Кайда ошый, сайлагыз,
Жир-сулар бик киң безнең.

7 нче бала.

Килсен, әйдә, килсеннәр,
Без – дуслары кошларның.
Оялар куйдык, керсеннәр,
Бүләге дип дусларның.

Алып баручы. Ә хәзер сорауларга җавап бирик:

Кайсы кошның балтасы борынында? ***(Тукран)***

Кайсы кош ауга төнлә генә чыга? ***(Ябалак)***

Кайсы кошның фатиры кар астында? ***(Көртлек)***

Кайсы кошның балалары әниләрен белми? ***(Күке)***

(Бәйрәм ахырында табышмакларның җавапларын дөрес әйтүчеләргә рәхмәт белдерелә, сыерчык ояларын иң яхшы ясаучыларга бүләкләр бирелә. Бәйрәм күмәк бию белән тәмамлана.)

II БҮЛЕК. ТАБИГАТЬ. ЭКОЛОГИЯ.

КОШЛАР ДӨНЬЯ

(Урта сыйныфларда дәрестән тыш чара)

Райлә ЛАТЫЙПОВА,
Арча районы Казанбаш
төп мәктәбе укытучысы

Чара барышы

Алып баручы. Укучылар, без бүген кошлар турында сөйләшү өчен түгәрәк өстәл янына җыелдык. (*Бер укучы Шәйхи Маннурның «Кошлар килде» шигырен яттан сөйли*).

Алып баручы. Сүзне тарихчыга бирәбез. Ул сезне «Кошлар көне» билгеләнү тарихы белән таныштырыр.

Тарихчы. Кошлар көне беренче апрельгә туры килә. Нәкъ шушы көнне бөтен дөньяда канатлы дусларыбызны саклау көне үткәрелә. Ни өчен беренче апрельдә диярсез? Чөнки «Кошлар көне»н дөньяда беренче тапкыр АКШта 1894 елның 1 апрелендә билгеләп үткәннәр. Ә 1906 елның 1 апрелендә «Кошларны саклау турында» дөньякүләм конвенция кабул ителгән. Россиядә бу көн беренче тапкыр 1927 елның 1 апрелендә билгеләнә. Ул чакта Мәскәүдә кошларга ярдәм йөзеннән меңнән артык сыерчык оясы эленә. Әлеге чарада балалар белән беррәттән зурлар да теләп катнаша. «Юный натуралист», «Живая природа» кебек журнал битләрендә ул турыда язмалар басылып чыга. Тарихка янә күз салсак, узган гасырның 30 нчы елларында бездә кошларны саклау көне беркадәр онытылып торган. Бөек Ватан сугышы алдыннан ул яңадан уздырыла башлаган. Соңгы елларда «Кошлар көне»нә яңа сулыш өрелде, ул янә бәйрәм булып әйләнеп кайтты. Хәзер мондый чаралар ЮНЕСКО программасы кысаларында уздырыла.

Алып баручы. Хөрмәтле укучылар, табигатьтә яз сулышы үзен көннән-көн ныграк сиздергән вакытта «Кошлар дөньясына сәяхәт»кә чыгуыбыз тикмәгә генә түгел. Чөнки кошлар – яз хәбәрчеләре, алар җир йөзендә иң күп таралган һәм иң үзенчәлекле тереклек ияләре. Сүзне ортинологка бирәбез. Ортинолог – ул кошларны өйрәнүче белгеч.

Ортинолог. Бүгенге көндә кошларның 8700гә якын төре исәпләнә. Ә инде кошларның гомуми санына килгәндә, танылган инглиз галим Джеймс Фишер планетабызда 100 миллиардтан артык кош яши дип саный. Россиянең иксез-чиксез киңлекләрендә 700ләп төр кош очрый. Татарстаныбызның да урман-болыннары кошларга бай, аларның фаунасы да бик төрле: бездә 19 отрядтан торган 300 гә якын төр кош исәпләнә.

Алып баручы. Кошлар – табигатебезнең күрке. Аларның күңелгә ятыш моң-жырларын ишетеп, кайсыбызның гына хозурланганы, илһам алганы юк икән?! Алар арасында безнең якта кышлаучы кошлар да, күчмә кошлар да бар. Болардан безгә иң танышы... *(Кара карга тавышы ишетелә.)* Таныдыгызмы? Әйе, бу кара карга тавышы.

Хәзер сүзне кара каргаларны өйрәнүче галимгә бирәбез.

Галим. Төньякта яшәүче каргалар – күчмә кошлар, көньякта яшәүчеләре утрак тормыш алып бара. Алар агачларга зур төркем хасил итеп оялый. Авыл тирәләрендә аларның колонияләре еш күренә. Болар үзләре корган ояларын 10 еллап саклый һәм гел бер урынга әйләнеп кайта. Кара каргалар бар әйберне дә ашый, кешеләрдән калган азык белән дә, орлык белән дә туклана.

ҺСЫНА СӘЯХӘТ

Алар безнең якларга иртә язда, әле кар бетмәгән чакта ук килә. Ана карга 3-7 йомырка сала, балалары апрель ахырында чыга. 30 көннән соң алар балаларын очарга өйрәтә.

Тарихчы. Каргалар турында кызыклы тарихи материаллар бар. Европада, күпчелек Германия һәм Украинада, әле XIX гасыр ахырында да ярлы халык карга итен ризык итеп кулланган. Германиядә карга итен хәтта тозлап ашаганнар.

Авыл хуҗалыгы белгече. Каргалар юл кырыйларына коелган бөртекне, үсемлекләрдән калган орлыкны чүпли, шул ук вакытта җир өстендәге бөҗәкләр белән туклана. Җәй көне май коңгызларын, каен һәм усак агачындагы яфраклардан бөҗәкләр чүпли. Шулай ук алар вак кимерүчеләргә дә көн күрсәтми. Бу яктан авыл хуҗалыгына зур файда китерә. Әмма карганың зыяны да юк түгел. Ул кукуруз, борчак орлыкларын чүпләргә ярата, чәчү вакытында сука артыннан яңгыр суалчаннарын җыя. Оя корган вакытта агачларның оч ботакларын сындырулары, тизәкләре белән агач яфракларын яндырулары да зыян китерә.

Алып баручы. Кара каргалардан соң... (*Сыерчык тавышы.)* Әйе, сыерчыклар кайта. Сүзне янәдән галимгә бирәбез.

Галим. Сыерчыклар ояларын агач куышларына ясыйлар. Шулай ук бу кошлар өчен авыл һәм шәһәр тирәсенә кешеләр дә оя ясап элә. Алар эре бөҗәкләр, әкәм-төкәмгә охшаш вак шуышучылар белән туклана. Агачлардагы җимешләрдән дә авыз итә. Бу кош корткыч бөҗәкләрне аулавы белән авыл хуҗалыгына зур файда китерә. Сыерчыкның аерым сүзләр һәм җыр «көй»ләрен оту үзенчәлеге бар. Ул үзе кышлаган урындагы кошлар тавышы белән җырлый. Сандугач, тургай кебек кошлар тавышын да бик ошатып кабатлый.

Эколог. Сыерчыклар җиләк-җимешкә һәм орлыкларга зыян салып, икътисадый яктан зыян китерә. Алар шулай ук кешеләргә йога торган авыруларны күчерүчеләр булып тора. Бластимикоз, цистицеркоз, гистоплазмос кебек авырулар алар аша йогарга мөмкин. Сыерчыкларның зур көтүләре аэропорт эшчәнлегенә дә комачаулый. Бу кошларның гомер озынлыгына килсәк, алар 12 елга кадәр яши ала.

Тарихчы. Беренче сыерчык оясын голландиялеләр XVI гасыр башында ясый башлый Ул оялар кызыл балчыктан эшләнгән тишекле савытлардан гыйбарәт була.

Алып баручы. Сүзебезне шушы урында туктатып, без яраткан тагын бер кош авазын тыңлап алыйк. *(Кыр казы тавышы.)*

Алып баручы.

Әйе, сүзне кыр казы турында дәвам итәбез.

Галим. Кыр казы – су кошы, үрдәкләр һәм аккошлар белән бер төркемгә керә.Ул үрдәктән зуррак, аккоштан кечерәк. Барлык кыр казлары да кыска тәпиле һәм озын муенлы. Аккошлардан аермалы буларак, аларның томшыклары озынрак һәм ян-ягыннан кысылган була. Ана каз һәм ата каз төсләре ягыннан бертөрле. Йорт казларыннан аермалы буларак, аларның томшыгында фәкать аларга гына хас теш пластинкалары бар. Болар азык чәйнәр өчен бик кулай. Кыр казларының тәпиләре зур һәм ятьмәле. Шуның белән суда йөзәр өчен уңай. Барлык кыр казлары да курку белмәс батырлар. Алар үзләренең биләмәләрен чит-ятлардан аяусыз саклый. Бу кыргый кошлар оя корган вакытта бигрәк тә явыз. Зур кыр казы ачуы чыккан вакытта хәтта кешене яхшы гына чукып алырга мөмкин.

Эколог. Кыр казлары сәгатенә 65 чакрым тизлек белән оча ала. Иң биек оча торган кыр казы – тау кыр казы. Ул 7000 метр биеклеккә кадәр күтәрелә.

Алып баручы. Безнең тирәдә яшәүче бу матур кошның тавышын кем генә танымас икән! *(Тукран тавышы.)* Сез танып алган тукран турында сөйләү өчен сүзне кабат галимгә бирәбез.

Галим. Тукран урман санитары булып санала. Ул агач кәүсәсенең аскы өлешеннән кортларны чүпли башлый һәм, һәр ботакны җентекле тикшереп, өскә таба менә. Шулай итеп 12-16 метр биеклеккә кадәр күтәрелә. Көзге салкыннар башлангач, тукран чыршы, нарат күркәләре эчендәге орлыклар белән туклана.

Тукран бик зур түгел, аның озынлыгы 23-26 сантиметр гына була. Күзләре кызыл, 5–8 сантиметрлы томшыгы соры. Муенының һәм аркасының өске өлеше кара төстә. Теле гәүдәсеннән дә озынрак. Аягы зәңгәр, кызгылт сары, көрән төсләрдә була. Баш очы кызыл. Тукран, бик әйбәт очса да, күбрәк үрмәләргә ярата.

Эколог. Тукраннар бөтен жир шары буйлап таралган, аларны бары тик Австралиядә һәм Мадагаскар утравында гына очратып булмый. Хәзерге вакытка 380 төре билгеле. Яз көне тукраннар гаилә төзи башлый. Ояларны каенда, имәндә, усакта кора. Апрель ахырында, май башында балалары чыга. Алар туганда бер әйбер дә күрми, ишетми, бернинди тавыш чыгара алмый, ике атнадан соң гына тавышлары чыгып, тиз арада көрәеп китә һәм 80-100 метр ераклыкка кадәр ишетелә башлый. Ата тукран аларга 2 минут саен ашарга алып килә.

Авыл хуҗалыгы белгече. Яз һәм җәй көннәрендә тукраннар төрле бөҗәк һәм личинкалар ашый. Тукран авыру агачлар янында була, ә таза агачларга кагылмый. Көнгә 600-700 бөҗәкнең «башына җитә». Ашарга азык тапмаган очракта колбаса, сыр кисәкләре, хайван үләксәләре, төрле орлыклар белән дә туклана.

Алып баручы. Кызылтүшләр – безнең урмандагы иң матур кошлар. Сезнең әле аларның тавышын ишеткәнегез юктыр. *(Кызылтүш тавышы.)* Кызылтүшләрнең тормышы белән танышу өчен сүзне галимгә бирәбез.

Галим. Бездә очрый торган кызылтүшләр Евразия кызылтүшләре булып санала. Аларны куе урманнарда да, сирәгрәк урманнарда да, паркларда һәм бакчаларда да очратып була. Ләкин без кызылтүшне бик сирәк күрәбез, бигрәк тә җәй айларында. Кышын кар өстендә аларны әллә каян танырга була, чөнки аның түше кызыл һәм ап-ак карда аерылып тора. Кош артык зур түгел, күзләре кап-кара. Каурыйлары кара, зәңгәр таплары бар. Койрык яны ак, аркасы көрән төстә. Йөзләренең кайбер җирләре, корсагы һәм ян-яклары кызыл. Калган җирләренең төсләре, нинди төрдәге булуына карап, төрлечә булырга мөмкин.

Кышын кайбер кызылтүшләр, башка кошлар кебек, җылы якларга – көньякка таба очып китә, хәтта Амурга, Байкал аръягына, Кырымга һәм Төньяк Африкага кадәр барып җитә. Алар да март-апрель айларында кире кайта. Бу чибәркәйләр көнбагыш ярата, җиләк, бөртек белән туклана.

Кызылтүшләр ояларын ылыслы һәм катнаш урманнарда ясый, бигрәк тә чыршылы, елгадан ерак булмаган җирләрне ярата.

Эколог. Россиядә кызылтүшләрнең 3 төре яши: Көнчыгыш Европа төре, Кавказдагы һәм Камчаткадагы гади төрләре. Аларны башка илләрдә дә, мәсәлән: Пиреней ярымутравында, Эльбрус тавында, Иранда, Италиядә, Германиядә, Франциядә һәм Европаның башка илләрендә очратып була.

Алып баручы. Иң матур сайраулары белән безне нинди кошлар җәлеп итә? Әйе, сандугач. Алар турында бик күп шигырьләр, җырлар иҗат ителгән. Аларның тавышы һәркемне гәҗәпкә калдыра.

Галим. Сандугачлар Европа һәм Көнбатыш Азиядә яши. Алар күчмә кошлар, Африкада кышлыйлар. Бу кошлар елга тугайларында, куаклыкларда яши. Ояларын җиргә якын урыннарга кора, 4-6 йомырка сала. Балалары 13 көндә чыга. Бөҗәк, үрмәкүч, аерым очракларда җиләк-җимеш белән дә тукланалар.

Алып баручы. Табигатьтә кошлар бик күп. Ләкин кышны безнең белән үткәрүчеләре сирәк. Шулар

арасыннан песнәк. Песнәкнең тормышы белән танышканчы, аның да тавышын тыңлап китегез. *(Песнәк тавышы.)*

Галим. Песнәк урман һәм парклларда яши. Ул кеше яшәгән урыннарга тиз ияләнә. Авыл тирәсендә еш очрый. Бу кошларны кыш көне, җимлекләр куеп, йортлар тирәсенә дә ияләндерергә була. Алар кыска вакыт эчендә кулдан да җим алырга өйрәнә. Ояларын төрле урыннарга кора, 9-13 йомырка сала. Балалары 13 көннән чыга, ә 15 көннән ояларын калдырып оча башлый. Песнәкләр Россиянең Европа өлешендә, Азиянең көньяк өлешендә, Кавказда яши.

Алып баручы. Очрашуда тагын бер яз кошының тавышын тыңлап, аның турында сөйләшмәсәк, ул безгә үпкәләр. *(Карлыгач тавышы.)* Карлыгач – бик тырыш кош. Балаларын ашату өчен тәүлегенә 3000 гә якын бөҗәк ташый. Шул хезмәте белән ул бакчачыларга бик зур файда китерә. Шуңа күрә бу кошларны йорт тирәсенә ияләндерергә кирәк.

Ә хәзер кошлар тавышын тану буенча бәйге оештырабыз.

(Балалар кабаттан кошлар тавышын тыңлый, төгәл җавап бирүчеләр бүләкләнә.)

Очрашу Шәйхи Маннурның «Хуш килдегез, кошлар» шигыре белән тәмамлана.

II БҮЛЕК. ТАБИГАТЬ. ЭКОЛОГИЯ.

ТУГАН ЯГЫМ – ЯШЕЛ БИШЕК

Зирәкләр һәм тапкырлар кичәсе *(Экология елына багышланган сыйныфтан тыш чара)*

Зөлфия БИКЧУРОВА,
Чүпрәле районы Иске Шәйморза урта мәктәбе укытучысы

Кичә барышы

Укытучы. Россия Президенты В.В.Путин 2017 елны Экология елы дип игълан итте. Ә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов «2017 ел – Татарстанда Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елы» дип расланган фәрманга имза салды. Бүгенге сыйныфтан тыш чарабыз Экология елына багышлана.

Беренче укучы.

Һәр көн саен хәерле көн телим,
Аяз көннәр телим илемә.
Биек күкләр телим бөркетләргә
Һәм иминлек телим илемә.
Хәерле көн димен һәр бөркеткә,
Кояшлы көн телим гөлләргә.
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Һәм сабырлык телим ирләргә.
Юлчыларга хәерле юл телим.

Икенче укучы.

Чәчәкләргә карап елмаям.
Һәрбер кеше якын кардәш сыман,
Үз балам күк һәр бала.
Шуңа күрә, хәерле көн телим
Таңнар туган саен җиремә.
Аяз көннәр телим һәммәгезгә
Һәм иминлек телим илемә.

Укытучы. Менә шулай дип яза шагыйрь Фирая Зыятдинова. Табигатьне өйрәнү, саклау юлларын табар өчен без бүген кечкенә генә сәяхәткә чыгарбыз. Юлда тукталышлар ясарбыз, яңалыклар күрербез, табигать турындагы белемнәребезне арттырырбыз. Сәяхәт вакытында узебезгә юлдаш итеп әдәпләлеккә өйрәтүче табигать-ананы, дуслык-

ны, тапкырлыкны, җырны алырбыз. Алар белән юлыбыз тиз һәм күңелле узар. Сәяхәтебез су буйлап булыр. Көймәгә утырыр алдыннан бер мәкальне искә төшерик әле: «Юлга чыксаң, иптәшең үзеңнән яхшырак булсын». Ә чын иптәш, укучылар, нинди була икән соң?

Беренче укучы. (Хәкимҗан Халиковның «Эшләпәле дуслар» шигыреннән өзек).

Дуслар белән дус булганга
Шатлан син, шатлан син.
Юха белән дус булудан
Саклан син, саклан син.
Карама син теленә, теленә,
Дус бит юлда беленә, беленә.
Дустың булсын берне бишкә
Бүләрлек, бүләрлек,
Синең өчен аягүрә
Үләрлек, үләрлек.

Укытучы. Без дә, дусларым, сезнең белән дус булыйк. Шатлыкны да, кайгы булганда, кайгыны да уртаклашып яшик

(«Уртаклаш кешенең кайгысын» җыры башкарыла.)

Сәяхәтебезнең беренче туктalышы – «Елга». *(Зирәкләр һәм тапкырлар командаларына сораулар презентация слайдында чыга.)*

Нәрсә ул елга?

Нәрсә ул күл?

Татарстанда нинди елгалар бар?

Безнең район биләмәләрендә нинди сулыклар бар?

Татарстан сулыкларында нинди балыклар яши?

Безнең елга-күлләребез нинди хәлдә?

Укытучы. Балыкларның зарланганын ишеткәнегез бармы? Шигырь тыңлап китик әле.

Икенче укучы.

Без яшәгән илләрдә:
Елгаларда, күлләрдә,
Су асты катларында,
Бормалы чатларында,
Мүкләрдә һәм ләмнәрдә,
Каян килгән нәрсәләр бу:
Галошлар, итекләр,
Күгәргән үтүкләр,
Кәчтерүл-чиләкләр,
Иләкләр-көрәкләр,
Буяулар, цементлар,
Ташландык уенчыклар,
Кирпечләр, ярчыклар,
Целлофан капчыклар.
Болар безнең су иленә
Каян килгән?
Нигә килгән?

Укытучы. *(Сораулар бирүне дәвам итә.)*

Каян килгән бу ташландыклар?

Нинди чаралар күрергә кирәк?

(Җавапларга очко куела бара. «Ага чишмә» җыры (Ф.Мортазин көе, С.Хәким сүзләренә) башкарыла.)

Сәяхәтебезнең икенче туктalышы – «Урман».

Нинди агачлар беләсез?

Урман – кешенең иң якын дусты дибез. Ул кешегә ни өчен кирәк соң?

(Укучылар җавап бирә. Һәр җавап өчен 1 очко куела.)

Укытучы. Урман – безнең байлыгыбыз. Шуңа күрә ул байлыкны кадерләп сакларга кирәк. Ә урманны ничек саклап була, моның өчен урманга баргач ниләр эшләү тыела?

(Җавап бирүчегә 1 очко куела.)

«Агачлар бәхәсе» бәйгесен башлыйбыз. Командалар һәрберсе бер агач рәсемен сайлап алырга һәм аның иң кирәкле агач икәнен дәлилләргә тиеш.

(Вахит Монасыйпның «Шифалы табиблар» дигән әсәреннән сәхнәләштерелгән күренеш тәкъдим ителә.).

Табигать ана. Ромашка, ромашка! Кая болай чабасың?

Ромашка. Чапмый хәлем юк! Гыйлаҗ бабайга салкын тигән, тамагы авырткан, шуны дәваларга барам.

Табигать ана. Әрем-Әрем! Кая болай йөгерәсең?

Әрем. Йөгерми хәлем юк! Сәрби әбинең ашказаны бозылган. Шуны төзәтергә йөгерәм.

Табигать ана. Энҗе, энҗекәй! Тукта әле, кая болай чабасың?

Энҗе чәчәк (Ландыш). Гафу, гафу! Туктап торырга вакытым юк. Мөнәвәрә апаның нервлары какшаган, шуларны дәваларга ашыгам.

Табигать ана. Бака яфрагы! Бака яфрагы!

Бака яфрагы. Соңыннан, соңыннан! Вакытым юк. Хәйрүш абыйның күзенә арпа чыккан. Шуны дәваларга кирәк!

Табигать ана. Кычыткан, кычыткан! Ә син кая?

Кычыткан. Искәндәр дигән малай янына, арт сабагын укытырга. Бүген тагын «2»ле эләктергән.

Димәк, укучылар, кычытканның да файдасы күп икән. Ул эләктермәсен өчен «2»ле алмаска кирәк.

Укытучы. Чиратта – «Яшь каләмчеләр» бәйгесе. Урманда үсемлекләр генә түгел, хайваннар да бик күп. Командалар берәр кош яки хайван рәсемен ала да, көндәшенә күрсәтмичә, 3 минут дәвамында хикәя төзи, ләкин исемен атамый. Ә каршы як команда кешесе, бу хайванны яки кошны танып, исемен әйтергә тиеш. *(Тукран, карга, бүре, куян)*.

Өченче туктalыш – «Мәкальләр һәм әйтемнәр утравы».

Бу утрауга керер өчен без мәкальләр һәм әйтемнәр белергә тиеш. Әйдәгез, бу мәкальләрнең башын слайдта укыйк, ә ахырын сез әйтә барасыз. Һәр җавап өчен командага 1 очко.

Аерылганны аю ашар, … *(бүленгәнне бүре ашар.)*

Ашыккан… *(ашка пешкән.)*

Сәламәт тәндә – *(сәламәт акыл.)*

Бәйрәм ашы… *(кара-каршы.)*

Агач җимеше белән, … *(кеше эше белән матур.)*

Саф һава… *(тәнгә дәва.)*

Ипи-тоз –… *(якты йөз.)*

Кош канаты белән, … *(кеше дуслары белән көчле)*.

Күз өчен яз яхшы, … *(авыз өчен көз яхшы.)*

Белмәү гаеп түгел,… *(белергә теләмәү гаеп.)*

Зур урманда карга булганчы, ... *(бәләкәй куакта былбыл булсаңчы.)*

Алдан кычкырган кәккүкнең... *(башы таз булыр.)*

(«Кошкайлар» җыры (У.Рәшитов көе, Р.Миңнуллин сүзләре) башкарыла.)

Менә без сезнең белән утрауга аяк бастык, әйдәгез, хәзер бераз уйнап алыйк.

«Яшь рәссамнар» бәйгесендә катнашу өчен һәр командадан берәр уенчы чыга һәм, күз бәйләп, табигать күренеше рәсемен ясый.

Тамашачылар белән «Сорау-җавап» уенын уйныйбыз.

Табигатьтә иң нечкә җеп? (*Пәрәвез чәчтән 1000 тапкыр нәзегрәк.)*

Бал корты чаккач үлә. Ни өчен? *(ук тәндә калгач, үз җәрәхәтеннән үлә.*)

Ни өчен кыш көне чыпчыклар һәм вак кошлар каурыйларын тырпайта? *(Тырпайган каурыйлар арасында һава күп була һәм җылылык аз югала.)*

Нинди хайваннарның йоклаганда күзләре ачык? *(Еланнар, балыклар.)*

Бакаларның файдасы нидә? *(Корткыч бөҗәкләрне юк итәләр.)*

Дүртенче тукталыш – «Табышмаклар илендә».

Башы тауда, аягы диңгездә. *(Елга)*

Кыш буена тик тора, яз җиттеме – котыра. *(Елга)*

Аты юк, тәртәсе юк, көне-төне бара, юлы кала. *(Чишмә)*

Бертуктаусыз көн-төн ага, бөтен кеше рәхмәт әйтә аңа. (*Чишмә)*

Укытучы. Табышмакларның җаваплары барысы бергә нәрсәне аңлата? *(Укучылар җаваплары тыңлана.)*

Сулыкларны саклау – безнең бурычыбыз.

Бишенче тукталыш – «Табигать кочагында».

Командалар өй эше итеп бирелгән «Табигать кочагында» дип аталган сәхнәләштерелгән тамаша күрсәтә.

Укытучы. Кешене туендыручы, киендерүче, суларга һава, сусаганда су биргән Табигать-ана бүген ярдәм көтә. Аның киләчәге безнең кулда.

Димәк:

елга-сулыкларны пычратмаска;

чәчәкләрне өзмәскә;

кошларны рәнҗетмәскә;

яшеллекне, табигатьне сакларга кирәк!

(«Җәйге ямьле иртәдә» җыры башкарыла.)

Укытучы. Без – табигать балалары, ә табигать – безнең хуҗабыз! Дусларым, әйдәгез барыбыз бергә табигатьне саклыйк. Бездән соң килүче буынга сулары быз чиста, һавабыз саф, урманнарыбыз яшел килеш саклансын. Табигатьне саклау – һәрберебезнең изге бурычы.

II БҮЛЕК. ТАБИГАТЬ. ЭКОЛОГИЯ.

УРМАН БӘЙРӘМЕ

Сиринә ХӘМИДУЛЛИНА,
Бөгелмә районы Зеленая Роща-Наратлы
мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Чара барышы

(Үткәрү урыны – урман.)

Алып баручы. Исәнмесез, укучылар, укытучылар һәм кадерле кунаклар! Хәерле көн!

Безнең мәктәп тәрбия эшләрен «Бөгелмә ягын могҗизага төргән иҗат көче әле саекмас» концепциясе буенча алып бара. 9-11 нче сыйныф укучылары бу концепцияне тормышка ашырганда «Шаулагыз, имәннәр!» дигән юнәлеш буенча эшләде. Алар ел дәвамында Бөгелмәнең атаклы урманчылары – Николай Фирсов, Әмир Галиев, Идрис Шәфиев, Алексей Вакатов, Наил Нәсыйбуллин турында мәгълүмат җыйдылар. Бүген без «Урман бәйрәме»нә җыелдык. Ул иҗади алан рәвешендә үтәчәк, биредә атаклы урманчылар да катнаша.

«Кышкы урман» аланы. Безнең халкыбыз элек-электән табигать белән дустанә яшәгән, аңа хөрмәт белән караган.

«Язгы урман» аланы. Кеше үзенең табигатьтән бәйле икәнен һәрчак тоеп-белеп торган, аның кануннарына буйсынган.

«Җәйге урман» аланы. Нократ, Чулман, Идел буйларында яшәгән борынгы бабаларыбыз каенны изге агачларның берсе итеп санаган.

«Көзге урман» аланы. Көзге урманда халкыбыз «моң», «сагыш»-ны күрсә, язгы, җәйгеләре «яшәү», «яшьлек» билгеләрен аңлаткан.

(Бөгелмәнең табигате, урман байлыклары, тереклеге турында презентация күрсәтелә.)

1 нче алан. Чәчәкләр аланы.

«Карт имәннәр салмак кына шаулый. Җил имән очларына кагыла. Имән – тарихчы ул. Имән – урманның тарих укытучысы. Юкә, каен, миләш – җыр, әдәбият, рәсем укытучылары. Өрәңге кем? Белмәссең. Ихтимал, ул – физиктыр. Каты, конкрет, төгәл, хисләр белән исәпләшми. Имән – тарихчы, монысы, бәхәссез!» (*«Шаулагыз, имәннәр».*)

Әсәрнең авторы кем?

1	2	3
М. Мәһдиев	Ш. Камал	һ. Такташ

2. Урманны җирнең **нәрсәсе** дип йөртәләр?

1	2	3
йөзләре	күзләре	***үпкәләре***

3. Нарат **күпме** яши?

1	2	3
100 ел	***300 ел***	70 ел

2 нче алан. *(Урманнарны саклауга багышлана. Милли киемнәр кигән кызлар-егетләр зифа каенны уртада калдырып әйләнә. З.Ярмәки сүзләренә «Ак каен» җыры башкарыла.)*

1 нче укучы. Чыннан да, җырдан күренгәнчә, борынгыда ***Урман*** бәйрәме булган: яшьләр ***Урманга*** үзләренең бүләкләрен алып килгән һәм теләк-үтенечләрен дә ***Урманга*** җиткергән.

2 нче укучы. Без дә үзебенең ***Урман*** бәйрәмен дәвам итик. Зифа ***Урманны*** яшәрүе белән котлап, дөньяга иминлек, җиһанга сәламәтлек телик. Аклык-сафлык, яшьлек билгесе – Каенсылуның яшел күлмәген тагын да күркәмрәк итик.

(Укучылар, биремнәрне үтәгәч, сорауларга җаваплар язылган яфракларны агачка элә.)

Биремнәр – сораулар *(мисал өчен.)*

1. Яшел шәлен ураган, үзе кигән ап-ак тун;
Үзе бөдрә – чәче юк, ул нәрсә? *(Каен)*

2. Бөгелмәдә чишмәләрне барлау, яңарту эшләре алып барыламы? Кемнәр катнаша? Яңартылган чишмәләрнең исемнәрен әйтегез. *(Изгеләр чишмәсе, Нур, Кече Бөгелмә чишмәләре)*

3. Урман санитарлары – кырмыскаларның ояларын саклау һәм күбәйтү эшләрендә ничек катнашасыз? *(Ояларны туздырмау, күчереп утырту.)*

4. Урманда үсә торган гөмбәләрнең төзелеше һәм үсеше турында гадәти булмаган кызыклы мәгълүмат бирү. *(Нинди шартларда, нинди туфракта, кайсы агач төбендә үсә)*

Гөмбәләрнең ниндиен, кайда, кайчан, көннең кайсы вакытында, нинди савытка җыярга кирәклеген төшендерү. Гөмбәчеләр куллана торган кагыйдәләр белән таныштыру. Гөмбәләрнең кайбер төрләре Кызыл китапка кергән.

3 нче алан. Матурлык аланы

1 нче укучы. Иртә язда караманы кара син. Ул бу вакытта яшь кызлардай үрсәләнә, берәү дә көтмәгәндә, уйламаганда, әле һавада кар сулышы да басылмаганда, ялангач ботакларына яшел чәчәкләрен тезеп куя. Нинди матурлык үзендә, нинди хуш ис! Шунысы гаҗәп, ул

яшел чәчәкләр һичберкемнең күңелен җәлеп итмичә чайкалып торалар да бердәнбер көнне коелалар. Тик аннары гына ботакларда барлыкка килгән калын, кытыршы яфраклар, урман авазына кушылып шыпырдаша башлыйлар.

Язгы ашкынуына, ялгышына үкенә булса кирәк карама. Көзге якта инде ул, уйланып, барын да үлчәп бизәнә. Урман юлыннан барганда, синең алдыңа чәчәк бәйләме кебек килеп баса. Шушы чибәркәйне, бөтен агачлардан аерып, ап-ачык итеп күрәсең. Кытыршы яфраклары күз явын алырдай булып аллана, кызыл кучкылга әйләнеп яна. Бу кадәр матур төсләрне кайдан ала, ничек итеп башка агачлардан алдарак бизәнеп өлгерә икән ул!

2 нче укучы. Дөньяда тау кадәр алтын белән дә бәяләп бетерә алмаслык нәрсәләр була. Ил матди байлыкка карап кына куәтле була алмый, аның куәте халыкның рухына, күңеленә бәйле. Халыкның рухы нихәтле хөр һәм күтәренке булса, дәүләт тә шулхәтле көчлерәк һәм санлырак була. Ә халыкны сәламәт рухлы итеп, киң күңелле итеп менә шушы гүзәл табигатьтән гайре нәрсә тәрбияли ала? Кеше баласы дөньяда ничек кадерле булса, табигать үзе дә шулай кадерле булырга тиеш. Аны мәсхәрә итсәк, киләчәк буын безне беркайчан да кичермәс, чөнки киләчәк буынның да табигатьтән файдаланырга хакы бар.

Алып баручы. Уенның бу өлешенә йомгак ясыйбыз: йолдызлар саны иң аз булган уенчы алга чыга. «Уенда катнашуың өчен рәхмәт».*(Аңа бер тубал миләш бүләк ителә.)* Ул каен агачы утырта. Үзе дә шул каенлыкка күчә. «Ромашка тажы» дигән уен әзерли.

4 нче алан. Музыкаль алан

1. Хәзер сезгә бер музыкаль әсәр тәкъдим ителә. Бу маршны кем язган? Маршның исемен дә әйтә алсагыз, өстәмә йолдыз бирелә. (Совет Армиясе маршы.)

1	2	3
А. Ключарев	Ж. Фәйзи	***С. Сәйдәшев***

2. Хәзер берничә көй уйнала, аларны белгән кешегә йолдыз бирелә. *(Баянчы берничә көйнең башлангыч ноталарын уйный.)*

Йолдызлары аз булган тагын бер уенчы белән сөйләшәбез. Аңа, уен истәлеге итеп, бер тубал балан бирелә. Ул да агач утырта. Умырзая аланы рәсемен ясый. Урманчы иң төгәл җавап бирүчегә, бүләк итеп, бер савыт юкә балы тапшыра.

(«Шаулый Урман» җыры (Р. Андреев көе, Г. Зәйнашева сүзләре) башкарыла.)

5 нче алан. Татарстанның рәссамнарына багышлана.

1. Портретларда республиканың атаклы рәссамнары дөрес тәртиптә урнашканмы? (*Иван Иванович Шишкин, 1832-1898*).

1
Шишкин

2
Урманче

3
Зарипов

Уенның бу этабы нәтиҗәләре буенча тагын бер укучы белән сөйләшеп, аңа бүләк тапшырыла. Аз йолдызлы уенчы нарат агачы утырта. Наратлык – батырлык аланы үстерәбез. Урманчы иң төгәл җавап бирүчегә бүләк бирә.

6 нчы алан. С. Хәмидуллинаның бер шигырен уку:

1. «**Кышкы урман» шигъри аланы;**
2. **«Язгы урман» шигъри аланы;**
3. **«Җәйге урман» шигъри аланы;**
4. **«Көзге урман» шигъри аланы.**

Арлы-бирле йөргәнем бар
Матурлыгыңа сокланып,
Назлы җил искән чагында,
Торганым бар, тыңланып.

Зифа каен, иркә юкә,
Сәламли мине имән.
Өрәңгеләр шаулап дәшә:
Без исән, әлегә исән.

Урман – безнең яшәеш,
Урман йорт-җир. Урман кием.
Сакла аны, үрчет аны
Һәм саф һавага тиен.

Килдең безгә, үттең түргә.
Бәйрәм иттең, җилкенеп.
Чүп-чарыңны күмеп калдыр,
Ятмасын тузып, череп.

Чишмә кибәр, сөрем сарыр,
Урман булмаса әгәр,
Җәен, көзен, кышын, язын –
Сөендерергә әзер.

7 нче алан.
Урман – кешенең якын дусты.
Әдәби алан

1. «Урманны кем генә яратмый икән?! Мөгаен, андый кеше юктыр. Ә шагыйрьләр, язучылар өчен урман – илһам чыганагы. Габдулла Тукайның Кырлай урманнары турында язганнары һәммәбезнең хәтерендә саклана. Без дә урманны бик яратабыз. Аның гүзәллеген, ямен мактарга берсеннән-берсе матур сүзләр эзлибез.

Матурлыгы, табигатькә ямь бирүе өстенә урманның файдасы да бик күп. Ул без сулый торган һаваны сафландыра, тузаннан чистарта. Шуңа күрә дә урманның һавасы һәрвакыт саф була.

Яз һәм җәйләрен урманнарда нинди генә кошлар сайрамый! Дару үләннәренең дә бик күбесе шунда үсә. Башта урман кешеләргә тәмле-тәмле җиләкләрен бүләк итә. Соңга таба гөмбәчеләрне үзенә чакыра.

Урмандагы һәр агач табигатькә үзенә бер ямь биреп тора. Аларның файдасы да төрлечә. Мисалга бөдрә яфраклы ак каенны алыйк. Аның суы кешеләрне ревматизм авыруыннан дәвалый. Май аенда җыйналган яфрагын чәй итеп эчү бавыр, бөер һәм эчәкләргә шифа була. Мунча яратучылар да каенга рәхмәт әйтәләр. Ә аның буй-сыны нинди тагын!

Урман матур да, файдалы да. Аны сакларга кирәк!»

Өзекнең авторы кем? Әсәрнең исеме – «Урман – кешенең якын дусты».

1	2	3
И. Гәрәй	Ф. Кәрим	Г. Камал

2. «Безнең якларда санап бетергесез канатлы җырчылар яши. Иртә язда урман-кырларга чыксаң, әйләнеп кайтасың килми. Әйтерсең урманда җыр ярышы ачканнар.

Урман тургае бик иртә кайта. Кыш әле калын тунын салмаган, ә тургай, яз киләсен тоеп, чишмәдәй челтери. Аңа кушылып, урман ешлыгыннан башка тургайлар аваз бирә. Урман тургаеның төсе-кыяфәте сабан тургаена охшаган. Тик гәүдәгә аннан бераз кечерәк, ә башында коңгырт түбәтәе бар.

Җәйге көндә урман тургаен агач башында күреп булмый. Ул ак болытлар янында, зәңгәр күктә табигатькә мактау җырлый: лү-лү-лү-лү... Ул шушы җырын суза да суза. Якты йолдызлар гүя аның җырыннан кабына. Гаҗәп йомшак, искиткеч саф тавышы тын урманда кош балаларына бишек җыры булып яңгырый. Бу яктан ул мәшһүр сандугачка тартым.

Урман тургае көзге салкында да туктамый. Сабан тургайлары киткәч тә, ул безнең як урманнарын ташламый, җырлый да җырлый. Күктә ап-ак кар бөртекләре оча башлагач кына, ерак сәяхәткә кузгала».

Өзекнең авторы кем? Әсәрнең исеме «Урман тургае».

1	2	3
М. Җәлил	***Г. Хәсәнов***	Т. Гыйззәт

3. «Безнең авылга якын гына зур гына бер урман бар. Авыл кешеләре аны Югары урман, Кәҗүнни урманы дип йөртәләр. Җәен кызарып кояш батканда, ул урманның һичбер яфрагын да селкетмичә, тын гына нәрсә турындадыр уйлаганын карау бик тә күңелле була.

Мин ул урманга баргалаганым бар. Аның кырыйларында чикләвек, миләш, шомырт шикелле куаклар гына үсә, эчкә киткән саен алар арасында каен, өрәңге, карама шикелле эрерәк агачлар да күренә башлый. Алар арасыннан озын, таза имән агачлары үзләренең калын ботаклары белән әле анда, әле монда күккә сузылалар.

Без абый белән күп вакыт анда Сәхип әби дигән карчыкка ияреп бара идек. Сәхип әби инде тәмам картайган. Ул инде колакка да катыланган».

Өзекнең авторы кем? Әсәрнең исеме – «Югары урманга җиләккә бару».

1	2	3
С. Җәлал	Ә. Бикчәнтәева	Г. Әпсәләмов

4. «Урман – урман инде, бер менгәч, кармак сабы белән генә чикләнеп калып буламыни?! Уйный-уйный әллә кайларга барып чыктык, шундый иркен, тыныч урманны ташлап кире кайтасы киләме соң?! Төрлебез төрле якка сибелеп, җиләк эзли башладык.

Кинәт бөтен урманны сискәндереп, якында гына чырылдавык тавыш яңгырады. Наил тавышы:

– Җыла-ан! Җылан!

Бер мизгелгә катып калган аякларны көч-хәл белән урыннарыннан кузгатып, куак артларына поса-поса, шул якка атладык.

Чү, әллә куркуыннан җиңеләя башлады бу Гаяз? Бөтенебездән алда еланга таба туп-туры бара бит.

– Әй, җүләрләр, – ди үзе, – җыланмыни, тузбаш ич бу!

Малайлар, бертавыштан «ах» итеп, авызларын ачтылар. Гаяз еланның янына ук барып җитте. Кулы белән сыртыннан сыйпый түгелме соң?..

Безнең күзләр маңгайга менгән, авыз ачылмый да, ябылмый да. Бары тик Наил генә, йөрәге җитеп:

– Гаяз! Куркак Гаяз! Нишлисең, чага бит! – дип кычкырып җибәрде».

Өзекнең авторы кем? Әсәрнең исеме – «Куркак Гаяз».

1	2	3
Р. Мөхәммәдиев	Г. Ибраһимов	Г. Ахунов

8 нче алан. ФИНАЛ. Уеныбызның бәхетле мизгеле якынлаша. Бу аланда уенчылар беренче һәм икенче урыннар өчен көч сынаша.

1. **«Кышкы урман» аланы экологик әкият яза.**
2. **«Язгы урман» аланы «Урман һәм кеше» плакаты ясый.**
3. **«Җәйге урман» аланы шигырь яза.**
4. **«Көзге урман» аланы җыр яза.**

(Урыннар билгеләү. Нәтиҗә ясау. Бүләкләү. Бергәләшеп каен, имән, нарат агачлары утырту. Каенлык, имәнлек, наратлык үстерү.)

III БҮЛЕК. ГОРЕФ-ГАДӘТ. ЙОЛА.

БЕЗДӘ БҮГЕН Э

(Татар халкының җыен бәйрәме)

Гөлфия ВИЛДАНОВА,
Арча районы Яңа Кенәр
балалар иҗат йорты педагогы

(Авыл тирәсендәге су буе. Авылның яше-карты, бала-чагасы эш белән мәшгуль. Берәүләр киртә ташый, кунакларны сыйлау өчен урын хәстәрли, берәүләр мәйданга савыт-саба, ашамлык алып чыга, утын кисә, кемнәрдер өстәл әзерли. Авыл малайлары өчен бу көн икеләтә бәйрәм: үзләренең аерылмас дуслары – этләр белән чаба-йөгерә, гөрләшә-гөрләшә, өлкәннәргә булышалар. Шулвакыт бер малай: «Киләләр!» – дип кычкыра.)

Кунаклар.
Әй, Әпсәләм, Әпсәләм!
Сәлам бирдек – әссәлам!
Сездән безгә тиештер бит –
Хуҗалар.
Вәгаләйкемәссәлам!
Хуш киләсез, узыгыз,
Түрдән рәхим итегез!
Бездә бүген зур бәйрәм,
Бездә бүген зур җыен.

Илгиз бабай. Кечегә шәфкать итеп юл бир, олыга хөрмәт итеп кул бир дигәннәр. Әйбәт кенә килдегезме, кунаклар! Әйдәгез, күрешеп алыйк әле!

Кунаклар. Бик әйбәт килдек, күршеләр.

Кәрим. Әйдә әле, Фазыл бабай, берне җырлап әйт әле!

(Фазыл «Авыл көе»нең беренче куплетын башкара, икенче куплетын кунаклар ягыннан дәвам итәләр.)

Кәрим. Әйдәгез, юлда арып килгәнсездер, ял итеп, тамак ялгап алыйк. Ашның бәрәкәте – кунак белән дигәннәр бит. Ә аннан соң күңел ачып алырбыз.

(Табынга утыралар.)

ЗУР ҖЫЕН

Фазыл бабай. Куышыбыз тар, сыебыз аз булса да, сезнең өчен, хөрмәтле кунаклар, күңелебез киң.

Зөлфия.

Әйдәгез, түрдән узыгыз,
Бездә кунак булыгыз.
Изгелекле, мәрхәмәтле
Булсын йөргән юлыгыз.

Илүзә. Безнең борынгы бабаларыбыз иген иккәннәр, чыпта сукканнар, күп итеп хайван асраганнар. Иген игү, хайван асрау белән халкыбыз әле дә бик теләп шөгыльләнә. Һава торышы гына әйбәт булсын инде.

Алмаз бабай. «Кышын кар күп булса – иген яхшы уңар», – дигәннәр борынгы бабаларыбыз. Быел да кар бик мул булды, игеннәр әйбәт булыр, Алла боерса.

Фазыл бабай. Ашап бетердекме барыбыз да? Ягез, ашка бер дога кылыйк. *(Дога кылалар.)* Кадерле кунаклар, әйдәгез, бәйрәмебезне башлап җибәрик.

Зөһрә. Такмаклар әйтешәбез!

(*Кара-каршы такмаклар әйтешеп җырлыйлар.)*

Без җырлыйбыз шаян җырлар,
Ә сез тыңлап торыгыз.
«Әнә килә автомобиль»
Булыр безнең җырыбыз.
Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк?
Сезнең алда җырлар өчен
Сандугач теле кирәк.
Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Җыр капчыгым ертылган;
Кичә бер җыр откан идем,
Ул да булса онытылган.
Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле берәрне.

Җырлап искә төшерербез
Бергә булган көннәрне.
Рүзилә. Бию ярышы!
(Кызлар биеп ярыша.)
Илүзә. «Ша» уены!
Зөлфия. Үзем саныйм!
Чар, чар чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.
(Яшьләр пар-пар булып түгәрәкләнеп баса. Уртада бер парсыз кеше кала. Ул түгәрәк буйлап гармун көенә биеп китә. Урта ягында, беренче рәттә торучылар да түгәрәк буенча аның артыннан биеп китәләр. Гармунчы үзе теләгән вакытта «Ша» дип әйтүгә, биючеләр борылып кире якка таба биеп китәләр. Бераз икенче якка биегәч, гармунчы «Ша» дип әйтә, һәркем үзенең беренче пары каршына басарга тырыша. Парсыз калган кешегә җәза бирелә.)
Алмаз бабай. Таяк тартышу ярышы!
(Таяк тартышалар.)
Фазыл бабай. «Наза» уены!
Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән,
«Наза» дигән уенны без
Уйныйбыз чын күңелдән.
Кушымта:
Наза, наза,
Наза матур кыз бала.
Наза тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бала.
Рәмзия. Әйдәгез, җыр ярышы үткәрәбез!
(Кызлар-егетләр җырлап ярыша.)
Данис. Дуслар, көрәшсез бәйрәм төссез булыр кебек. Әйдәгез көрәшеп тә алыгыз әле!
(Көрәшәләр.)
Раилә. Бүгенгә бәйрәмне тәмамлап «Челтәр элдем читәнгә» уенын уйныйк.
Ал алъяпкыч челтәрле, илдә матур бетәрме?
Илдә матурлар бетәрме, җан сөйгәнгә җитәрме?
Кызлар.
Челтәр элдем читәнгә, җилфер-җилфер итәргә;

Егетләр.
Без килмәдек буш китәргә, кил-
дек алып китәргә.
Кызлар.
Алын алырсыз микән, гөлен
алырсыз микән?
Урталарга чыгып сайлап кемне
алырсыз икән?
Егетләр.
Алларын да алырбыз, гөлләрен дә
алырбыз;
Күңелебезгә кем ошаса, шуны
сайлап алырбыз.
Кәрим.
Әй, дусларым, дусларым, дусла-
рым, бәгырьләрем;
Яшь гомерләр ике килми, белегез
кадерләрен.
Кызлар.
Челтәр элдем читәнгә, җил-
фер-җилфер итәргә;
Егетләр.
Без килмәдек буш китәргә, кил-
дек алып китәргә.
Кызлар.
Ак алъяпкыч билләрдә, җил-
фердәми җилләрдә;
Сандугачлар да сайрамый сез
булмаган җирләрдә.
Кызлар.
Челтәр элдем читәнгә, җил-
фер-җилфер итәргә;
Егетләр.
Без килмәдек буш китәргә, кил-
дек алып китәргә.
Кызлар.
Алай да бергә-бергә, болай да
бергә-бергә;
Егетләр.
Дуслар белән бергә булсаң, күгәрчен кебек гөрлә.
Бергә.
Алларын да алырбыз, гөлләрен дә
алырбыз;
Күңелебезгә кем ошаса, шуны
сайлап алырбыз.
Зөһрә:
Дуслык җебе өзелмәс ул,
Моңлы халык бар җирдә.
Безнең шушы очрашу
Истә калыр гомергә.
(«Баламишкин» җырын башкаралар.)

III БҮЛЕК. ГОРЕФ-ГАДӘТ. ЙОЛА.

ҖИДЕ БАБАҢНЫ БЕЛ!

(Татар теле һәм әдәбияты атналыгы кысаларында үткәрелә торган сыйныфтан тыш чара)

Гүзәлия БӘДРЕТДИНОВА,
Балык Бистәсе районы Корноухово төп мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Чара барышы

Факиһә. Йә, Алла, бу дөнья мәшәкате. Эштән кайтасың, ашарга пешерәсең, мал-туар карыйсың, балаларга вакыт та калмый. Менә бүген дә мәктәпкә дәшеп кәгазь алдык. Гаилә бәйрәменә чакырганнар. Хәбиб! Хәбиб дим!

Хәбиб. Куркыттың бит! Нигә шулкадәр кычкырасың? Талыйлар дип торам.

Факиһә. Хәбибем-наным, әйдә, без дә барыйк әле Гаилә бәйрәменә.

Хәбиб. Юк-юк, бармыйм. Бүген «Нежный яд», «Адашкан мәхәббәт», «Новости». Юк-юк, кыстама да, үпкәләмә дә.

Факиһә. Хәбиб дим, барыйк инде. Нуруллалар да була, Айдарлар да килә. Барыйк инде, ә?

Хәбиб. Алай булса, барабыз, анасы, барабыз. Тик өскә нәрсә киябез?

Факиһә. Мин ак яулыгымны япсам, син түбәтәеңне кисәң, бер дигән булырбыз? Әзерләнә тор, мин хәзер.

Хәбиб. Белмим шул, ничек булыр икән? Үземнең дә барасым, шул мәктәпне бер күрәсем килә килүен. Телевизорны калдырып китү дә кызганыч… Алай да минем башкалардан кай җирем ким? Барыйм, күрим. Факиһәнең дә күңеле булыр.

Факиһә. *(Бизәнеп-төзәнеп, киенеп, ясанып керә.)*

Тра-та-там!
Бүген мәктәпкә барам!
Тра-та-там!
Директорларын күрәм!
Хәбиб, җаный, әйдә киттек!

***

Укытучы. Хәерле кич, кадерле балалар, хөрмәтле ата-аналар, килгән кунаклар! Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты атналыгы бара. Шул форсаттан файдаланып,

нәсел-нисбәт, ыру-чирү, нәсел шәҗәрәсе кебек барыбыз өчен дә кызыклы темаларга сөйләшеп алырга булдык.

Ата-бабадан, буыннан-буынга күчеп килгән бер мәкаль бар: «Тату туганнар таштан койма ясаган». Дин буенча да, фән буенча да, авыр чакта да, күңелебез бәхеттән ташыганда да без якыннарыбыз, туганнарыбыз, әти-әниләребез янына ашыгабыз. Менә бүген, иң якын кешеләр җыелып, «Гаилә бәйрәме» үткәрергә булдык.

(«Аллага шөкер» җыры (Р.Хәкимов көе, Р.Чурагулов сүзләре) башкарыла.)

1 нче укучы.

Ходай безнең һәммәбезгә җан иңдергән,
Хәтер дигән зирәк акыл, зиһен биргән.
Мәңге уяу күзне галәм үзе әйтер,
Вакыт яшәр, яшәгәндә җирдә Хәтер!

2 нче укучы.

Явызлыкка нокта куйсак кына,
Туар таңның матур, яңасы:
Тормыш тезгенеңне ныклап тотчы,
Егермеберенче гасыр баласы.

3 нче укучы.

Җиребездә шатлыклар күп шөкер,
Бәхетләр күп, шунысы сөенеч.
Күз тимәсен диеп җир шарына
Ай да аны мактап сөйли ич.

Укытучы.

Сөбеханалла, сөбеханалла,
Җир йөзендә күпме бала,
Уйный, көлә һәм шаяра,
Күз тигезмик без аларга.
Авыр димим сине, җинел димим,
Үлчәп булмый сине, замана.
Еллар белән яшьләр картаялар,
Яшьләр белән еллар яңара.

Әйе, бу дөньяда татар атлы халык бар, аның хәтере бар. Башыннан кичкәннәре аның күңеленә уеп язылган, һәм ул язуларны беркем сызып, бетереп ташлый алмас. И, гыйбрәтле язмышка дучар булган халкым, киләчәгеңне сакла, үткәнеңне онытма!

Кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш. Үткәннәрне барлау йөзеннән укучыларга нәсел шәҗәрәләрен төзергә бирем бирелгән иде. Әти-әниләре белән берлектә балалар бу эшне яхшы гына башкарып чыкты. Биредә аеруча уңышлы дип табылган нәсел агачлары урын алды.*(Күргәзмә белән танышу.)* Хәзер алар турында сөйләү өчен авторларның үзләренә сүз бирик.

(Укучыларның чыгышлары тыңлана.)

Кичәбезнең беренче өлеше тәмам. Ә икенчесенә, хөрмәтле әти-әниләр, сезнең ярдәм кирәк. Сәхнәгә 10 уенчы чакырыла. Сезнең өчен 1 нче бирем: бишәр хәрефтән торган команда исемнәрен җыярга («Өлгер», «Җитез» һ.б.)

4 нче укучы.

Туган якның шәһәрләрен,
Елгаларын, күлләрен
Карап карыйк әле бергә
Кемнең күпме белгәнен.
Алфавит хәрефләренә
Исемнәрен табыйк та,
Ярыша-ярыша язып барыйк
Һәм тутырыйк таблица.

Ә без ул арада, тамашачылар, сезнең белән мәкальләр әйтешеп алыйк. *«Мәкальне дәвам ит» уены.*

Ата телен ул ала, … (ана телен кыз ала.)

Ата-анага кадер күрсәткән – (бала-чагадан кадер күрер.)

Туганыңнан бизмә, … (нәселең корыр.)

Кояш янында – җылылык, ана янында –… (изгелек.)

Ата-анасын хурлаган – … (үзен хурлаган булыр.)

Якыныңа ялганыңны әйтмә, … (читкә чыныңны әйтмә.)

Бала өчен ананың йөрәге,… (атаның беләге авырта.)

Эт өреп, егет йөреп, кыз көлеп … (картая.)

Ир кешегә бер елмаеп карасаң,… (кар өстеннән яланаяк йөгерә.)

Ярышны дәвам итәбез. Бу кадәр авыр хезмәттән соң ял итеп алу файдалы булыр.

5 нче укучы.

Халыкларның җаны ул – җыр диләр,
Җыр диләр дә, бездә моң диләр.
Өзгәләсә, телсә бәгырьләрне,
Татар җыры инде шул диләр.

(1 команда җырның 2 юлын җырлый, икенчесе дәвам итә.)

Укытучы. Әти-әниләр балаларының укуы белән һәрдаим кызыксынып тора. Ягез әле, өстәлдәге китаплар арасыннан балагыз укый торган дәреслекләрне табыгыз һәм хәзер үтелә торган материалны күрсәтегез.

Хәзер исә күз алдыгызга шундый күренеш килсен. Кич, ут бетте, ә сезгә тиз генә балагызны киендерергә кирәк. Күзләрне бәйләп, шул эшне башкарып чыгыгыз әле.

Хөрмәтле әти-әниләр, үзегезне бәйрәмдә түгел, ә дәрестә итеп хис итегез. Сезгә икешәр

кәгазь бите бирелә: берсенә бүгенче кичә турында инша язарга, ә икенчесенә берәр әдәби әсәргә багышланган рәсем ясарга кирәк.

Ул арада җанатарлар яраткан командаларына өстәмә баллар бүләк итә ала. Моның өчен түбәндәге өзекләрнең кайсы әсәрләрдән булуын һәм авторларын әйтергә кирәк.

(Һади Такташның «Мокамай», Габдулла Тукайның «Су анасы», Галиәсгар Камалның «Беренче театр», Муса Җәлилнең «Имән», Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Фатих Кәримнең «Пионерка Гөлчәчәккә хат» әсәрләреннән өзекләр укыла.)

Укытучы. Командалар әзер, аларга сүз бирәбез. Жюри нәтиҗә ясаганчы, яңа гына табадан төшкән китаплар белән танышыйк. Укучылар иҗат иткән «Гаилә альбомнары» презентациясенә рәхим итегез.

Жюри нәтиҗәләре буенча 10 номинациядәге дипломнар тапшырыла:

Шәҗәрәсен иң яхшы белүче.
Иң өлгер.
Иң тату.
Иң җитез.
Иң актив.
Иң бердәм.
Иң зирәк.
Иң игътибарлы.
Иң шаян.
Иң тапкыр.

Укытучы.

Беребез дә мәңге түгел,
Бу дөньяда кунак кына.
Бер-беребезгә терәк булып
Яшик гөрләп-җырлап кына.

Бәйрәм кичәсе чәй табыны артында дәвам итә, рәхим итегез!

(Факиһә, башкаларга иярәп, өйдән алып килгән сый-нигъмәтләрне гомуми өстәлгә күчереп куя.)

Хәбиб. Кыстап алып килмәсәң, шундый мәгънәле һәм күңелле бәйрәмне күрми каласы икәнмен! Телевизорың бер якта торып торсын. Рәхмәт сиңа, әнисе! Рәхмәт сезгә, укытучылар һәм балалар!

III БҮЛЕК. ГОРЕФ-ГАДӘТ. ЙОЛА.

ЮГАЛМАС МИРАС

(Әдәби-музыкаль кичә)

Рәйсә ӘХМӘТҖАНОВА,
Мамадыш шәһәренең 1 нче урта мәктәбе
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Кичә барышы

1 нче алып баручы. Кирәкле һәм матур әйберләр кеше күңеленә шатлык китерә, борчу-кайгыларны оныттыра. Матурлык безне кара уйлардан коткара, явызлыктан саклый. Безнең ерак әби-бабаларыбыз да һәрвакыт матурлыкка омтылган, өйләрен зәвык белән бизәгәннәр, ихата-кураларын чиста-пөхтә тотканнар.

2 нче алып баручы. Алар моннан 100-200 ел элек нинди кием кигәннәр соң?

Аякларында – чабата, өсләрендә бәби итәкле күлмәк тә алъяпкыч, башларында калфак та түбәтәй диярсез. Дөрес микән?

(Сәхнәгә татар кызы һәм егете чыгып баса, салмак кына бииләр.)

1 нче алып баручы. Татар халык иҗаты һәм сәнгать әсәрләре әби-бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен күзалларга ярдәм итә. Әйдәгез, ачып җибәрик әле әбиләребезнең борынгы сандыгын. *(Сандыктан алып күрсәтелә.)*

Менә болары бизәнү әйберләре, монысы пәрдә-чаршаулар, сөлгеләр, җәймәләр, тастымаллар, паласлар – нәрсә генә юк монда!

(Татар халык җыры «Гөлҗамал» башкарыла.)

2 нче алып баручы. Кешене киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар. Шуңа күрә өс-баш матурлыгы, пөхтәлеге, чисталыгы да бик әһәмиятле. Татар милли киемнәре – үзе бер гүзәл дөнья. Осталар теккән-чиккән калфак, кәләпүш, түбәтәй, сафьян читек-кәвеш, бәби итәкле күлмәк, бәрхет камзул, камчат бүрек, алтын-көмештән коелган алка, йөзек, беләзек, муенсалар... Әби-бабайлар кием-салымга тәнне каплау, тәнне җылыту чарасы итеп кенә карамаган, ә бәлки аның уңайлы, килешле, күркәм булуына да игътибар иткән.

1 нче алып баручы. Халкыбызның сәнгать әсәренә тиң кием-салымы халык җырларында киң урын алган.

Ак калфакларың ука чук,
Укаларын алсам, яме юк.
Син сылудан башка чибәрләр күп,
Синнән башка торыр хәлем юк.

Укалы калфак... Халык аны элек-электән җырларына керткән.

(Кызлар бии-бии «Сөмбел» җырын башкара.)

2 нче алып баручы.

Ак калфагың чиккән-бөккән.
Ука белән чигелгән.

Ай, Сөмбел, вай, Сөмбел,
Сөйгәнемне үзең бел.

Калфакны барыгызның да күргәне бардыр, мөгаен. Заманына карап модасы гел үзгәреп торган аның. XVIII гасырда ак җептән бәйләнгән 80 сантиметрлы чуклы калфак кигәннәр. XIX гасырда аны 16-20 сантиметр озынлыктагы бәрхет калфак алыштырган. Хатын-кызның баш киеменә алтын-көмеш җепләр белән чигелгән чәчәкләр аеруча затлы төс биргән. Соңга таба калфакка чәчәкләрне энҗе-мәрҗән, сәйләннәрдән тезгәннәр.

1 нче алып баручы. XX гасыр башында калфак тәмам кечерәя. Ул баш киеме булудан бигрәк, бизәнү әйбере сенә әйләнеп кала. Сөекле композиторыбыз Сара Садыйкова гомеренең ахырына кадәр калфагына тугрылыклы калды. Калфак – баш киеме буларак та, бизәнү әйбере буларак та татар хатын-кызларының рухи матурлыгын, күңел байлыгын, тегү-чигү эшенә осталыгын, дөньяны танып белүдә нечкә сизгерлеген, зәвыгын чагылдырган сәнгать җәүһәре ул.

2 нче алып баручы.

Талир тәңкә авыр тарта,
Алты мыскылдан арта, – дип тә җырлаганнар бит әле.

Тәңкәләр... Алар яка чылбырына да, беләзекләргә дә, чулпыларга да, муенсаларга да тагылган. Моның бер сере булгандыр, мөгаен. Чынлап та, мәҗүсилек заманнарында яшәгән бабаларыбыз тәңкәләрдә магик көч сизгән. Алар төрле бәхетсезлекләрдән, авырулардан саклый дип ышанганнар. Тәңкәләр түгәрәк кенә булмыйча, квадрат, ярымай, ромбик, йолдыз рәвешендә дә булганнар.

(Н.Исәнбәтнең «Уракчы кыз»ы башкарыла.)

1 нче алып баручы. Әбием сандыгында тагын ниләр бар икән?

Укучылар. Беләзек-йөзекләр.

2 нче алып баручы. Хатын-кызларның безнең көннәргәчә сакланып калган бизәнү әйберләре ич болар. Безнең әби-апаларыбыз андый бизәнгечләрне бик яраткан.

1 нче алып баручы. Шуңа күрә халык җырларында алар еш телгә алына.

Беләзекләрең беләктә,
Асыл камзулың келәттә.
Насыйп булса, кавышырбыз,
Тор, җаныкаем, изге теләктә.

2 нче алып баручы.

Беләккәйләрем билле иде,

Беләзекләрем билге иде.
Шәм яндырып эзләп йөрсәм дә,
Таба алмам, җаныем, синдәйне.

Укытучы. Әйдәгез, «Беләзегем-йөзегем» җырын җырлап, түгәрәк әйләник әле. Борынгыдан шушы уен уйнала торган чишмә буйлары искә төшсен.

1 нче алып баручы. Беләзек – безнең халыкта киң таралган һәм иң борынгы бизәнү әйберләренең берсе. Археологлар казып тапкан табылдыклар шуны күрсәтә: таш гасырда беләзекләрне мамонтның казык тешеннән ясаганнар. Татарларда беләзек киемнең аерылгысыз өлеше саналган. Аны бай хатыннары да, ярлылар да, яше дә, карты да яратып кигән. Гадәттә, беләзекне парлап, һәр кулда берәрне йөрткәннәр. Бу – гаиләдә ир белән хатын арасында татулык яшәсен өчен шулай кабул ителгән.

2 нче алып баручы. Зәркәнчеләр беләзекне көмештән, сирәк очракларда алтыннан ясаган. Яшь кызлар тар беләзекләр йөрткән, өлкәнрәк хатыннар киңрәк беләзекне хуп күргән. Аларны төрлечә бизәгәннәр: я металлны чокып нәкыш салынган, я аңа асылташлар тезелгән.

1 нче алып баручы. Ә ташлары җемелдәп торган нәфис йөзекләр, балдаклар турында оныттык түгелме?

Алар турында сөйләү генә аз. Чөнки халкыбызның иң күп җырларында искә алынган бизәнү әйберләре бит алар.

Көмеш йөзек бер булмас,
Кулга кисәң, кер кунмас.
Уңган да егет ул булыр,
Кайда йөрсә дә, хур булмас.

2 нче алып баручы.

Көмеш кенә йөзек, әй, койдырдым.
Унике көмеш акчадан.
Эзләдем дә сине таптым,
Гөлләр үсә торган бакчадан.

1 нче алып баручы.

Кулымдагы балдагымның
Исеме бар кашында.
Син кояш чыгышы ягында,
Мин кояш баешында.

2 нче алып баручы. «Кулымдагы йөзегемнең» дип башланган такмак җырларын җырлап, безнең әбиләр, әниләр чишмә буйларын, клубларны дер селкетеп бии торган булганнар.

1 нче алып баручы.

Кулымдагы балдагымның исеме Газизулла.

Һәр кешенең сөйгән яры үзенә газиз була.

2 нче алып баручы.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Асия.
Гөлләр маяк, сандугачлар
Юлдаш булсыннар сиңа.

1 нче алып баручы. Халкыбызның гүзәл муенсалары, изүләре, хәситәләре, яка чылбырлары турында да тәфсилләп сөйләргә булыр иде. Сезнең каршыда – аларның рәсемнәре.

Аларның тарихы, кулланылышы турында күргәзмәдәге әдәбияттан таныша аласыз.

2 нче алып баручы. Вакытлар үтү белән кешеләрнең киемнәре дә үзгәрә. Бүген без сөйләгән киемнәр, бизәнү әйберләрен музей витриналарында, сәхнәләрдә генә күрергә мөмкин. Билгеле, хәзерге киемнәребез бик уңайлы безнең. Әмма бертөрле. Киеменә карап, кешенең Мәскәүдән яки Казаннанмы, Чабаксардан яки Ижауданмы икәнен аерам димә. Милләтнең кабатланмас милли үзенчәлеге әнә шулай итеп югала бара.

(«Шәрык кызы» җыры (Л.Батыр-Болгари музыкасы, М.Галиев сүзләре) башкарыла.)

1 нче алып баручы. Борынгыларның киемнәре, бизәнү әйберләре бүгенге тегүчеләр, зәркәнчеләр, дизайнерлар өчен бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы булып тора. Ул матурлыклар мәңгелек. *(«Сөлге чигәм» җыры (Ф.Әхмәтов көе, Х.Җәләлов сүзләре) башкарыла.)*

III БҮЛЕК. ГОРЕФ-ГАДӘТ. ЙОЛА.

БУЫННАР ЧЫЛБЫРЫ

(Әхлак түгәрәге материаллары буенча район күләмендә үткәрелгән дәрестән тыш чара)

Алия САДРИЕВА,
Әтнә районы Күәм урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Чара барышы

Алып баручы.
Исәнмесез, хәерле көн барчагызга!
Телим сезне үткәннәргә кайтарырга.
Җәйге кичтә урам тулы бала-чага
Шау-гөр килеп уйнаулардан зур тәм таба.

1 нче бала.
Әй, дусларым, туктагыз да
Күрегез сез,
Капка төбенә чыккан безнең
Ак әбиебез.

2 нче бала.
Әйдәгез, киттек, сорыйк әле
Ак әбидән.
Каян чыккан икән безнең
Авыл – Күәм?

3 нче бала.
Ничек булган бабайларның
Тормышлары?
Ничек булган язмышлардан
Узмышлары?
(Ак әби чыгып утыра.)

Алып баручы.
Балаларны борчый икән
Зур сораулар.
Җавап эзләп Ак әбигә
Килде алар.

Ак әби.
Әй, оланнар, безнең тарих
Бик тирәндә.
Утырыгыз тезелешеп
Бер тирәгә.
Тыңлагыз сез чал тарихта
Ни булганын,
Бабаларның бу төбәктә
Ни кылганын.

1 нче бала.
Әби, әби, авыл читендә
Таулык бар бит.
Ник атыйлар ул тауларны
«Калатау» дип?

Ак әби.
Моннан мең еллар элек
Ул тауларга
Бабайларга туры килгән
Тукталырга.
Ул заманда Ашыт суы
Бик зур булган,
Дәрья кебек ярларыннан
Ташып торган.
Шул су буйлап йөзеп килгән
Төрки халык.
Тормыш корган тау башына
Кирмән салып.

2 нче бала.
Әби димен, нәрсә икән
Соң ул кирмән?
Ул кирмәнгә нинди төрки
Халык килгән?

Ак әби.
Төркиләр дип аталадыр
Безнең халык,
Бик борынгы заманнардан
Бирле барып.

Ә кирмән ул бабайларның
Йорт-җирләре. Ихатасы.
Диварлары, ай-һай, булган биек.
Дошман түгел,
Керә алмаган
Хәтта киек.
Тау башында балкып торган
Мәгърүр кирмән.
Шаклар каткан, диләр,
Калатауны күргән,
Каратауны белгән.
(Слайдтагы кирмән рәсеменә ишарәли.)

3 нче бала.
Әби, әби, ул кирмән бит
Кала түгел.
Ә нигә соң Калатау дип
Әйттең бүген?

Ак әби.
Менә шунда олы кала
Төзибез дип,
Уйлаганнар зур шәһәрле
Булырбыз дип.

1 нче бала.
Ник соң алар төземәгән
Монда шәһәр,
Әллә инде төзү эше
Булган хәтәр?

Ак әби.
Дөрес анысы, төзелешләр
Авыр барган.
Кран түгел, шәһәрләрне
Кеше салган.
Җыелышып сөйләшкәннәр
Бу бабайлар.
Бер аксакал торып әйткән:
«Сез, агайлар,
Төзесәгез монда кала,
Һәлак булыр.
Чөнки тиздән Ашыт суы
Тәмам корыр.

3 нче бала.
Кала булгач, аның суы
Нигә кирәк?
Ашыйм дисәң, җирдә үсә
Бик күп җиләк.

Ак әби.
Юк, балакай, судан башка
Тормыш юк ул.
Иртән торып шул су белән
Юабыз бит-кул.
Җир белән су һәм дә килеп
Чиста һава.
Ходай биргән җылы яңгыр,
Һәм кар ява.
Болар бар да кеше өчен
Бик кирәкле.
Шулар бирә безгә кирәк
Мул икмәкне.

1 нче бала.
Әби, нигә
Искавыл дип
Атыйлар соң,
Түбән ягын
Авылыбызның?

Ак әби.
Чөнки әүвәл шул урында
Урнашканнар,
Урман кисеп, басу ачкан
Әйдәманнәр.

2 нче бала.
Баш-аяк дип безнең очны
Ник атыйлар?

Ак әби.
Анда гел-гел гомер иткән
Ярлы халык,
Болар өчен мал-туарның
Баш-аягы булган ризык
Менә шундый хәлләр, наным.
(Баланың башыннан сыйпый.)

3 нче бала.
Әби-әби, кайдан белеп
Бетердегез
Сез боларны?
Әйбәт икән
Хәтерегез,
Зиһенегез.

Ак әби.
Өлкәннәрдән килгән ядкарь –
Хатирәләр
Буыннардан-буыннарга
Бара күчеп.
Сакла аны, күз карасы
Кебек күреп. *(Баланы кочаклый.)*
Яшь буынга
Аннан тапшыр.
Әби-баба васыяте
Шушы булыр.
Я, оланнар, сау булыгыз,
Өйгә керим.
Барчагызга тәүфыйкъ, зиһен,
Бәхет телим.

1 нче бала.
Ак әбиебез,
Озак яшә безнең белән. *(Елмая.)*
Хәзер инде мин авылның
Тарихын беләм.
(Бергәләшеп кереп китәләр.)

Укытучы. Рәхмәт, укучылар, әйдәгез, парталарга урнашыгыз.
Балалар, әле генә үзегез кат-

нашкан «Ак әби хатирәсе» күренеше буенча фикер алышыйк.

Бу күренештә кемнәр катнашты?

Укучылар. Балалар һәм Ак әби.

Укытучы. Кем соң ул Ак әби? Шуны ачыклап китик әле.

Укучылар. Ул – өлкән яшьтә, күпне күргән, күп белә.

Укытучы. Нәрсәне күп белә?

Укучылар. Тарихны.

Укытучы. Нинди тарихны?

Укучылар. Авылыбыз тарихын, үткәнен.

Укытучы. Бик дөрес, укучылар, үткәнен белмәгәннең киләчәге юк дигән күренекле галим, дин белгече, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани. Балалар, күпне күргән, белгән өчен генә Ак әби дибезме? Мондый абруйлы исемгә, кадер-хөрмәткә лаек булу өчен тагын нинди сыйфатларга ия булырга кирәк дип уйлыйсыз?

Укучылар. Ул сөйкемле, мәрхәмәтле, олы җанлы, гыйлемле булырга тиеш.

Укытучы. Әлеге күренештәге кебек ак әбиләр чынлыкта бармы? Кемнәр алар?

Укучылар. Безнең әбиләр.

Укучылар. Барлык әбиләрне дә ак әби дип әйтеп буламы?

Укытучы. Кемнәрнең әбиләре бар? *(Җаваплар тыңлана.)* Ак әбиләр булган кебек, Ак бабайлар да юкмы икән, укучылар? Бүген бәйрәмгә кунак булып районыбызның Ак бабайлары да килгән.

Укучылар. Аларны «Аксакаллар» диләр . Укучылар, әбиләребез, бабайларыбыз турында сөйләшә идек. Алар сезне яратамы? Ә сез аларны? Әбиләрегез, бабайларыгыз сезгә ниләр тели, нәрсәгә өйрәтә?

Укучылар. Акыллы булырга .

Эшчән, тырыш булырга.

Кечкенәләрне һәм өлкәннәрне хөрмәт итәргә.

Ярдәмчел булырга.

Күршеләр белән дус, тату яшәргә.

Әти-әнине яратырга,

Туган телебезне сакларга.

Укытучы. Ак яулыклы әбиләр дибез. Ак яулык, ак төс нәрсә билгесе?

Укучылар. Сафлык, чисталык.

Укытучы. Әбиләрегез кайчан ак яулык бәйли? Сезне алар нәрсәгә өйрәтә?

Укучылар. Әбиләр, ак яулык бәйләп, намаз укый. Безгә дога өйрәтә.

Укытучы. Намаз нәрсә соң ул? Нинди намазлар була? Намаз вакытын кайдан беләбез? Нәрсә ул азан? Аны кайда әйтәләр? *(Җаваплар тыңлана.)*

Укытучы. Арагызда кемнең әтисе я булмаса бабайсы азан әйтә? Намаз уку дибез. Анда нәрсә укыйлар соң, балалар?

Укучылар. Догалар.

Укытучы. Сезгә әбиләрегез нинди намаз догалары өйрәтте? Кайсыларыгыз укып күрсәтер икән? *(Белүчеләр укый)*

Укытучы. Рәхмәт, балалар. Әбисе булган кешенең нинди бәхетле икәнен һәр бала белә. Әбием! Бабаем! Дип әйтүләре үк рәхәттер. Нинди матур яңгырый бу сүзләр. Алар булмаса, өйдә, гомумән, тормышта ямь калмас иде. Аларны рәнҗетү, берүзләрен ялгыз калдырып китү, алар белән дорфа мөгамәләдә булу зур гөнаһтыр. Бу сөйләшүдән мин менә шундый нәтиҗә ясыйм.

Укучылар, сез табышмаклар яратасызмы? Нәрсә соң ул табышмак? Аны кемнәр уйлап чыгарган?

Укучылар. Әби-бабаларыбыз. Халык. Бу – борынгыдан килә торган мирас.*(Укучылар үзләре әзерләгән табышмакларны иптәшләренә әйтә.)*

Укытучы. Тагын нәрсәләрне әби-бабайлардан калган мирас дип атый алабыз?

Укучылар. Мәкальләр. *(Мәкальнең ахырын табу уены.)*

Укытучы. Укучылар, сез нинди дини бәйрәмнәр беләсез? Ә нинди милли бәйрәмнәр бар? Алар хәзер дә үткәреләме? *(Укучылар бәйрәмнәрне искә төшерә).*

Укытучы. Әйдәгез, слайдтагы фотоларны карыйк әле. Сабантуй бәйрәмнәре кайда үтә? Сез катнашасызмы? Анда нинди ярышлар була? Бүләкләр алганыгыз бармы? Әйдәгез әле, Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» повестен искә төшерик. *(Әсәрдән өзек укыла.)* Ничек уйлыйсыз, элеккеге Сабантуй бәйрәмнәре хәзергеләреннән аерыламы? Элек бүләкләр нинди булган? Бәйрәм вакытында кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары нинди? Сабантуй мәйданы, бәйрәм төгәлләнгәч, нәрсәгә охшап кала, күзәткәнегез бармы? Сезгә ничектер, мин ул мәйданны чүпләккә охшатам. Кайткан кунакларга да, авыл кешеләренә, балалардан бигрәк ата-аналарга, тәрбия җитеп бетми, күрәсең. Укучылар сез уйнап күрсәткән күренештә Ак әби тормышта яшәр өчен иң кирәкле нәрсәләр турында әйтте?

Укучылар. Җир, су, һава.

Укытучы. Нинди елганың исемен атады?

Укучылар. Ашыт.

Укытучы. Хәзер ул елга буендагы уйсулык ничек атала?

Укучылар. Ашыт табигать сакланышы.

Укытучы. Ни өчен сакланыш?

Укучылар. Кайбер үсемлекләр, хайваннарга юкка чыгу куркынычы яный. Алар Кызыл китапка кертелгән.

Укытучы. Укучылар, аларны ничек итеп саклап булыр икән соң? Без нинди булырга тиеш? *(«Моң-зар» бәйгесе. Төркемнәрдә эшләү.)*

1 төркемгә:

Матурлыгыма сокланып мине күпме кеше өзә. Ә миңа чәчәк атар өчен 10 ел вакыт кирәген уйламыйлар да. Кешеләр миннән йөрәк авыруларын дәвалаучы тамчылар ала. Элек мине теләсә кайсы урманда очратырга мөмкин булса, хәзер мин яклауга мохтаҗ. (Энҗе чәчәк)

Матур түгел икәнлегемне үзем дә беләм. Мине күрсәләр, күпләр читкә тайпыла, таш ыргыта яки аяклары белән тибеп җибәрә. Бар да матур булмый инде. Черки, башка канэчкеч бөҗәкләрне юк итеп, мин кешеләргә зур файда китерәм. Сез әле белмисездер, матур тавышларыбыз өчен японнар безне өйләрендә асрый. (Гөберле бака)

2 төркемгә:

Без елдан-ел азаябыз. Табигать безгә иртә чәчәк ату мөмкинлеге биргән. Кеше, кыш буе чәчәккә сусап, кулына тотып карау өчен безне өзә, тажларыбызны йолкый... һәм ташлый. Ә бит без аңа күпме файда китерә алыр идек . Бездән ясаган дару балаларга да файдалы. Без бит әле бал кортларына да кирәк. Яз көне аларга азык табу авыр. Шуңа күрә беренче чәчәкләргә куныП, сутыбызны эчәләр. (Үги ана яфрагы)

Безнең турында күп легендалар, уйдырмалар сөйлиләр. Без кошларга да, җәнлекләргә дә охшамаганбыз. Караңгылыкны яратабыз. Ләкин без дошманнар түгел, ә кешенең дуслары. Башны аска каратып эленеп торганга, ямьсез булганга карап кына бездән чирканырга ярыймыни?! (Ярканат)

Укытучы. Табигатьне саклау – һәр кешенең изге бурычы ул. Әбиләребез, бабайларыбыз тезгән буыннар чылбыры бервакытта да өзелмәсен! Алар рәнҗүдән тизрәк картаймыйча, безне акылга-тәүфыйкъка өйрәтеп бәхетле яшәсеннәр, ә урыннары өйнең түрендә булсын!

Тәмле ашлар пешерә,
Кем ул?
Матур гөлләр үстерә,
Кем ул?
Минем яраткан әби.
Ә ашлары – өчпочмак,
Бәлеш, җәймә һәм коймак,
Табын күрке – ипи-тоз,
Ә ахыры – якты йөз.

1нче укучы.

Дәү әнием

Дәү әни өчпочмак ясый,
Пешерә бәлешен дә.
Вак-вак түгәрәкләр җәеп
Ясый ул өлешен дә.
Кабартмасы да бик тәмле,
Бик йомшак камыры да,
Баллы, майлы була аның
Пешергән коймагы да.
Бүген урама пешерә:
«Сезне сыйлыйм әле», – дип,
Ә мин читтән карап торам:
«Ничек ясый икән?» – дип.
Йомшак кына камыр баса,
Аннан җәя җәймәсен
Кызу-кызу тасма кисә,
Хәзер беләм хәйләсен.
Чәнечкегә тасма урый
Китереп майга сала
Берсен ала, берсен сала
Табакка өелеп бара.
Хикмәтләре бик күп икән
Сөйләп бетәрлек түгел,
Өстәл өстенә менгәчтен
Ашавы гына җиңел.
Фотоаппарат алдым да,
Төшердем мин рәсемгә.
Дәү әнигә әйтеп тормый,
Җибәрдем аны сезгә.
Дәү әнигә бүләк булсын
Әниләр бәйрәменә
«Чын-чын бүләк» – була инде
Җиңеп чыксам бәйгедә.
Рецебы бик гади аның:
Иң беренче – «бисмилла»,
Чеметеп тоз, өч йомырка,
Сала аңа бераз он.
Шуңа тагын өстәп куя
Барлык күңел җылысын.

Укытучы. Димәк, укучылар, әбиләребез, милли ризыкларның серен саклап, буыннан-буынга тапшыручылар да икән.

Әйе, әбиләребезне яратабыз, аларга иркәләнәбез. Кайчак үзебез булдыра торган эшләрне дә алардан эшләтергә тырышабыз. Бу сүзләр аеруча малайларга кагыла. Күренекле шагыйребез Шәүкәт Галиевнең «Мактаныша малайлар» дигән шигырендә тыңлап карый әле.

2 нче укучы.

Мактаныша малайлар:
Мәхмүт, Нәгыйм, Рамайлар.
Мәхмүт әйтә болай дип:
– Минем әби уңган бик,
Минем әби кулай бик –
Әйткәнемне дә көтми,
Чалбарны да үтүкли,
Күлмәкне дә үтүкли!
– Минем әби дә бик шәп,
Барын да бирә эшләп, –
Диеп Рамай кушыла
Шунда Мәхмүт дустына.
Нәгыйм дә ялгап китә:
– Бабакайга кем җитә –
Яратып эшли бик тә,
Ботинкамны чистартып,
Китерә ялтыратып.
Күрдем мин малайларны,
Мактанчык Рамайларны
Тыңладым, абайладым –
Шәп икән әбиләре,
Шәп икән бабайлары.

Укытучы. Сезнең арада да юкмы андый малайлар? *(Җаваплар тыңлана.)*

Укучылар, без сезнең белән бүгенге әхлак түгәрәгендә нәрсәләр өйрәндек?

Әхлаклы татар малае һәм әхлаклы татар кызы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? *(Җаваплар тыңлана.)*

Төркемнәрдә проект эше башкарабыз. Әзерләп куйган конверттан рәсемнәрне алып, матур җөмләләр язарга һәм эшегезне якларга кирәк булачак. *(Укучыларның эшләре белән танышу.)*

Дәрестән тыш чарабыз тәмам. Сау-сәламәт, иманлы, тәүфыйкълы, рәхим-шәфкатьле балалар булып үсегез.

III БҮЛЕК. ГОРЕФ-ГАДӘТ. ЙОЛА.

КАЗ ӨМӘСЕ

(Урта сыйныф укучылары катнашында кичә)

Гөлфия ИБРАһИМОВА,
Алабуга районы мәгариф идарәсе методисты

Кичә барышы

(Сәхнәдә авыл өе күренеше. Караватта – чигүле мендәрләр, ишек башларында – сөлгеләр. Стенага «Аятел көрси» эленгән, татар кызы белән татар егете рәсеме куелган. Чәй өстәле әзерләнгән, чәкчәк куелган. Сәкедә каурыйлар салынган иләкләр. Идәндә паласлар, ләгәндә комган тора. «Каз канатлары» көе яңгырый. Сәхнәгә алып баручылар чыга.)

1 нче алып баручы. Хөрмәтле укытучылар, укучылар һәм әти-әниләр, без бүген «Каз өмәсе» үткәрергә җыелдык. Халкыбызның онытыла барган шундый өмәләре олы бәйрәмгә әйләнсен иде.

2 нче алып баручы.

Каз өмәсе бүген, каз өмәсе,
Шау-гөр килер бәйрәм һәр йортта.
Табыннар мул булсын,
Җырлар яңгырап торсын!
Уй-хәсрәтләр моннан ерак качсын!
Һәрберебез җырлап күңел ачсын,
Бәйрәмебез котлы, мөбарәк булсын!

Диләрә. *(«Каз өмәсе»нә кызлар чакырып йөри.)* Бүген бездә – «Каз өмәсе». Кызлар, «Каз өмәсе»нә килегез. Кызла-а-а-р, «Каз өмәсе»нә килегез! *(Чыгып китә.)*

Әби. *(Самовар күтәреп керә.)* Ай, аллам! Оныгымның тавышы түгелме соң? «Каз өмәсе»нә кызларны чакырырга киткән иде, кая китеп югалды инде тагын? Кер әле, кызым, кер әле.

Бабай. Нәрсә бар, карчык, ни дип шәрран ярасың? Күрше урамга ишетелерлек итеп.

Әби. Бабасы дим, ишеттеңме? Кызым кайтып җитте бугай. Кызларны каз өмәсенә чакырырга киткән иде.

Бабай. Кемнәрне дисең, анасы?

Әби. Кызларны дим, казларны әзерлә.

Бабай. Кызлары әзер булса, казларны әзерлим мин аны. Хәзер, хәзер, барсы да булыр. Бисмилләһир-рахманир-рахим… *(Каз аякларын бәйләргә җепләр тотып чыгып китә).*

Диләрә. Әбекәй, мин кайттым, казлар әзерме?

Әби. И-и кызым, бәхетле бала булырсың, бигрәк җитез үзең. Әллә кызлар да килдеме?

Диләрә. Әйе, әбекәй, алар ишек алдында.

Әби. *(кет-кет көлә-көлә).* Кызларым, керегез, керегез. Әй, аллам, берсеннән-берсе матурлар!

Кызлар. Исәнмесез!

1 нче кыз. Әбекәй, каз өмәсе мөбарәк булсын!

Әби. Амин, балам, шулай булсын!

2 нче кыз. Казларыгыз симез булсын!

3 нче кыз. Казларыгызның мамыклары күп булсын!

Әби. Амин, балам, шулай булсын. Әле менә Диләрә оныгыма мендәр ясармын дигән идем. Әйдәгез, утырыгыз. *(Утыралар.)* Хәзер бабагыз казлар кертеп бирер. Бабалары, кер әле!

Бабай. Анасы, нигә дәшәсең тагын? *(Кызларны күреп туктап кала.)* Эһе, кызларым килгән икән. Берсеннән-берсе матурлар. Эх, яшь чагым булсамы?!

Әби. Әй, сиңа һаман шаяртырга булсын, кая, казларың әзерме?

Бабай. Әзер, хәзер алып керәм. (*Чыгып китә.)*

Әби. Менә, кызларым, каз мамыкларын салырга иләкләр. (*Иләкләр бирә.)*

Бабай (*керә*). Ягез, кызларым, уңганлыкларыгызны күрсә-

тегез әле. Ә мин казларны эләргә урын әзерлим. (*Чыгып китә.*)

(Кызлар казларны алларына куя, иләкләргә йон йолкып салган хәрәкәтләр белән «Каз өмәсе» җырын җырлыйлар. Җыр бетүгә ишектән бер егет керә.)

Егет. Исәнмесез барыгыз да. Кызларыгыз симез булсын, әй лә, казларыгыз симез булсын! (*Кызлар көлешеп ала.*)

Кызлар. Әй, юньсез, ни дигән була?!

Әби. Әй, шаярта гына ул. Әйе бит, улым? Ни эш бетереп йөрисең?

Егет. Әби, без булышырга килдек. Башкалар тышта калды, эшләрегез беттеме? Егетләр керсеннәрме?

Әби. Ярый, балам, бар, чакыр, керсеннәр. *(Егетләр «Их, сез матур кызлар!» җырын җырлый-җырлый ишектән керәләр.)*

Егетләр. Исәнмесез!

1 нче егет. Ярдәм кирәкме, кызлар? Әллә эшегез бетте дәме?

Кызлар. Бетте, бетте.

1 нче кыз. Килегез, аякларын бәйләгез, су буена юарга барабыз.

Әби. Диләрә кызым, көянтәләрне өйалдыннан алып кер әле. *(Диләрә, көянтәләрне алып кереп, кызларга бирә. Егетләр казларны элә.)*

Әби. Сез кайтуга коймак пешерермен. Барыгыз, балакайларым, барыгыз.

(«Каз канатлары» көе яңгырый. Иң арттагы кыз каурый сибеп бара.)

Егетләр, кызлар. Әйдәгез, әйдәгез… (*Яшьләр китә. 3-4 кыз өйдә кала.)*

Әби. Бу йоннарны сыдырырга кирәк инде.

Кызлар. Хәзер, әбекәй, үзебез.

1 нче кыз. Карагыз инде, кызлар, егетләр кызларыгыз симез булсын дигән булалар.

Әби. Шаярталар гына бит алар. И-и, кызларым, бабагызны «Каз өмәсе»ндә беренче мәртәбә күргән идем. И, ул чаклар!.. Сөйли китсәң…

Кызлар. Сөйлә әле, әбекәй, сөйлә инде.

Әби. Сөйләрмен, балакайларым, башка вакытта сөйләрмен. Кызым, бабаңны чакыр әле.

Диләрә. Бабакай, әбекәй чакыра.

Бабай. Булды, булды, анасы, казларны эләргә урын әзерләдем.

(Яшьләр кайталар. Музыка.)

1 нче егет. Әби, эшебезне бетердек, казларыгызны кабул итеп алыгыз.

Әби, бабай. Ай-яй, бигрәк чиста итеп югансыз. Хәерле ризык булып, үзебезгә насыйп булсын, Ходаем!

Бабай. Өйалдына элеп куйыйм әле. (*Бабай казларны алып чыгып китә.)*

Әби. Менә, балакайларым, коймактан авыз итегез, каз мае белән майладым. Кыенсынмагыз, сыйланыгыз.

Диләрә. Бигрәк тәмле каз мае белән коймак. Рәхмәт, әбекәй. Әйдәгез, хәзер уеннар уйныйбыз. «Без-без идек»не уйныйбызмы?

Бергә. Уйныйбыз, уйныйбыз. *(Кулларының баш бармакларыннан тоталар да әйтәләр.*)

Без-без, без идек,
Без 12 кыз идек.
Базга төштек май ашадык,
Келәткә кердек бал ашадык,
Өйгә кердек чәй эчтек,
Коега төштек су эчтек.
Таң атканчы юк булдык.
Авызыңны ач та йом.

Бабай (*Көлдереп йөри.)* Кара-кара син боларны, почык борыннар, кап-корсаклар, he-he-he, кайсының теше күренә микән? Ә-ә-ә, менә бусының авызы колакта, колагы ераста, теше күренә, теше. Кил әле, кил. Ништәтәбез? (*Бер кызны уртага чыгара.)*

Бергә. Җырлатабыз, бабай, җырлатабыз. *(Кыз җырлый.)*

Диләрә. Тагын берне уйныйбыз. (*Бабай көлдереп йөри. Бер малай авызын ача.*) Менә бусын нишләтәбез?

1 нче егет. Әтәч булып кычкырсын.

(Малай урындыкка басып,берничә мәртәбә яшь әтәч булып кычкыра.)

Әби. Балалар, каз йоннарын бу табакка салыгыз әле. Карагыз әле суга. Каз йоннары суда аккошлар кебек йөзә, күрәсезме? *(Барысы да суга карый. Бер малай уч төбе белән суга китереп суга. Барысына да су чәчри. Көләләр, шау-гөр киләләр, кагыналар.)*

Диләрә. «Йөзек салыш» уйныйбыз. *(Көй уйный. Балалар тезелешеп баса, Диләрә бии-бии йөзек сала.)* Кемдә йөзек – сикереп чык. (*Бер кыз алга сикереп чыга.)*

1 нче кыз. Нишләтәбез?

1 нче егет. Биетәбез. *(Биюче кыз бабайны чакыра, бабай әбине чакыра.)*

Яшьләр. Һәй, булдыралар да инде безнең әби белән бабай! *(Кул чабалар.)*

Диләрә. Әбием, бабаем, утырып торыгыз. Без сезгә хәзер үзебез җырлап, биеп күрсәтәбез. *(Түгәрәкләнеп басалар. «Сара сибә гөлләргә» дигән җырлы-биюле уен уйнала.)*

Сара сибә, Сара сибә,
Сара сибә гөлләргә.
Сип, Сара, гөлләргә,
Саргаймасын гөлләр дә. *(Башта – кызлар, аннан малайлар әйләнә.)*

(«Эх, зилем, зиләле» уены тәкъдим ителә. Малайлар һәм кызлар парлашып басалар.)

Менә сиңа – уң кулым,
Менә сиңа – сул кулым.
Менә сиңа, якын дустым,
Менә сиңа – куш кулым.
Их, зилем, зиләле,
Сандугачым кил әле.
Кил әле, дустым, кил әле,
Икәү әйләник әле. *(Икешәрләп әйләнәләр.)*

Әби. Һай, рәхмәт балакайларым, «Каз өмәсе» бигрәк күңелле узды.

(«Каз канатлары» җыры яңгырый.)

1 нче алып баручы.
Курый сибәм су юлына
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күрсәтеп,
Парлар табып калыгыз.

2 нче алып баручы.
Бии-бии сылу кызлар,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан калган гадәт –

Икесе бергә. Татарның «Каз өмәсе».

1 нче алып баручы.
Каз канатлары сибәбез
Сез барасы юлларга.
«Каз өмәсе» бәйрәмнәрен
Бергә үткәрергә язсын
Киләсе елларга да.

(«Каз канатлары» көе уйнала. Баш иеп, уртадан алга киләләр дә көчле алкышлар астында пәрдә ябыла.)

III БҮЛЕК. ГОРЕФ-ГАДӘТ. ЙОЛА.

ИСЕМ - КҮҢЕЛ КӨЗГЕСЕ

(Татар халкының гореф-гадәтләрен саклауга багышланган күңел ачу кичәсе)

Гөлнар ЗӘКИЕВА,
Актаныш районы башлангыч мәктәп-балалар бакчасы тәрбиячесе

Кичә барышы

(Борынгы татар өе күренеше. Уртада бишек эленеп тора. Салмак кына көй яңгырый.)

Алып баручы. Исәнмесез, хөрмәтле ата-аналар, килгән кунаклар! Бүген без сезгә татар гаиләсендә уза торган йолаларның берсе – Исем кушу йоласын күрсәтербез. «Кыз бала исеме йолдыз балкышына охшасын, назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын. Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын хәтерләтсен, аның мәгънәсендә гакыл гәүдәләнсен», – дип язган шагыйрь, тәрҗемәче, публицист **Рәсүл Гамзатов.**

Яхшы исем кыйммәт барсыннан да,
Аннан тугры дусны күрмисең;
Безнең хакта мәңге ядкарь саклап,
Картаймыйча яши һәр исем.

(Сәхнәгә Ак әби чыга. Бишек янына килеп бишек җыры җырлый.)

Ак әби. Бүген бездә зур шатлык. Дөньяга сабый туды. Гаиләгә ямь, юаныч, бәхет өстәлде. Бәхетле булып, пар канатлы булып үссен сабыебыз. Котлы булсын бәби ашы бәйрәме, котлы булсын! Бүген без кунак җыябыз. Кая соң әле үзләре, күренмиләр *(Тәрәзәдән карый)*. Әнә, киләләр. *(Кулларына бүләкләр алып балалар чыга.)*

Балалар.

Без, без, без идек
Без унике кыз идек.
Базга төштек – бал ашадык,
Келәткә кердек – май ашадык.
Балы да тәмле булды,
Мае да тәмле булды,
Әмирханга да калды.

(Балалар кулларын биреп Ак әби һәм кунаклар белән күрешә. Бүләкләрен өстәлгә куя.)

Ак әби. Рәхмәт, балакайларым, бик зурлап килгәнсез. Түрдән узыгыз, әйдә.

(Балалар ике якка капма-каршы тезелеп баса.)

1 нче бала. Ә кая соң бәби? Безнең бәбине бик күрәсебез килә.

Балалар. Әйе, әйе. Күрәсебез килә.

Ак әби. Бала бәбәй мунчасында шул әле. Яшь баланы көн саен мунчада коендыру файдалы.

2 нче бала. Ә без баланы юындырганда әйтә торган юаткыч беләбез. Сөйлибезме?

Балалар. Сөйлибез!

(Балалар Җәүдәт Тәрҗемановның «Йомшак су, йөгерек су» шигырен сөйли. Сүзләргә туры килгән хәрәкәтләр ясыйлар.)

Йомшак су, йөгерек су!
Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын.
Битләрем аллансын,
Кулларым агарсын.
Тешләрем тазарсын.
Авызым елмайсын,
Колагым тыңласын,
Йомшак су, йөгерек су!
Һәммәсен чиста ю!

Ак әби. Рәхмәт, балакайлар. Менә булдырасыз.

(Кунак әбиләр килә. Кулларында мич ашлары – бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, чәк-чәк һ.б.)

Ак әби. Әйдәгез, әйдәгез, рәхим итегез, кадерле кунаклар. Күптән сезне көтәбез.

Алып баручы. Әбиләребез күчтәнәчләр белән килгән.

1 нче әби. Яшь бала туган гаиләгә мич ашлары пешереп алып килү – күркәм гадәт. Менә шундый тәмле ризыклар кебек әнисенең дә, әтисенең дә телләре татлы булсын.

Алып баручы. Болар бит татар халкының милли ризыклары. Без аларны беләбез. Балалар, әйдәгез, аларның исемнәрен искә төшерик.

2 нче әби.
Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар.

Балалар. Өчпочмак.

3 нче әби.
Утырсам да юаш кына.
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы май, дөге.
Эчем тулы ит кенә,

Балалар. Бәлеш.

1 нче әби.
Вак-вак кына кискәләп
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына капкалап
Ашаулар булыр кулай.

Балалар. Чәк-чәк.

2 нче әби.
Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә?

Балалар. Коймак.

(Әбиләр күчтәнәчләрен өстәлләргә куя һәм урындыкларга барып утыра.)

3 нче бала. Без дә коймак пешерергә яратабыз. Сезгә дип җырлы-биюле уен да әзерләп килдек. *(Балалар, уртага басып, «Коймаклар» дигән җырлы-биюле уенны уйный. Сүзләргә туры килгән хәрәкәтләр ясый.)*

Әмирханның туган көнендә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.
Коймакларга карасаң,
Менә шулай күпергән,
Менә шулай җәелгән.
Менә шулай кысылган.
Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнеңне сайлап ал!

(Берничә тапкыр уйныйлар. Балалар урындыкларга барып утыра. Бала күтәргән Ана чыга. Ул Габдулла Тукай сүзләрен халык көйгә салган Бишек җырын җырлый.)

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең.

Ана. Бу – безнең улыбыз. Бүген аның бәйрәме – Бәби ашы. Кара әле, улым, сине котларга күпме кунак килгән.

1 нче әби. Бала тугач, күңелле мәшәкатьләр башлана. Аның беренчесе – исем кушу. Аңа нинди исем бирергә? Бу мәсьәлә ата-ананы, туганнарны уйландыра, чөнки исем кешегә бер генә тапкыр бирелә.

2 нче әби. Һәр кешегә исеме туган тел кебек якын, газиз, кадерле. Балага исем кушу – бик җаваплы вакыйга. Күркәм исем белән дәшү балага дога кебек уңай тәэсир итә. Шуңа да балага яхшы мәгънәле исем кушарга кирәк.

3 нче әби. Элек исемнәрнең мәгънәсен карап кушканнар. Кызларга күбрәк чәчәк исемнәре бирелгән, чәчәк кебек матур булсын дигәннәр.

4 нче бала. Әбекәй, ә малайларга элек нинди исемнәр кушканнар соң?

3 нче әби. Ә малайларга тимер кебек нык булсын өчен Тимерхан, Биктимер, Минтимер кебек исемнәр кушканнар. Балалары бай булуын теләгәннәр Байбикә, Алтынбикә, Байбулат ише исемнәр сайлаган.

5 нче бала. Ә без бу нәниебезгә нинди исем бирербез соң?

Ана. Без балабызга Әмирхан исеме кушарбыз. Әмирхан – өметле, ышанычлы дигәнне аңлата. Әмирхан исемен йөртүче кеше – төгәл кеше. Ул кайда һәм ничек эшләргә кирәк икәнлеген һәрвакыт яхшы белә. *(Ана баланы бишеккә сала. Кечкенә бала елаган тавыш ишетелә. Экранда мулланың балага исем кушуы күрсәтелә.)*

Алып баручы. Бәйрәмебез кунаклары, әйдәгез, бергәләп җырлы-биюле уен уйнап алыйк. Әмирханыбыз да ишетеп ятсын әле.

(«Зәңгәр чәчәк» җырлы-биюле уены. Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәк ясый. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнә.)

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар,
Зәңгәр чәчәк ярата.

(Туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри.)

IV БҮЛЕК. ШӘХЕСЛӘР.

ЯЗУЧЫ ВАХИТ ИМАМОВНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Илфания НУРЕТДИНОВА,
Яр Чаллы шәһәренең
52 нче мәктәп китапханәчесе

Китапханәче. Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, укытучылар, укучылар! «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Г. Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, прозаик Вахит Имамов укучыларга «Татарлар Пугачев явында», «Сәет батыр», «Утлы дала» тарихи романнары, шулай ук «Нәзер» романы һәм башка әдәби әсәрләре аша яхшы таныш. Язучы онытылган һәм яшерелгән тарихны халкыбызга кайтару буенча зур эшчәнлек алып бара.

Укучылар белән әзерләгән бүгенге кичәбез язучының биографиясе белән таныштыру һәм аның кайбер әсәрләрен тәкъдим итүгә юнәлтелгән. Язучының күңел дөньясына рәхим итегез. *(Экранда Вахит Имамовның «Мәйдан» журналында басылып чыккан фоторәсеме.)*

1 нче алып баручы. Сезгә җиргә нык баскан гаярь ир-егет карап тора. Артында искиткеч табигать манзарасы. Тип-тигез үзәндә салмак агудан ямь тапмаган кебек, дөньяның тыныч битарафлыгын үз итмәгәндәй, бормаланып-бормаланып ага торган Сөн елгасы, баш очында – ак каурый болытларын фирүзә нурга төргән биек зәңгәр күк һәм шушы илаһилыктан кырыс тормыш чынлыгына кайтарган, күңелне сагайткан, дүрт сүз: «Бөркет кошлар кулга ияләшми!..»

Электән дә матур җирнең өсте
Матурлана төште тагын да.
Сәждә итәр әле бар табигать
Бу кешенең эше алдында.

Менә шушы манзара язучы, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Вахит Имамовның холкын, бар иҗатын ачып сала.

2 нче алып баручы. Вахит Имамов 1954 елның 18 мартында Сөн елгасына сыенып утырган Актаныш районы Иске Байсар авылында туа. Урта мәктәпне бик яхшы билгеләргә тәмамлаган егет Казанда моторлар төзү берләшмәсендә токарь булып беренче хезмәт чыныгуы үтә, эшчеләр дөньясында тормыш дәресләре ала. Армия сафларыннан кайткач, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. Балык Бистәсе районы газетасында хәбәрче, бүлек мөдире булып эшли. *(Ф.Сафин, «Мәйдан», №6, 2002)*

1 нче алып баручы. Вахит Имамов әдәбиятка сиксәненче еллар уртасында өлгергән прозаик булып килеп керде. «Ир канаты» исемле беренче китабы ук тәнкыйтьчеләр, укучылар тарафыннан җылы кабул ителде.

2 нче алып баручы. Шуннан соң язучы дөнья мәшәкатьләрен, гамь-бор-

чуларын бер якка куеп, Әбүгалисина кебек «мәгарәгә» – архивлар, китапханәләргә кереп бикләнде. Халкыбызның үткәне, канлы һәм шанлы чор-дәверләре язма хәзинә булып сакланган һәм гаделлек тантанасын көтеп яткан тарих көшеленә чумды.

Нәтиҗәдә, «Запрятанная история татар» исемле хезмәте 1993 елда зур тираж белән басылып чыкты. Язучы дәүләтен җуярга мәҗбүр ителгән татар халкының нинди фаҗигале язмышка дучар булуын аяусыз ачып салды. Карагруһчыларның өнен алган бу хезмәтне кайбер урыннарда өеп яндырганнар икән дип тә сөйләделәр. Әгәр хак икән, бу уңыш түгелмени?! Юаш-күндәм кол китабын өеп яндырганны тарих әлегә хәтерләми...

(Тарихи җыр башкарыла.)

1 нче алып баручы. Иҗат дөньясында үз кыйбласын табып, чирканчык алган әдип, үзендә тирән вә хәтәр хәтер чоңгылларына керергә көч-дәрман сизеп, эшкә тотына. Озак та үтми, 1994 елда зур тираж белән «Сәет батыр» китабы басылып чыга.

Бу әсәрдә язучы моңа кадәр беркем кузгатмаган һәм хәтта кузгатырга җөрьәт тә итмәгән бер хикмәтне ача: восстание барышында зур-зур гаскәргә тупланып, көч-корал дәһшәтен тойган татарлар җимерелгән ханлыкны яңадан торгызу омтылышына адарынып куя. Ул вакытта аларга Казанны алу, тәхетне кайтару шулкадәр якын тоела.

Вахит Имамов, бик күп архивларны өйрәнгән кеше буларак, Пугачев фетнәсе хакында моңа кадәр язылган бик күп хезмәтләрдәге ялган битлекне ача.

2 нче алып баручы. «...Кайчандыр, инде йөз еллар элек үк башкорт далаларында мондый кобайыр туган:

...Салаватның тугры дуслары –
Кинҗә-батыр белән Ханзафар,
Кыйгыр-бөркет булып, яу кыйратып,
Мәлгунь дошманнардан көл ясар...

Гади халык татар белән башкортның бергәлеген – дуслыгын йөз еллар элек үк шулай расланган.

(Экранда «Утлы дала» дигән язу чыга.)

1 нче алып баручы. 2001 елда Вахит Имамовның «Утлы дала» һәм «Могикан» исемле китаплары басылып чыга. «Утлы дала» романында әдәби геройлар булып дөнья тарихында калырлык дәүләтләр белән идарә итүче ханнар яки кенәзләр тора. Берләре Болгар дәүләте ханнары булса, икенчеләре – рус дәүләте кенәзләре. Бу – Андрей Боголюбский, Ясүгәй баһадир һәм Чыңгызханнар чоры.

(«Болгар төне» шигъри композициясе яңгырый.)

2 нче алып баручы. Романда гыйбрәт алырлык вакыйгалар һәр бәйләмдә дә җитәрлек бирелгән. Заманында яхшы яки яман аты белән данланган күп кенә дәүләт башлыклары, аларның гаиләләре исемнәре белән

китерелгән. Тарихи сюжетлар укучы хәтерендә тирән эз калдырырлык итеп сурәтләнеп бара

(Сәхнәгә сугышчылар чыга. Магнитофоннан кычкырыш, талаш, шомлы тавышлар ишетелә.)

Андрей. Алга, берсен дә кызганып тормаска!

Күчкәй. Туктатыгыз бу мәхшәрне, тимәгез балаларга, рәнҗетмәгез хатын-кызларны. Әнә, алыгыз алтыннарны, җыегыз көмешләрне, тик калдырыгыз безне!

Юрий. Ха-ха-ха… Бу байлык, бу авыл болай да минеке. Ха-ха-ха… Әнә шул каен ботагына асыгыз Күчкәй бәкне!

(Сәхнәгә ачы тавышлар белән елап Байгөл чыга.)

Байгөл. Әт-кә-ем, әткәем җаным! Җибәрегез аны, тимәгез!

Юрий. *(Юрий кенәз кылычы белән кызның ияген күтәрде.)* Атың кем? (*Сокланып карап тора.)* Чибәр үзе. Атың кем дим?

Байгөл. Байгөл.

Юрий. Минем киленем булырсың. Андрей, бирегә кил! Хатының үлеменнән бирле ничә ел буйдак булып йөргән идең, менә сиңа кәләш! Әниең кыпчак иде, хатының Болгар кызы булыр. Бу Болгар хатыны синең ике ятимә кызыңа да ана булыр. *(Байгөл җиңе эченнән хәнҗәр чыгара.)*

Байгөл. Мин үз-үземне чәнчермен, мәгәр әткәемне үтергән ерткычка килен булып төшмәм! *(Хәнҗәр очын бугазына тери.)*

Юрий. Төшәрсең, күгәрченкәем, әле сөенечеңнән елап, ялына-ялына төшәрсең. Агай-энеләреңне, барча авылдашларыңны суеп чыкканны теләмисең лә син. *(Чыгып китәләр.)*

2 нче алып баручы. Шул ук атнада Андрей белән Байгөлнең туе булды. Үзе белән сеңлесе Осланбикәне алып Байгөл калага – кенәз йортына күчте. *(«Гөлҗамал» җыры.)*

2 нче алып баручы. Рус җирендә сугыш-талашлар кабатланып тора. Андрей төрле уйлар белән баш ватып яши башлый.

Дүртенче бәйләмдә Ясүгәй (Есугей – Чыңгыз ханның әтисе) аудан кайтканда татар кызын мөркитләргә хатынлыкка алып китеп баручы туйны очрата һәм, кызның матурлыгын күреп, аны урларга ниятли.

Айлыбикә (кәләш исеме) озак вакытлар каршылык күрсәтә. Ясүгәйнең туганнары аның бу кызны урлавын ошатмыйлар, аннан аерылып китәләр.

1 нче алып баручы. Айлыбикә белән Ясүгәй 9 ай бергә яши. Магулларга кара татарлар һөҗүм итә. Ясүгәй кара-каршы сугышта Тимерҗанны үтерә. Тимерҗан үтерелгәч, кара татарлар сугышны туктатып кайтып китә. Шул көнне Айлыбикә ул таба. Малайга Тимерҗан (Тимучин) исеме бирәләр.

2 нче алып баручы. Тимучинга 9 яшь тулган көнне, ата-баба йоласы буенча кәләш яраштырга дип Ясүгәй юлга җыена.

Айлыбикә аларны елый-елый озатып кала. Чөнки әтисе, кәләшенә ияләшсен өчен, улы Тимучинны кодаларда калдырырга тиеш була.

(Сәхнәдә Ясүгәй юлчы, Тимучин, Ясүгәй кешеләре. Аларны татарлар урап ала.)

Ясүгәй. Мине бәгегез янына озатыгыз! Аңа минем 9 ел үстергән зур бүләгем бар. *(Тирмә эченнән берәү чыга.)* Мин бит Сәмыйк бәкне күрергә ниятләгән идем. Миңа Сәмыйк бәк кирәк.

Хуҗа. Сәмыйк бәк юк шул инде. Җәй башында сезнең чирү илә булган яуда аңа ук аттылар. Җәрәхәттән савыга алмады ул, менә бер ай тула булыр, мәңгелеккә күчте.

(Ясүгәй Тимучинның иңбашына кулын салды). Ә син Ясүгәй баһадир буласыңдыр, шаять?

Ясүгәй. Әйе шул, нәкъ үзе. Моны каян белдең?

Хуҗа. Мин сине бүген төштә күрдем. Шәхсән сине түгел, кабиләгезнең изге әмәле – сүлдәне күрдем мин. Аермачык күрдем. Сүлдәнең өске ягына бабаң Бәдуансар сөя торган шонкар сурәте төшкән, ә ул үзенең тырнакларына карга эләктергән иде. Сүлдәдә 9 чук бар. Һәркайсына ат кылы тагылган, алар җилдә җилфер-җилфер килеп уйныйлар иде.

Ясүгәй. Син моны нәрсәгә юрыйсың соң инде?

Хуҗа. Магул кабиләләренең тугызы да бүген таркалган, туздырылган хәлдә. Мәгәр кайчан да булса берзаманны тугыз кабиләгез дә күмәк сүлдә астын тупланачак. Мин шулай дип беләм.

Ясүгәй. Җылы сүзләрең өчен рәхмәт сиңа, хуҗа. Аларны мәңгелек Күк тәңресе ишетә күрсен. Син кем атлы буласың, мөхтәрәм бәк? Минем бабам хакында хатирәләрне кая ишеттең син?

Хуҗа. Мин Дәй атлы чәчән булырмын, батыр. Сине мондый ерак җирләргә нинди җилләр ташлады? Нинди йомыш шулай йөртә?

Ясүгәй. Менә улым Тимучинга кыз ярәшергә дип килгән идек.

Хуҗа. Син мәрхүм Сәмыйк бәккә кода тиеш идең, мәгәр туганлашу тәмен татып өлгермәдең. Инде улың Тимучин да шул кадердән мәхрүм булмасын, татар кавеме илә орыш-талаш кырында түгел, туй вә мәҗлесләрдә аралашып яши күрсен иде.

Синең Тимучиныңа тиң булырлык, унынчы яше белән баручы бер кызым бар минем. Аты Бөртек булыр. Шуңа күз сал. Җаның ята икән, ул киленең булсын. Бүген сезнең кабиләнең сүлдәсе төшемә юкка гына кермәгәндер. Ходай Тәгалә насыйп итә икән, әйдә, кодалашыйк… Кызым, Бөртек, кил әле монда.

(Сәхнәгә бала җитәкләп бер хатын керә. Ясүгәй кыз балага карап сокланып тора.)

Ясүгәй. Йә, Ходаем! Минем Айнулым – Айлыбикәм төсле үк татар кызы. Гәрәбәдәй саргылт чәч, саф күк йөзе кебек зәңгәр күзләр, аккош канаты шикелле ап-ак куллар. Күрәм, улым да үземнең яшь чагымдагы кебек гашыйк булды. Сөбханалла!

(Тимучин кызның кулыннан алып көлә-көлә йөгерешле уйнап кереп китәләр.)

1 нче алып баручы. Әсәрдә Тимучинның ачы язмышлы үсү еллары бик җентекле сурәтләнә. Нинаять, ул мең бәлаләр белән үзенең тугыз чуклы байрагы астына төрле кабиләләрне берләштеүгә ирешә. Хыялы – үзара кан коеп яшәгән халыкларны басып алу, тынычлык урнаштыру, дөньяны имин-бөтен итү. Аныңча, дөнья үсешенә каршы килгән сәләтсез халыклар рәхимсез кырылырга тиеш...

2 нче алып баручы. Романда, әнә шулай итеп, бүгенге көндә Россия дип аталган кыйтганың өч ноктасында яшәү дигән учак тергезелә, өч бәһадир халыкның яралу чоры сурәтләнә. Роман тәңренең тамгасы белән туган Тимучин атлы егеткә Чыңгыз дигән кодрәтле кушамат бирү белән тәмамлана.

Китапханәче. Вахит Имамовның кулымдагы «Нәзер» исемле китабы укучылар тарафыннан укылып, күргәнегезчә, инде таушалып та беткән. Ни өчен дигәндә, беренчедән, бу китапның басылып чыгуына егерме елга якын вакыт үткән, икенчедән, укучы тарафыннан җылы кабул ителгән ул. 1991 елда басылып чыккан бу китапка авторның «Күке», «Нәзер» кебек повестьлары һәм берничә хикәясе кергән. Әлеге җыентыктагы «Нәзер» повесте һәм «Өмет» хикәясе буенча Казан телевидениесе тулы метражлы нәфис фильм төшерде, һәм аның соңгысы телевидение буенча күп тапкырлар күрсәтелде дә инде. Ул чагында Вахит Имамовка нибары утыз җиде яшь кенә була. Яшь язучы өчен бу, әлбәттә, зур танылу. Хәзер сезнең игътибарга шул фильмнан өзек тәкъдим итәбез. *(Фильм күрсәтелә.)*

Вахит Имамовның соңгы елларда «Казан дастаны», Татар яугирләре» кебек китаплары дөнья күрде. Ул – татар халкының язмышына, үткәненә битараф кала алмаган, киләчәгә өчен борчылып иҗат итүче язучы. Хәзер сүзне аның үзенә бирик.

(Вахит Имамов сәхнәгә чакырыла.)

IV БҮЛЕК. ШӘХЕСЛӘР.

ЯНЫГЫЗ, ЙОЛДЫЗЛАР, ЯНЫГЫЗ ЯКТЫРАК, ӘДӘБИЯТ КҮГЕНДӘ СЕЗДӘЙЛӘР СИРӘК!

(2016 елда Габдулла Тукайның тууына – 130, Муса Җәлилгә – 110, Һади Такташка – 115, Фатыйх Әмирханга – 120, Сибгать Хәкимгә – 105, Габдрахман Әпсәләмовка – 105, Мөдәррис Әгъләмовка – 70, Рәдиф Гаташка 75 ел тулды. Шушы уңайдан әлеге әдипләребезнең әсәрләренә нигезләнеп төзелгән әдәби-музыкаль тамаша.)

(Бүлмә. Асрау кыз, «Бәйрәм бүген»не җырлый-җырлый, тузан сөртеп йөри. Ишек шакыйлар. Лиза килеп керә.)

Лиза. Биби, Хаечка дома?

Биби. *(Бакчаның челтәрле коймасы янына килеп.)* Хәят апа, Лиза килде! *(Бер минуттан соң бакчадан Хәятнең йөгереп чыкканы күренә.)*

Хәят. О, Лиза! Менә акыллы кыз, дустын онытмаган! (*Дуслар бик күптән күрешми торган шикелле кочаклашып күрешәләр.)*

Лиза. Әйе, дустым, мин сине кунакка алырга килдем.

Хәят. Юк, дустым, бара алмыйм, бердән, әтием җибәрми.

Лиза. Борһан Әхмәдович ачулана башласа, мине гаепле итеп күрсәтерсез, мин аннан үзем гафу үтенермен.

Хәят. Юк, дустым, беләсеңме, бүген су буенда кичке уен була, мин шунда барам. Хәзер кызлар да килеп җитә. Лиза, дустым, әйдә, безнең белән кичке уенга!

Лиза. Ой, дустым, нинди уен соң ул? Минем кичке уенда бер тапкыр да булганым юк бит. Кызык буламы соң анда? *(Асрау кыз тыңлап тора.)*

Хәят.
Күмәк бию, уен-көлке
Була кичке уенда.
Кызлар-егетләр җыела
Таллыкта, су буенда.
Җырлар, биюләр өзелмәс,
Шатлык өстәр гармун да,
Үкенмәссең, дустым, барсаң,
Кызык булачак анда!

Биби. Хәят апа, мин дә барыйм әле…

Хәят. Бик әйбәт, бергә барырбыз, бергә кайтырбыз.

(Еракта «Хәят, әйдә!» дигән кызлар тавышы ишетелә. Музыка. Кызлар чыгып китә. Су буе, табигать күренеше, кошлар сайрый. Бер төркем кызлар керә: Хәят, Миләүшә, Диләрә, Әдилә, Лиза, Биби, Гөлшәһидә, Айсылу.)

Миләүшә. Әй, кызлар, карагыз әле, нинди матурлык! Бигрәк ямьле инде урман-чишмә буйлары! Нинди гүзәллек, сокланып туймаслык! Ничек дигән әле бөек Тукаебыз? (Габдулла Тукайның «Шүрәле»сеннән өзек сөйли.)

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – «Кырлай» диләр;

Җырлаганда көй өчен, «тавыклары җырлай» диләр.
Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем;
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.
Ул авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халыкның эчкән суы бик кечкенә инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

Диләрә.

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, ганҗәләр.
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчәкләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчәкләр.
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп;
Киткән булып тагын да шунда чүгәләп.
Бервакыт чут-чут итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары…

Әдилә. Кызлар, шундый матур сөйлисез! Мин дә шундый матур шигырь беләм, сөйлимме, кызлар? Барыбер егетләр дә килеп җитмәгән әле.

Кызлар. Сөйлә, сөйлә.

Диләрә. (М.Әгъләмов «Шулкадәр»)

Шулкадәр гүзәллек, күзләр бәйләнә.
Шулкадәр саф һава – башлар әйләнә!
Шулкадәр дөнья тын. Колак сал! Шылт та юк,
Еш кына шомланып каласың, тукталып.
Шулкадәр иркенлек, иге-чиге юк,
Шулкадәр пакь җиһан, әйтерсең, чигүлек!
Безнең һәр эзебез барадыр чигелеп.
Шулкадәр яшәве рәхәт бит, шулкадәр!
Шулкадәр матурлык, шулкадәр гүзәллек!

Биби. Чыннан да, матур. Үзеннән-үзе җырлыйсы килә. *(«Туган авыл» җырын башкара, ул җырлап бетергәндә, шигырь сөйли-сөйли Такташ-Рәдис керә.*)

Рәдис. *(һади Такташ «Мокамай»)*

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын…
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар…
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары –
Андагыдай шаулый торганнар…

(*Кызлар, ул чыгып киткәч, бераз тын торалар*.)

Биби. Хәят апа, кем булды бу?

Хәят. Танымадыңмыни? Такташ үзе иде бит!

Биби. Ай-яй, матур сөйли!

(*Чиләк-көянтә белән урта яшьләрдәге ханым – Нурсия «Фазыл чишмәсе» җырын (С.Хәким сүзләре, татар халык көе) җырлап керә, су алган кыяфәт ясый.)*

Нурсия.

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем шул;
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.
Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән шул?
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән.
Кызарып янган шәфәкътән
Күзләрем алалмадым шул;
Тибрәнде телем әйтергә,
Сүзләрем табалмадым.
Чишмәгә төшкән сукмакның
Читләре үлән генә шул;
Вәгъдәм бар сиңа, белмәсен
Тик күрше-күлән генә. (*Җырның соңгы юлларына кызлар да кушыла.*)

Кичке уенга җыелдыгызмыни, кызлар? И-и-и, иң күңелле чагыгыз шул. Балалар, вакытында уйнагыз, җырлагыз, биегез, көлегез, яшьлекнең кадерен белегез. (*Көянтә-чиләкләрен күтәреп, басма аша чыгып китә, һәм, җырлап, егетләр килеп керә.)*

Егетләр.

Сандугачның балалары
Талга кунганнар икән.
Кызларыбыз бигрәк чибәр,
Бигрәк уңганнар икән. *(Соңгы 2 юл кабатлана.)*

Лиза. Менә тамаша, никадәр кеше, кайлардан җыелып беткәннәр болар, Хәят?

Хәят. Әйттем бит мин сиңа, дустым, күңелле булачак дип (*көлә)*. Безнең әниләр дә кичке уенда танышып кавышканнар.

(Егетләр керә.)

1 нче егет. Әйдәгез, егетләр, бер

биеп алыйк әле. Дустым, әйдә, гармуныңны сыздырып җибәр.

(Егетләр бии, кызларны чакыра.)

2 нче егет . Кызлар-егетләр, кичке уенны башлыйбыз! Нинди уен уйныйбыз?

– Сигезле!

– Бишле

– Чума үрдәк, чума каз.

3 нче егет . Әйдәгез , «Кулъяулык салыш» уенын уйныйк!

4 нче егет. Күрегез, миндә нинди матур кулъяулык!

Айсылу. Асия бүләк иткәндер инде.

(Түгәрәкләнеп басалар. Егет, бии-бии, кулъяулык сала, музыка туктый.)

Нияз.

Кулъяулыгың ак икән,
Бизәкләре вак икән.
Кулъяулыгыңны алып,
Кайчан чыгарсың икән.

(Кулъяулыкны алган кыз – Лиза уртага чыга.)

Азат. О-о! Кунак кыз! Кунак кызга нинди җәза бирәбез?

– Җырласын!

– Такмак әйтсен!

– Биесен, биесен! Рус кызлары ничек бии икән?!

(Лиза Ирек белән вальс бии. Кабат уйныйлар, Илсаф кала.)

– Кызлар, бу егеткә нинди җәза бирәбез?

– Әтәч булып кычкырсын!

– Йолдыз санасын!

– Шаян егет ул, шаян шигырь сөйләсен!

(Егет Муса Җәлилнең «Хәдичә» шигырен сөйли. Барысы да кул чабалар, уен кабат башлана, кулъяулыкны Зөлфиягә сала.)

Илназ. Егетләр, нишләтәбез?

– Сандугач булып сайрасын!

– Җырласын, җырласын!

(*«Серле йөрәк» җыры (М.Әгъләмов сүзләре, Р.Гатауллин көе) (Михаил керә.)*

Зөлфия. Сез кем?

Михаил. Мин – Михаил!

Лиза. О, абыем, мине эзләп килдеңме? Минем кайтасым килми әле, монда шундый күңелле! Таныш булыгыз, минем абыем – Михаил!

Михаил. Хәерле кичләр, матур туташлар һәм әфәнделәр! (*Хәят янына килеп)*. Кемне күрәм мин! Ничә җәй дә ничә кыш?! Бер кыш эчендә Сез, Хәят, танымаслык булып үсеп киткәнсез, тагын да матурлангансыз…

Хәят. Сез мине оялтасыз..

Михаил. *(Һади Такташ «Урман кызы»)*

Тарат, Хәят, озын чәчләреңне!
Алар тузып төшсен алдыңа,
Шулай килешә сиңа.
Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан агалар?!
(Михаил, уң кулы белән Хәятнең сул кулыннан йомшак кына тотып, уйчан гына тавыш белән). Ачуланмагыз, Хәят, мин Сезне сөям… Минем күңелемдә Сез генә…

Хәят. Сез бик мәхәббәтле! *(йөгереп китә.)*

Михаил. (*Рәдиф Гаташ «Егерме дүрт йолдыз һәм унҗиде диңгез»)*

«Хисләреннән шашкан» дисез, әйеме?!
Бер сүзем юк…
Мәхәббәтнең
Мәңгүн исемендәге премиясен
Бу ел өчен миңа бирегез, яме?!

Михаил. Егетләр, кызлар, нигә тынып калдыгыз әле. Нинди уен уйныйбыз? Ә бездә яшьләр «Почта уены» уйный…

– Нинди уен ул?

– Ничек уйныйлар?

Михаил. Егетләр һәм кызлар күзләре төшкән кешегә, хисләрен белдереп, хат язалар. Уйныйбызмы? (*төрле яктан «Әйе» дигән тавышлар ишетелә. Галиябану читкә китә, кызлар аны чакыра.)*

Әдилә. Борчымагыз аны, ул Хәлилен юксына.

Галиябану. *(Сибгать Хәким «Юксыну»)*

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән;
Син киләсе юлдан күзем алмый
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.
Яратам мин, әйтмим генә аны,
Син йөрәкне минем белмисең,
Кошлар кайта безгә, син һаман юк,
Син һаман юк, никтер килмисең.
Сагынуымны төннәр утырып язган
Хатлар гына басар дисеңме?
Юк, басалмый, сөйгән җырларыма
Сыйдыралмыйм хәзер хисемне.
Бу вакытлы гына юксынуым,
Дусларымның исе китмәсен;
Тик ярата белгән кеше генә
Сагына шулай үзенең иптәшен.

Әдилә. И-ии, дустым, шулкадәр сагынасың икән, җырла, син, дустым, җырла, җыр тынычландыра ул, җырлап күңелләр күтәрелә.

(*Галиябану җырлый. Егетләр, җыр беткәндә, тарткалашып китә, берсе икенчесенең хатын тартып ала.)*

– Нишлисең син, бир, миңа дигән хат бит ул.

(Тегесе бирми, тарткалашалар.)

1нче егет – Азат. (*Муса Җәлилнең «Бер үгет»шигырен укый.)*

2нче егет – Илназ. (*Рәдиф Гаташның «Ирләр булыйк»шигырен укый*.)

Ирләр булыйк, һәрвакыт һәм һәр адымда,
Малай чакта –
Уйнаганда,
Күккә карап төрле уйлар уйлаганда.
Кыйналганда.
Ирләр булыйк – үсмер чакта,
Беренче кат яратканда:
Яшьтәш кызыңа оялып бер көн аңлатканда.
Үпкәләшеп йөрешкәндә.
Килешкәндә.
Ирләр булыйк.

*(Гөлшәһидә бу егетләргә карап тора да: «*Уйныйсым килми», *– дип торып китә, алгы планга күчә, аның янына Мансур килә.)*

Мансур. Гөлшәһидә, хәтерлисеңме…

Гөлшәһидә. Хәтерлим, Мансур, айлы кич… Федосеев дамбасы…

Мансур. Әйе иң самими чаклар… Хәтерлисеңме?

Гөлшәһидә. (*Рәдиф Гаташ «Сөйлә» шигыре)*

Сөйлә! Мансур!
Бик күптәннән тавышың ишетмәдем.
Шундый тансык миңа!
Колак салыйм шатлыкларың чишмәсенә,нинди көчләр шулай күчкән сиңа? Мин бәхетле, тыңлыйм озак…
Сөйлә!
Сөйлә серләреңне, яшь җаныңда нинди хыяллар бар, сөйлә!
Язгы яңгыр кебек җылы сүзең –
чыланырга ризамын мин.
Кояш тә әнә чыгып килә, сөйлә!

Мансур. *(Рәдиф Гаташ «Янган йөрәк»)*

Янган йөрәк, сузылган кул –
Минеке,
Ике толым, кап-кара күз –
Синеке.
Ал йөрәгем! Бүгеннән ул
Синеке,
Синең йөрәк булсын ләкин минеке…
Син ризамы? Юк, дисеңме?
Синең эш.
Сөймә мине, оныт! Дисең?
Синең эш!
…Тик оныту һәм онытмау –
Минем эш.

Гөлшәһидә. Шигырьләр язуыңнан туктамагансың икән…

Мансур. Сиңа карагач, алар күңелдә үзенннән-үзе туа. Ә үзең, Гөлшәһидә, бик матур җырлый идең, җырла әле*!(Гөлшәһидә ялындыра.)*

Гөлшәһидә. Күптән инде кеше алдында җырлаганым юк.

Мансур. Сагындым, җаным, җырыңны! (*Гөлшәһидә җырлый. «Гөлшәһидә җыры» (Г. Әпсәләмов сүзләре, Ж.Фәйзи көе))*

Сызлама, әрнемә юксынып йөрәгем!
Сагынып, саргаеп өзелмә, үзәгем!
Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә,
Карлыгач шикелле кичекми һәр язда.
Ак күңел, пакь күңел, бу кадәр ярсыма,
Тилереп, шашынып дөньяны тарсынма.
Син чыда барсына сөюең хакына,
Ул килер, баш ияр бер заман каршыңда.
Хәзергә белми ул, хәзергә күрми ул
Янганың, көйгәнең гел аның утында.
Җил исә тын гына, ай йөзә моң гына,
Күңелдә ул гына, йөрәктә ул гына.

(Җыр барышында Михаил Хәятне биергә чакыра, Хәят, оялып, ризалашмагач, Лизаны чакыра, биилләр. Әтәч кычкырган тавыш ишетелә, Нурсия иртәнге су алырга чишмәгә төшкән.)

Нурсия. Абау, Ходаем, әле кайтмаганнар! Таң әтәчләре кычкырды бит инде, иртән торып, ындырга эшкә төшәсегез бар, әйдәгез! Әйдәгез, кайтыгыз!

(Егетләр һәм кызлар барысы бергә җырлый-җырлый чыгып китәләр. Сәхнәдә Лиза, Хәят һәм Михаил кала.)

Лиза. Хәят, дустым, мин шундый шат, миңа биредә шундый ошады! Рәхмәт сиңа! Икенче атнага безгә килерсең, дустым. Безнең дә бик матур уеннарыбыз бар. Килерсеңме?

Михаил. Хәят, мин сезне килеп алырмын. Ризамы?

Хәят. Ярый, килермен. Әйдәгез, кайтыйк.

Михаил. Кызлар, әйдәгез, мин сезне озатыйм.

(Хәят белән Лизаны култыклап чыгып китә. Музыка.)



IV БҮЛЕК. ШӘХЕСЛӘР.

САГЫНАЛАР СИНЕ ЯКЫН ДУСЛАР

(Сара Садыйкова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Венира ГАДЕЛШИНА,
Бөгелмә шәһәре 8 нче урта мәктәбенең I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Кичә барышы

1 нче алып баручы.

«Халык – зур ул, моңлы ул, шагыйрь ул». Моннан бер гасырга якын элек бөек Тукаебыз язып калдырган бу сүзләр үзенең асыл мәгънәсен һич-кайчан югалтмаячак. Ул халкыбызның моң чишмәсе, Татарстанның халык артисткасы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, композитор, җырчы Сара Садыйковага карата да әйтелгән кебек.

2 нче укучы.

Йөрәкләргә керә назлый күңелләрне
Сара апаның моңлы көйләре.
Кайдан килгән аңа моң бәйләме?
Гөлбакчадыр туган җирләре.
Сара апаның җыры яңгыраса,
Йөрәк хисләремне уята.
Уйландыра, җанны уята,
Күзгә яшь китерә, җылата.

3 нче укучы.

Күпме тыңлап, күпме хисләнсәм дә,
Аңлатырга сүзләр аз кебек.
Аның сүзе, аның моңлы көе
Гөрләп килгән ямьле яз кебек.
Онытылмас моңнар бүләк иттең,
Без җырларбыз синең хакында.
Китсәң дә кайтмас булып,
Зур мирасың калды халкыңа.

(Сара Садыйкованың «Вальс турында вальс» көе яңгырый, вальс бииләр.)

4 нче укучы. Татар халкының зур мәхәббәтен казанган композитор Сара Садыйкова 1906 елның 1 ноябрендә Казанда туа. Шул заманның данлыклы кызлар мәктәбе – Фатиха Аитова мәктәбендә укый.

5 нче укучы. Шушы чордан башлап, Сара Садыйкова җырлый. 1921 елны ачлыктан җәфа күргән кешеләр өчен хәйрия спектакле итеп куелган «Бүз егет» драмасында беренче тапкыр сәхнәгә чыгып, җырлап уйнала торган Сәхипҗамал ролен башкара.

6 нчы укучы. 1922 елда Сара Садыйкова, татар кызларыннан беренче булып, композитор Солтан Габәши тәкъдиме белән Мәскәүгә – П.Чайковский исемендәге консерваториягә укырга җибәрелә. Ул анда вокал буенча белем ала. 1934-1938 елларда шушы консерваториянең татар опера студиясен тәмамлый.

7 нче укучы. 30 нчы елларда Мәскәүдәге «Эшче» театрында, шулай ук татар драма театрында эшләп, С.Садыйкова күп кенә җырлы образлар тудыра. Гөлсем Камская, Хөсәен Уразиков кебек сәхнә осталары белән бер иҗат коллективында кайнап, Сара Садыйкова драма артисткасы буларак та уңыш казана. 1930 елны Казанга кайткач, аны Татар дәүләт академия театры хуплап кабул итә.

(Хәсән Туфан сүзләренә «Казан кичләре» җыры башкарыла.)

8 нче укучы. 1942 ел. Сара ханымның тормыш иптәше сугыш кырында. Сагышлы көннәр. Шундый көннәрнең берсендә Сара ханым Әхмәт Ерикәйнең «Көтәм сине» шигырен көйли башлый. Моңлы, талгын гына агыла торган җыр туа.

(«Көтәм сине» җыры башкарыла.)

9 нчы укучы. «Көтәм сине**»** тангосын язуы белән Сара Садыйкованың композиторлык иҗаты башлана. Үзенең иҗат гомерендә 400гә якын җыр, 30дан артык спектакльгә музыка, 2 музыкаль комедия, танго, вальслар иҗат итә композитор.

1 нче алып баручы. Гомәр Бәширов үзенең истәлекләрендә Сара Садыйкова турында болай ди: «Музыкаль әсәрләрне никадәр генә күп иҗат итмәсен, беркайчан да үзен дә, башкаларны да кабатламады. Һәр җыры кеше рухының нинди дә булса бер нечкә кылын чиртеп ала, уй-хисләрен уята».

2 нче алып баручы. Мәһшүр композиторның һәрбер җыры – матур тарих. Менә шуларның берсе – «Җидегән чишмә». Бу әсәр җырлар мәйданына чишмә булып бәреп чыкты һәм челтерәп ага да ага.

(Гомәр Бәширов сүзләренә «Җидегән чишмә» җыры башкарыла.)

10 нчы укучы.
Тормышны бик сөйгәнгәме,
Картаюны белмәде.
Гел унҗиде яшьтә иде
Сара апа йөрәге.
11 нче укучы.
Сагындыра, сагындыра,
Сагындыра Сара апа.
Еллар ераклашкан саен,
Юксыну хисе арта.
12 нче укучы.
Кемнәр генә сиңа табынмаган,
Кемнәр генә сине белмәгән,
Җир йөзендә бәлки юктыр татар,
Синең җырдан ярдәм күрмәгән.

1 нче алып баручы. «Җыр булмаса, кешенең йөрәге өши, кеше йөрәге туңа» дигән әйтем бар. Сара Садыйкова исә үзенең җырлары белән кешеләргә бәхет, җылылык, илһам өләште.

1 нче укучы.
Синең гомер берәү генә түгел,
Һәр буында кабат калкырсың.
Моңы белән җырны иркәләүче
Якты йолдыз булып балкырсың.

2 нче алып баручы. Сара Садыйкова – Татарстанның атказанган артисткасы. Аңа 1997 елда – халык артисткасы, 1984 елда – Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе исеме, 1990 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

1 нче алып баручы. 1986 елның 7 июнендә композитор, җырчы, актриса Сара Садыйкова каты авырудан соң вафат була.

2 нче укучы.
Изге җаннар җирдә кими бара,
Бәгырьләргә тагы кан сава.
Җырың гына калды микәнни соң,
Соңгы ядкарь булып дөньяга.
Киләчәкне күрер кешеләрнең
Кешелеген җирдә сакларга.
Мәңгелек җан иңдерергә иде
Синең кебек изге затларга.

3 нче укучы.
Күпме юксылларның йөрәк серен
Моң бишеккә салып тирбәттең.
И, моңлы кош! Син бит кешеләргә
Сандугачлар телен өйрәттең.
Сагына сине күлдә кыр казлары,
Сагына сине күктә тургайлар,
Сагына сине бөдрә ак каеннар,
Чишмә, сулар, кырлар, тугайлар.
(«Үз илемдә» җыры башкарыла.)
2 нче алып баручы.
Тылсымлы моңнар белән
Ул безне гашыйк итте.
Юк, үлмәде чал сандугач,
Моңнар эзләргә китте.

1 нче алып баручы. Халкыбыз үзенең кадерле Бибисарасын – Ак калфаклы сандугачын онытмас, мәңге сагыныр, юксыныр, аның җырларын, гүзәл моңнарын үзе белән киләчәккә алып барыр.

Татар халкы яшәгәндә Сара Садыйкова моңнары да яшәр!

IV БҮЛЕК. ШӘХЕСЛӘР.

ИЛһАМ ШАКИРОВ ЗАМАНДАШЛАРЫ ХӘТЕРЕНДӘ

(Җырчы иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Эльмира ХӘБИБУЛЛИНА,
Бөгелмә шәһәре 8 нче урта мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

(Кичә буласы залга мультимедиа тактасы, Илһам Шакиров портреты эленә. И.Шакиров язмасында «Татарстан – минем республикам» (Нәби Дәүли шигыре, Сара Садыйкова көе) җыры яңгырый. Бәйрәмчә киенгән укучылар чыга.)

1 нче укучы.
Илһам җырлый.
Илһам килгән
Дисәләр,
Бәйрәмнәргә
Әйләнәләр
Кичәләр.
Концертка дип,
Куба авыл
Тамырдан.
Җыр бит бездә
Бик тә яшьли
Кабынган.
Бишек җыры
Җырлап безне
Бакканнар.
Җырлап кына
Уятканнар
Ак таңнар.

2 нче укучы.
Атилла Расих дип болай яза: «Илһам Шакиров турында фикер бөртерле генә була ала: ул – моңарчы күрелмәгән, халык җырларын оста башкаручы җырчыбыз.

Миңа үз гомеремдә татар халкының бик күп җырларын тыңларга туры килде. Әмма Илһам кебек моңлы һәм нюансларын җиренә җиткереп чын татарча җырлаучыны белмим.

Яшә, Илһам!»

(Илһам Шакиров башкаруында «Сарман» җыры яңгырый.)

3 нче укучы.
Нәби Дәүли, «Җырчыга шагыйрь сүзе»

Туган җирең – Сарман ягы,
Дөньяның тын почмагында.
Бөтен Ватан сагышлары



Синең татар җырларыңда.
Нинди авыл, шәһәрләрне
Узмадың син юлларыңда.
Татарстан чәчәкләрен
Йөретәсең җырларыңда.
Тыңлый сине Урал, Себер,
Казах тыңлый кырларында.
Таулар үтеп, сулар кичеп
Дуслык бара җырларыңда.

4 нче укучы.

Кемнәрнеңдер аһ-зарлары
Синең тавыш чыңлавыңда.
Бәхет куандырып
Шатлык туа җырларыңда.
Туган илгә чын мәхәббәт
Яши синең уйларыңда.
Илһам дигән исемеңә
Лаеклы син җырларыңда.
Гади сүзне син җыр иттең
Йөрәгеңнең кылларында.
Шагыйрь йөри синең белән,
Дустың булып җырларыңда.

5 нче укучы.

«Сарман якларында Яңа Бүләк дигән авыл бар. Аның табигате искиткеч, һәм менә шушы табигать ничәмә-ничә гасырлар җыйган моңны сиңа, кадерле якташым, бүләк иткән. Әгәр дә тагын йөз, ике йөз ел эчендә бу авылдан бер генә әдәбият-сәнгать кешесе чыкмаса да, халык рәнҗемәс. Чөнки – син бар! Яңа Бүләк авылы дигәч тә, күз алдына син килеп басасың. Авылың, аның шаулы урманы, чәлтер чишмәләре, чәчәкле аланнары сиңа моңын да, сагышын да, шатлыгын да жәлләмичә, кочагы белән биргән. Ә син аларны менә ничәмә дистә ел инде, йөрәгең аша үткәреп, яңадан халыкка өләшәсең. Ләкин инде Яңа Бүләк, Сарман халкына гына түгел, ә бөтен Татарстанга, туган илебезгә...» – дип яза Рәфкат Кәрами.

(Илһам Шакиров башкаруында «Туган авылым» җыры яңгырый.)

6 нчы укучы.

Илдар Юзеев, «Илһамга ничә яшь?»

Илһам Шакировка ничә яшь соң?
Нинди уйлар аның башында?
Халык яшәгәндә – яшәр моңы,
Илһамыбыз – халык яшендә.
Борынгы да үзе... Киләчәк тә...
Тоям шул чишмәнең кипмәсен.
Һәр кешенең йөрәгенә һәр көн
Илһам килсен, Илһам китмәсен!

7 нче укучы.

Салих Баттал, «Кышкы күкрәү»

Сиксән бишенче ел. Февраль.
Ап-ак кар җирне япкан.
Кинәт күк күкри сыман...
Каранам тирә-якка...
Һәм күркәм – шөһрәтле дата, –
Илһам Шакировка – Сиксән!
Димәк, ул җырлары белән
Шулай күкрәп килде!
Әйе, аның яз тавышы –
Кышкы күк күкрәвендә,
Кайтаваз булып яңгырый
Минем күкрәгемдә.
Кабыргама тибә йөрәк,
– Чыгасым килә! – ди ул, –
Бу дөньяга Илһам булып
Туасым килә! – ди ул.

8 нче укучы.

«Җырлый башлаганына ничә ел икән? Хәер, аны-сы нигә кирәк? Талантның гомере календарьларда күрсәтелгән вакыт белән билгеләнми. Әнә Тукаебыз, Сәйдәшебез һаман да исән. Мин Илһамның да гомере шулай озын булачагына ышанам», – дип язган үз вакытында Туфан Миңнуллин.

(Илһам Шакиров башкаруында «Яшьлегемә кире кайтыр идем» җыры яңгырый.)

9 нчы укучы.

Шәүкәт Галиев, «Илһам Шакировка – халкыбызның бөек улына, XX гасырда яңгыраган моңлы авазына...»

Ишеттем мин читтә «Туган тел»не,
Халкым, нинди моңлы көең бар...
Тукаемны йотылып тыңлаганда
Тамагымда кайнар төер бар:
Кем ничектер, әмма мин бу җырны
Тыңлыйм да гына тыңлыйм, туялмыйм.
Әсәрләнәм сабый бала кебек,
Ир булсам да, яшем тыялмыйм!...

10 нчы укучы.

«Дөньяда җырчы тавышы булган кешедән дә бәхетлерәк берәү дә юктыр. Чөнки ул күңел түрендә сакланган иң изге тойгыларын гажәеп бер ихласлык белән, турыдан-туры әйтеп бирә ала.

Илһам Шакиров – шундый кеше.

Ул берничә дистә ел буенча халкыбызның күңел хәзинәсен, мең еллык рухи байлыгын дөньяга житкереп килә.

Тукайдан һәм Сәйдәштән соң татар халкының нәрсәгә сәләтле икәнен кабатланмас таланты, табигать бүләк иткән моңлы-самими тавышы белән яңа катламнарда ача алды.

Әгәр без үзебезне интеллигент-зыялы дип саныйбыз икән, халкыбызның күренекле улы, гражданины Илһам Шакиров башкарган титаник хезмәт алдында баш иярга бурычлыбыз». (Гариф Ахунов)

11 нче укучы.

Батулла, «Татар халкының Илһамына бер сүз»

Халкыбызның өч Тукае бардыр.
Беренчесе – Тукай үзе.
Икенчесе – Сәйдәш.
Өченчесе – син, Илһам.

(Илһам Шакиров башкаруында «Туган тел» җыры яңгырый.)

12 нче укучы.

Әминә Бикчәнтәева, «Җырла әле»

Җырла әле, Илһам, «Карурман»ны,
Синең җырдан хисләр уяна.
Җырла әле, Илһам, «Сандугач»ны,
Сокландырып кошлар дөньясын.
Син бит, Илһам, сөйгән җырчыбыз да,
Дустыбыз да булып яшисең,
Синең күңелең гел яхшылык тели,
Ялкынланып кайчак яшьнисең.
Минем «Кулъяулык»ны җырладың син,
Күңел биреп һәрбер сүзенә.
Чын күңелдән шуңа аналарча
Рәхмәт әйтәм, энем, үзеңә.

13 нче укучы.

Ләис Зөлкәрнәй, «Теле булып та...»

Карурманнар шавы бу тавышта...
Ташмас җаны, мөлдерәп тулмаса.
Эндәшәлми халык кадәр халык,
Теле булып та, тавышы булмаса.

(Илһам Шакиров башкаруында «Карурман» җыры яңгырый.)

14 нче укучы.

Әсрар Гали, «Җыр хәзинәсе»

Илһам Шакиров дидеңме – бу җыр! Сихри моң. Тоташтан моң. Һәр буының, күзәнәгең калтырый. Син үзеңне онытасың. Шул сихри моңга эрисең. Шул йомшак дулкында агып барасың, дөньяны иңлисең сыман. Рәхәт моң. Бер дә туйдырмый торган моң. Көчле җыр. Матур җыр. Син үзеңне бу якты дөньяда күкләргә ашкан иң бөек зат итеп хис итәсең! Пәйгамбәр! Фәрештә кебек. Җыр шул кадәр тибрәтә сине, айга, йолдызларга менәсең. Ай, мәгърур татар моңы менә нинди көчкә ия бит ул дип, гомерлеккә шатланасың. Моннан да зур тәэсир көченең булуы мөмкин түгел... Газиз халкым татарда гына булган шул моң белән көчле бит ул. Моң аны яктырта, сагышларын аралый. Моңы көчәйтә татарны. Шатландыра. Шул моң аны киләчәккә өметле итә. Ышандыра...

15 нче укучы. Илһам Шакиров – янар таулар ул! Сез янар тауларның күгелҗем-яшькелт, зәңгәрсу-аксыл булып янганын җәен алсу таңнарда күзәткәнегез бармы?! Мин, шахтада эшләгән кеше буларак, моны үзем күреп беләм. Тетрәткеч матурлык бу. Тетрәткеч дөнья. Аларда мең төрле төс балкый. Шахтадан кеше чыгарган ташкүмер-порода утлары бу. Кеше тапкан кояш. Ул тауларның түбәсе болытларга аша. Илһам җыры шул янар таулар яктылыгы кебек күңелгә якын, күңелгә кадерле...

16 нчы укучы. Илһам Шакиров – карурман ул! Урманны гизеп кемнең туйганы бар?! Урманда – шомырт, миләш, балан, чикләвек, усак, юкә, каен, имән агачлары. Кура җиләге, бөрлегән, каен җиләге, җир җиләге. Какы, сәрдә, кузгалак, күке башы, яшел печән, сусыл үлән. Песнәк, саескан, тукран, урман тавыгы. Менә төрле бөҗәкәләр. Хуш исле чәчәкле аланнар. Зәңгәр күк йөзе. Сулап туймаслык саф һава. Әле без санамаганнары, санап бетерергә мөмкин булмаганы әллә никадәр. Илһам моңы белән күңелләребезгә иңгән «Иске карурман» җыры менә боларның һәм-

мәсен берләштерә. Карурманлы халык – бәхетле халык. Ул мәңге яшәячәк. Күңелләребезгә карурман нурын өрүче Илһам Шакировы булуы белән бәхетле безнең татар халкы.

17 нче укучы. Илһам Шакиров шаулы диңгез, төпсез океан ул! Диңгезче буларак беләм мин, диңгез-океанның бер җире тын торса да, икенче, өченче урыны аның илерә. Тау-тау дулкыннар куптара. Андагы көч, ярсу, кодрәт, табигатьнең үзеннән башка беркем тыешлы түгел. Бу бер Алла үзе биргән сихри көчне кешелек дөньясының әле файдалана белгәне юк. Илһам Шакировның «Әдрән диңгез» җыры еракларга шаулап ишетелә.

18 нче укучы. Илһам Шакиров – чәчәкле яшел болын ул! Анда – ал, яшел, зәңгәр, кызыл, күк, сары, күгелҗем, чәчәкләр чагылышы. Аны берәү дә, менә шул чәчәк, дип өзеп кенә әйтә алмас. Аның барлык төр чәчәкләр җыелмасы булуы – безнең өчен бәхет тә. Ул чәчәкләргә карап күзләр туймый. Чәчәк исенә күңел сусап яши. Сулап туешлы түгел…

19 нчы укучы. Илһам Шакиров – ургыл елга ул! Биек-биек таулардан агучы ургыл сулы елга, беркайчан саекмый, тизлеген югалтмый. Ашкына-ашкына алга таба ага. Шуңа күрә дә Илһамны куып җитәрлек җырчы юк әлегә. Яңа җырчы исеме ишетелдеме, аны Илһам Шакиров белән чагыштырып бәялисең. Башка үлчәм юк әлегә.

20 нче укучы. Гармун-гармун инде ул, диючеләр дә бар. Мин гармун булып идем дип тә әйтәләр. Әмма «Җыр!» диделәрме, иң беренче булып Илһам Шакиров күз алдына килә. Илһам – бөтен дөньядагы тау-тау алтын-көмешләрдән дә кыйммәт булган моңлы җыр ул! Җыр хәзинәсе…

(Илһам Шакиров башкаруында «Татарстан – минем республикам» җыры яңгырый.)

IV БҮЛЕК. ШӘХЕСЛӘР.

ЯЗУЧЫ АЙДАР ХӘЛИМ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Илфания НУРЕТДИНОВА,
Яр Чаллы шәһәре 52 нче мәктәп китапханәчесе.

Кичә барышы

(Сәхнәдә татар милли киемендәге егет «Фатиха» сүрәсен укый.)

Китапханәче.

Бәхет, тәүфыйк сорыйм Ходаемнан,
Дога белән көнем башлана.
Абынсам да, беркөн егылсам да,
Рәхмәтеңнән, Ходаем, ташлама.

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар һәм укытучылар! Иманыбыз, телебез, милләтебез, тарихыбызны саклауда, аны киләчәк буыннарга җиткерүдә күренекле публицист язучы, трибун шагыйрь Айдар Хәлимнең тырышлыгы гаять зур. Бүгенге кичәбезне өлкән прозаик, шагыйрь, драматург – бик күп китаплар авторы Айдар Хәлимгә багышлыйбыз.

1 нче алып баручы. Айдар Хәлим куе, серле урманнары, җырларда җырлана торган Агыйдел, Сөн елгалары белән горурланырлык Башкортстан Республикасының татарлар күпләп яшәүче төбәге – Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында 1942 елның 1 гыйнварында дөньяга килә. Ул чакта бу авылда башлангыч мәктәп эшләп, булачак язучының ата-анасы шунда мөгаллимлек итә. Айдарга белемгә омтылышны да алар сала. Балачактан китап яраткан Айдар Бәләкәй Керкәле мәктәбендә башлангычта укыганда да, Олы Керкәледә сигезьеллык белем алганда да китаптан аерылмый. Кыргыз-Миякә урта мәктәбен тәмамлаганда авыл китапханәсендә ул укымаган китап калмаган була инде.

2 нче алып баручы. Айдар Хәлим, хәрби хезмәттән кайткач, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга килә һәм аны уңышлы тәмамлап чыга. Университетта белем кыясын яулаганда ук ул хезмәт кешесенең тормыш-көнкүреше белән якыннан таныша башлый. «Үз гомеремдә миңа төрле эшләрдә: студент елларында Казанда – төнге сакчы, урам себерүче, Түбән Камада техник хәбәрләр буенча инженер, радиода мөхәррир, төзелештә балта остасы, Уфада – газета журналисты, Урал – Себер нефть үткәргеч идарәсендә өлкән инженер, Башкорт академия театрында әдәби бүлек мөдире, Чаллыда – «Аргамак» журналының баш мөхәррире булып эшләргә туры килде», – дип яза Айдар абый үзенең тормыш университетлары турында.

1 нче алып баручы. Айдар Хәлимнең әдәбияттәге юлы студент елларында шигырь язудан башлана дияргә була. Шигырь ул – кешелекнең мәңге сабый чагы. Ул картая белми торган яшьлек, саргая белми торган гөлбакча. Шагыйрь образлар йолдызлыгы белән эш итә. Дөньяны яңабаштан, бөтенләй көтелмәгәнчә, бары тик кабатланмас образлар системасы аша ача алган шагыйрь генә чын һәм зур шагыйрь булып санала ала. Бу бәхет сирәкләргә генә насыйп була. Айдар Хәлим менә шундый бәхетлеләр арасында.

2 нче алып баручы. Шагыйрьнең «Шигырьгә үтенеч» шигырендә авторның үз биографиясе чагылып китү белән бергә, аның шагыйрьлек миссиясен гаҗәеп югары дәрәҗәдә аңлавын да күрәбез.

Атын-алтын калдырмаган әти,
Похоронка бары калдырган.
Әни исә:
– Нәҗми үлмәс! – дигән.
Похоронканы да...
Яндырган.
Морза улы түгел – крепостнойлар
Минем өчен иген икмәгән.
Таулар мине, ачка үлмәсен дип,
«Балтырганлы Кул»га бикләнгән.
Жуковский, Державиннар өйгә
Килеп йөремәде үскәндә:
Жиде яшьлек сабый, кәҗә имеп,
Тузан эчеп, көтү көткәндә,
Миннән моңлы җырлар җырлатты да,
Киткән агайларга алмашка, –
Кояш үзе чыбыркы шартлатып,
Алып менде мине Парнаска...

2 нче алып баручы. *(Дәвам итә.)*

Мин Парнасны күрдем – шарты катгый,
Әмма Парнас миннән уңмады:
Җырлап яшәргә дип хыялландым,
Тик җырлап һич яшәп булмады...
Заман миңа «Талант– шартсыз», – диде,
Пегас ярсый сабан тартканда.
Шигырь яздым эшкә барган чакта,
Шигырь яздым эштән кайтканда.
Җирем, халкым!
Үләнем, игенем!
Артка этеп юк-бар юрауны,
Бер тын белән тамагыма алдым
Сезгә диеп төшкән кырауны...
Ун гаделсез дан-мал бүлешкәндә

Бер гаделне яклап калыктым.
Заман диеп,
Иман диеп, Парнас,
Мәңгелеккә синдә карлыктым…
Ә шигърият өчен плебейлар юк.
Ул – хәерсез, белми кызгану.
Чәчкә күзләвенә тамган чык та,
Чык түгел ул … Ул да – сызлану!

3 нче алып баручы. Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзе бер утрау кебек. Ачылмаган утрау… Язучы кайчан гына һәм нинди генә жанрда иҗат итмәсен, аның каләме һәрчак шагыйрь каләме булып кала.

Сүзләрем минем
Челтер-челтер аккан
Шарлама чуерташлары булып
Ялтырасын иде.
Сүзләрем минем
Корычларда чыңлап
Яңгырасын иде, – дип шигырияткә атылып килеп кергән Айдар иҗат юлының барлык борылышларында үзе куйган шул максатка тугрылык саклый. Еллар узган саен, шагыйрьнең каләм очындагы булат корычы ныграк чыңлый.

(«Татарлар, берләшегез!» җыры яңгырый.)

1 нче алып баручы. Айдар Хәлим диюгә, татар халкының ачы да, шанлы да булган язмышын үзәккә куеп, көрәш рухы белән сугарылган шигырьләр иҗат итүче трибун шагыйрь күз алдына килә. Әмма аның шигыриятә туган төбәк, табигать, мәхәббәт образларын кайнар хис белән сурәтләгән лирик әсәрләргә дә бай.

(Талгын гына музыка уйный.)

2 нче алып баручы.

Әй, Изге йолдызлар иле! Син минем туган ягым,
Хуш исле юкә бишекне көмеш дип таныган чагым…
Һәр ташың, җирем тарихтан җиткерә сихри аваз,
Тыңла да ятып шул ташны, либретто, опера яз!
Һәр тарафың чәчкәлек, һәр төшең төгәл, камил;
Һәр кешең миңа туган: булсын Камил, булсын Шамил….

Иҗатының тәүге чорында язылган «Туган җиремә» шигырендә автор үз укучысына табигатьтәге бөек гармониянең, якташ-тиңдәшләргә мәхәббәтнең кешегә яшәү куанычы бирүен нечкә образлар аша җиткерә. Бу шигърият. Талантлы шагыйрь генә дөньяга шул рәвешле сокланырга мөмкин.

– Айдар абый, хәзер башкарылачак башкорт халык биюе сезне туган якларыгызга, бала чакларга, яшьлегегезгә алып кайтыр дип көтәбез.

(Башкорт халык биюе башкарыла.)

3 нче алып баручы. Татарстаннан туган Башкортстанына кайтып эшли башлагач, язучының иҗат офыгы тагын да киңәеп китә. Уфада Айдар Хәлимнең бер-бер артлы «Беренчеләр» (1974), «Йөрәгемдә җитмеш параллель» (1978), «Мәхәббәттән язмыш башлана» (1982), «Таң сәфәре» (1985) китаплары басылып чыга. Казанда исә «Милли шигырьләр» (2001), «Тилергән сирень» (2003), «Печән чапканда» (2004) кебек шигырь китаплары дөнья күрә.

1нче алып баручы. Шагыйрь, шигырь кысаларына сыя алмагач, прозага күчә. Соңгы ике дистә елда ул дистәләрчә хикәя-повестьлар иҗат итә. Төрле нәшриятларда чыккан бик гыйбрәтле «Татар вакыты» романын, тетрәнденгеч «Книга печали, или Записки аборигена» һәм «Гомеремнең ун көне», «Этот непобедимый чеченец», «Убить империю» исемле публицистик китаплары укучыга барып җитә.

Шигырь. «Үзем турында»

– Акыллы бул! – диләр миңа кайчак.
Оныталар –
Акыл шуңа кирәк, кемдә – юк;
Мин акыллы диеп,
Милли хисләремнең
Гөлбакчасын таптар хакым юк.
Күпләр миңа: «Тыйнаграк бул», – диләр,
«Тыйнак эшлә, – диләр, – эшеңне…»
Ә мин әйтәм:
«Сезнең җебегәнлек беркайчан да
Күтәрә алмас минем исемне!»
Яшермичә эшлим эшемне,
Куәтемне тоям, көчемне.
Кемгә бирим ташкан хисемне?
Минме әллә милләтләрне сөймим?
Минме әллә дуслык хәтәр дим?!
Планетага яланаяк басып:
– Бар халыкны сөй син, татар! – дим.
Бар халыкны сөй син, татар, – дим.
Дуслар белә – юкка вакланмыйм.
Чәчкә атсын бөтен дөнья, дим,
Чәчкә атсын гүзәл Ватан, дим.

(Татар халык биюе башкарыла.)

2 нче алып баручы. Соңгы елларда язучы «Казанбаш», «Кыяр караклары» китаплары белән балаларны да сөендерде. Хәзер әнә шул китаплардан өзекләр тәкъдим итәбез.

(Өзекләр сәхнәләштерелә.)

1 нче алып баручы. 2008-2009 елларда язучының иҗатын яңа яктан укучыга бөтен тирәнлеге белән җиткерерлек бер вакыйга булды. Аның повесте буенча татар телендә эшләнгән беренче тулы метражлы «Өч аяклы ат» нәфис фильмы Казанда узучы «Алтын мөнбәр» Халыкара мөселман кинофестивалендә җиңү яулады.

2 нче алып баручы. Узган уку елында Чаллы мәктәбе укучылары Сара Садыйкова исемендәге концертлар залында фильмны халыкка тәкъдим итү тантанасында катнаштылар. Яшь буынны тәрбияләү ягыннан да, табигатькә, кеше хисләренә сак мөнәсәбәт тәрбияләү ягыннан да әлеге фильмның көче бик зур. Безне бигрәк тә анда катнашучы геройларны авыл мәктәбендә укучы балаларның оста уйнавы әсир итте.

Китапханәче. Хәзер кадерле кунагыбыз язучы Айдар Хәлимне сәхнәгә чакырабыз. *(Айдар Хәлим сәхнәгә күтәрелә. Кичәдә катнашучылар аңа үзләрен кызыксындырган сорауларны бирә.)*

IV БҮЛЕК. ШӘХЕСЛӘР.

ЯШИ АЛМЫЙМ ШУЛ МИН ЯНМЫЙЧА...

(Әдип Шәйхи Маннур иҗатына багышланган әдәби кичә)

Рәйсә ӘХМӘТҖАНОВА,
Мамадыш шәһәре беренче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Әдәби кичә барышы

Сәхнә түрендә «Шәхесләрне бирә мизгелләр» китап күргәзмәсе куела. Кичә дәвамында Шәйхи Маннурның тормышын, иҗатын, эшчәнлеген чагылдырган фотолар һәм рәсемнәр тәкъдим ителә.

(*Салмак кына татарча көй яңгырый.*)

1 нче укучы.
Тарих битләрендә дан казанган,
Батыр милләт без бит ул – татар.
Шул милләтнең олы горурлыгы –
Якташыбыз Шәйхи Маннур бар.

2 нче укучы.
Бик таләпчән, тирән эз калдырган
Олы шәхес данын зурлыйбыз.
Илнең һәрбер почмагында бүген
Аның сүзен, җырын тыңлыйбыз.

3 нче укучы
Безнең халык горурланып сөйли
Казан арты, Тукай-Кырлайны
Һәм онытмас телен хөрмәтләүче
Якташыбыз Шәйхи бабайны.

4 нче укучы
Шәйхи Маннур күңел түребездә,
Тик сагышлы чишмә, инешләр.
Алгы буыннарга мулдан иңде
Ул калдырган затлы җимешләр.

Алып баручы.
Бу шигырь юлларын Вахит Галиев олуг шагыйрь, прозаик Шәйхи ага Маннурга багышлап иҗат иткән. Без

бүген сезнең белән күренекле язучы Шәйхи ага Маннурның туган көне уңаеннан аның тормыш юлы, иҗаты белән танышырбыз.

«Күңел һаман сиңа тарта».

Күңел һаман сиңа тарта,
Эндәшә һәр сукмагың.
Сагынам да сиңа кайтам,
И, газиз туган ягым!
Кошларың күп,
Кояшың күп,
Шифалы яңгыр, җилең.
Беркайда да булмаган күк
Бар җирең матур синең.
Яланнарга чыгып йөрсәм,
Алсулана йөзләрем.
Чишмәләрнең суын эчсәм,
Кайта яшьлек көчләрем.
Киң, бөек Туган илемнең
Син – гүзәл бер почмагы.
Синдә үтте гомеремнең
Канатлы сабый чагы!

Туган җир. Туган авыл. Йөрәккә якын һәм кадерле сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, йортыбыз урнашкан кадерле авылыбыз, шәһәребез бар. Һәр авылның үзенә генә хас, сокланып туймаслык урыннары күп. Кая гына барсак та, нинди генә урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезне берни алыштыра алмый. Шәйхи ага Маннур туып үскән Тулбай авылы да искиткеч матур җирдә урнашкан.

Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров 1905 елның 15 гыйнварендә ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы Тулбайда ала. Күршедәге Шәмәк авылында «икенче баскыч» мәктәбен тәмамлагач, Мамадыш педагогия курсына мөгаллимлеккә укырга керә. 1921 елның җәендә ачлык гарасаты аларның гаиләсен, туган якларын ташлап, Кузбасс шахталарына китәргә мәҗбүр итә. Шул чакта 16 яшьлек Шәйхелисламның – булачак әдипнең «тормыш университетлары» башлана.

(Ш.Маннур сүзләренә язылган «Шахта»жыры башкарыла.)

«Котлыйм сезне, дусларым».

Әйе, Шәйхи аганың биографиясе күпкырлы. Ул Тубыл, Свердлау, Донбасс, Троицк, Минск, Мәскәү, Казан шәһәрләрендә яшәп, шахтер, эшче -прокатчы, укытучы-ликбезчы, журналист, профессиональ язучы була. Аның «Гайҗан бабай», «Меңнән бер кичә», «Каз көтүче малай» поэмалары хезмәт кешесенең күңел көрлеген, җиңелмәс рухын тасвирлый.

(«Каз көтүче малай» поэмасыннан өзек сәхнәләштерелә.)

Алып баручы. 1941-1945 еллар – әдипнең фронт еллары. Бөек Ватан сугышы башлану белән ул, үзе теләп, яуга китә, армия газеталарында хәрби хәбәрче булып хезмәт итә. «Гайҗан бабай бүләге», «Казан кызы» поэмаларында Шәйхи ага яу кырындагы татар кызларының батырлыгына, тормышка мәхәббәтенә соклана, аларның шәфкатьлеген данлый.

5 нче укучы.

«Казан кызы».

Сез йөрисез үлем кырларында
Чын сугышчы егет шикелле.
Мәхәббәт һәм шәфкать белән безгә
Сез җиңәсез шыксыз үлемне.
Сугышларда безне саклар өчен,
Ут эченә барып керәсез.
Кирәк чакта, һичбер кызганмыйча,
Гомерегезне хәтта бирәсез.

Алып баручы. Язучы иҗат иткән проза әсәрләре арасында иң күренеклесе – язучының яшьлек дусты, легендар шагыйрь Муса Җәлил турындагы «Муса» романы.

Җәлил гомере җәйге яшен сыман,
Ут уйнатты көрәш кырында.
Ут уйнатып сүнде … эзе булып,
Җыры калды үткән юлында, – дип яза Шәйхи Маннур бу әсәреның герое турында.

1970-1976 нчы елларда иҗат ителгән «Агымсуларга карап» исемле автобиографик, «Чын сөю бармы?» исемле лирик повестьлары белән Шәйхи Маннур үзен талантлы прозаик, зур каләм остасы итеп таныткан.

6 нчы укучы.

«Агымсуларга карап».

Узган саен гомер юлын һаман
Каерылып карыйм артыма.
Иң кадерле чаклар шунда калган
Һәм манылган бар да алтынга.
Кайгы да юк анда, хәсрәтләр дә,
Сагышлар да үзәк өзмәгән.
Күрелмәгән газап-михнәтләр дә…
Гел гизелгән зәңгәр эзләрдән.
Нигә шулай һаман сагындыра,
Ник күңелем шунда тартыла?
Гомернең шул газиз чагын гына
Бер күрәсем килеп,
Әйләнәм дә карыйм артыма.

(«Яратам» (Ф. Хатыйпов көе, Ш.Маннур сүзләре) җыры башкарыла.)

Яратам мин өемне,
Әти белән әнине,
Абый белен энемне,
Бишектәге сеңлемне.
Яратам мәктәбемне.
Укытучы апамны,
Дусымны, иптәшемне,
Уйнап йөргән бакчамны.
Яратам мин Иделне,
Кавказны һәм Себерне,
Яшәгән киң җиремне –
Бөек туган илемне!

Алып баручы. Шәйхи Маннур балалар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертте. «Олаучы малай» романтик поэмасы, «Миләүшә», «Нәниләргә – дусларга», «Күгәрченнәр гөрләгәндә» һ.б. китапларын балалар яратып укый. Әсәрләре мәктәп программасына кертелгән. «Уку китабы» аның сүзләре белән башлана:

«Исәнмесез, минем шаян дуслар,
Хуш киләсез, рәхим итегез!
Кулга тотып белем ачкычларын
Я, әйдәгез, түрдән үтегез!»
Китап шагыйрьнең:
«Сау бул инде көзгә хәтле,
Китәбез, мәктәп, синнән.
Көтә безне җәй рәхәте,
Ул безнең өчен килгән», – дигән шигыри юллары белән тәмамлана.

7 нче укучы

Ана теле, гаҗәеп һәм кыйммәтле серләрне кадерләп, гасырлар буена халыкның рухи мирасын саклап һәм үстереп килә. Шәйхи Маннур шигырьләрендә дә туган телгә мәхәббәт, ихтирам урын алган.

Шигырь укучы.

Мин сөйлим анам телендә,
Яшим атам җирендә.
Бу бәхет миңа бирелгән
Туган йорт бишегендә.
Тәүге кабат аяк басып,
Сукмактан киттем йөреп,
Әйттем анам теле белән:
– Мин җирдә кеше! – диеп.

Алып баручы. Шәйхи Маннурның әдәби мирасы зур һәм күпкырлы. Үзе исән чагында аның дүрт дистәгә якын китабы басылып чыкты. Язучының туган авылы Тулбайдагы музей-китапханәсе Дәүләт музееның филиалы статусын йөртә. Ел саен бер язучыга әдипнең васыяте буенча гамәлгә куелган Шәйхи Маннур исемендәге әдәби бүләк тапшырыла. Менә шулай халык күңелендә сүрелмичә, дәвер агымсуларында югалмыйча яши бирә Тулбай егете, олуг талант иясе Шәйхелислам ага – әдип Шәйхи Маннур һәм аның бай әдәби мирасы.

Агымсулар һаман агыла...
Агымсулар дулкынында гына
Кайтып киләм малай чагыма...
Агыла туар таңнар ягына...
Йөрәк җырым – гомер китабым
Тик шушында инде ябыла.

7. Чын дуслыкка ни җитә?

(Балалар язучысы Абдулла Алиш иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Рузия МӘҖИТОВА, Рая ХӘБИРОВА,
Арча районы Сикертән төп мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучылары (Залда музыка яңгырый.)

Алып баручы.

Рәхим итегез безнең бәйрәмгә,
Әйдәгез, дуслар, үтегез түргә!

Музыка астында балалар залга узалар, «Безнең җыр» (Л.Батыр-Болгари көе, Ә.Рәшитов сүзләре) башкарыла.

Безнең җыр

Кояшлы ил безнең ил – безнең ил,
Күге аның гел аяз.
Кыш китерсә, Кыш бабай,
Чәчәк алып килә яз.
Һавасы да, җиле дә,
Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да,
Безгә якын бары да.
Сандугачлы урманы,
Ашлык тулы кырлары,
Бөтен җиргә яңгырый
Безнең бәхет җырлары.
Бу ил безгә булсын дип
Кояш балкып торсын дип,
Бабайлар яулап алган,
Әтиләр саклап калган.

(Экранда Абдулла Алиш портреты чыга.)

2нче алып баручы. Хөрмәтле укучылар, укытучылар, кунакларыбыз! Без бүген бу залга яраткан язучыбыз Абдулла Алишны искә алырга җыелдык.

1нче укучы. Абдулла Алиш 1908 елның 15 сентябрендә Татарстанның Спас (элеккеге Куйбышев) районы Көек авылында туа. Әтисе Габделбари иген иккән, умарта караган. Әнисе, Газизә, укымышлы булган, әдәбиятны бик яраткан, шигырь һәм бәетләр чыгарган.

2нче укучы. Әгәр дә исән булса, әдипкә быел 109 яшь булыр иде. Мәктәптә укыган елларында ук ул кечкенә-кечкенә шигырьләр, бик матур әкиятләр яза.

3нче укучы. Абдулла абый зур үскәч тә, ул балалар өчен әкиятләр, хикәяләр язуыннан туктамый. Җырларны да бик яраткан ул. Ләкин барыннан да бигрәк балаларны яраткан. Балалар үзләре дә аны бик яраталар. Ул аларга үзенең мавыктыргыч әкиятләрен сөйләгән. Ә балалар аны тын да алмыйча тыңлаган. Алиш мәктәпкә килеп кергәч: «Әкиятче абый килде!» – диешеп, аны шундук сарып ала торган булалар.

4нче укучы. Ә фашистлар Германиясе сугыш башлагач, Абдулла Алиш сугышка китә. Анда да ул үзенең яраткан һөнәрен – язучылыкны ташламый. Балалар өчен яңадан-яңа әкиятләр, хикәяләр иҗат итә.

5нче укучы. Моабит төрмәсендә ул патриот-шагыйрь Муса Җәлил белән бергә була. Алар икесе дә фашист тоткынлыгында фашизмга каршы көрәшәләр. Ә туган илгә булган хисләре фронтта чакта язган шигырьләре һәм хатларында чагыла.

(Экранда Муса Җәлил портреты чыга.)

Алып баручы. Муса Җәлилнең якын дусты Абдулла Алишка багышлап язган шигыре дә бар.

(Бер укучы Муса Җәлилнең «Дуска» шигырен сөйли. «Салют сиңа, Муса Җәлил» җыры башкарыла.)

Салют сиңа, Муса Җәлил,
Салют иң яшь буыннан!
Рапорт тапшырырга сиңа
Бөтен отряд җыелган!
Пионер туганыбыз син
Муса агабыз,
Батырлыгыңа сокланып,
Җырларың белән рухланып,
Алга барабыз,
Үрләр алабыз!
Рәхмәт сиңа, Муса Җәлил,
Сынатмадың давылда.
Бүген дә син байракчыбыз,
Безнең сафлар алдында!
Маяк безгә, Муса Җәлил,
Синең янып яшәвең,
Көрәшләрдә илең өчен
Бәхет даулап яшнәвең.

6 нчы укучы. 1944 елның 25 августында Берлинда фашистлар җәлилчеләрне ерткычларча җәзалап үтерәләр. Гильотинада аларның башлары киселә.

7 нче укучы. Авыр газаплар кичерергә туры килсә дә, А.Алиш дошманга баш ими. Ул шигырьләрендә туган иле һәм дуслары белән горурлана!

1 нче укучы.

(Абдулла Алиш «Үзем турында җыр»)

Әйтсәләр дә: барып тор син дип
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел дип,
Кайтам мин дип туган илемә.
Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын дип,
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын дип.
Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.
Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын.
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

2 нче укучы. Абдулла Алишның иҗаты киң тармаклы. Әмма ул балалар язучы буларак танылган. Аның безнең

өчен язган әкиятләре татулыкка, дуслыкка, өлкәннәр сүзен тыңларга, тыйнаклыкка өйрәтә.

3 нче укучы. Без аның «Койрыклар», «Сертотмас үрдәк», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», «Куян кызы», «Чукмар белән Тукмар» һәм башка әкиятләрен бик яратып укыйбыз.

(Абдулла Алиш китаплары һәм әсәрләренә иллюстрацияләр күрсәтелә. «Чукмар белән Тукмар» әкияте сәхнәләштерелә.)

Автор.
Бер әбинең ике әтәче
Булган борын заманда.
Аларның кыланмышларын
Онытмыйм мин һаман да.
Әби.
Ике бик матур әтәчем
Бар бит минем, күрегез.
Берсе Тукмар булыр моның,
Берсен Чукмар, диярбез.
Тукмарым тукмый – тукмый
Күгәртеп лә бетерә.
Ә Чукмарым чукый – чукый
Манма тиргә төшерә.
Автор.
Әнә шулай берсе чукый,
Икенчесе тукмый, ди.
Әби җим биргән чагында
Тавыш тынып тормый, ди.
Чукмар.
Әби, кара, бу Тукмарың
Тукмый да һаман тукмый.
Чукып та карыйм ла үзен,
Ә ул миннән курыкмый.
Тукмар.
Ә Чукмарың чукый-чукый
Мине канга батырды.
Шулай һаман чукый-чукый
Тиште инде башымны-ы-ы. *(елый)*
Чукмар.
Сиңа әби күбрәк сипте,
Миңа ярма калмады.
Тукмар.
Ә сине соң әби һаман
Миннән күбрәк яклады.
Автор.
Менә шулай гел үзара
Талаш-ызгыш куптаргач,
Әби күршеләргә керткән
Тукмарны аптырагач.
Тукмар.
Аһ, ялгыштым, әби хәзер
Суйдыра бугай мине …
Борчымас идем әбине,
Башка сугышмас идем.
Автор.
Хәзер Чукмар берьялгызы
Бик күңелсез шул аңа.
Көннәре дә моңсу үтә,
Дусты булмагач янда.
Әби.
Менә, Чукмар, хәзер инде
Ялгызың яшәп кара.
«Миңа әз!» – дип, сөйлисең юк,
Үзеңә бөтен ярма.
Чукмар.
(бик күңелсез)
И-и, белмәдем ялгызлыкның
Болай читен икәнен.
Әби, тизрәк Тукмар кайтсын,
Берүзем мин нишләрмен?!
Автор.
Кет-кет көлә әби шунда
Әтәчкәен яратып.
Әби.
Моннан соң сугышмассызмы,
Маңгаегыз канатып?
Чукмар.
Юк, юк, әби, ялгыз булгач,
Бик күңелсез, мин – моңсу.
Бергә чакта гына рәхәт,
Аерылгач, ямансу.
И,Әбекәй, без беркайчан
Башка борчымас идек.
Тату гына яшәр идек,
Тәртипсез булмас идек.
Әби.
Ярар, алайса, Тукмарны
Алып кайтам хәзер үк.
Сүзегездә сез торыгыз,
Тик сугышмагыз берүк.
Автор.
Әбинең шулай әйтүе
Бәйрәм булды Чукмарга.
Үз-үзенә сүз бирде ул,
Кагылмаска Тукмарга.
Әби. *(Тукмарны алып кайта.)*
Бергә һаман дус булыгыз,
Ялгыз булсаң, уйлата.
Дустың булгач, кәеф тә шәп,
Дуслык күңел юата.
Чукмар.
Тукмар кайтты! Нинди шатлык!
Әйдә, бергә уйныйбыз!
Тукмар.
Әй, Чукмар, мин дә сагындым,
Бер дә дошман булмыйбыз!
(Кочаклашалар, сөенешәләр.)
Икесе бергә.
Менә, дуслар, без аңладык,
Дуслык зур нәрсә икән.
Шат күңелле булу өчен
Дуслар бик кирәк икән!

Алып баручы. Әле без карап үткән әкият безне дуслык кадерен белергә өйрәтә. Дуслык сүзе – бик мәгънәле сүз ул. Дусны таба белергә, тапкач, югалтмаска өйрәнергә кирәк.

4 нче укучы. Яныңда дусларың булса гына, бик күңелле була.

Алып баручы. Әйдәгез, дуслык турында белгән мәкальләребезне искә төшерик.

(Экранда дуслык турында мәкальләр чыга.)

Йөз сум акчаң булганчы, бер йөз дустың булсачы.

Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың.

Юлдашың үзеңнән яхшы булсын.

Дуслык сүздә түгел, эштә сынала.

Кош – канаты белән, кеше – дус-иш белән көчле.

5 нче укучы. Бер-беребезне, Туган илебезне, әти-әниләрне яратырга, тату, дус яшәргә кирәк! Тату булып яшәгәндә генә әйбәт укып, эшләп була.

6 нчы укучы. ***(****Рөстәм Мингалимов «Дусларың гына булсын»).*

Егылсаң, торып була,
Торсаң, йөгереп була,
Йөгерсәң, җитеп була –
Дусларың гына булсын!
Сөйләшеп, уйнап була,
Күп нәрсә белеп була,
Шаярып, көлеп була –
Дусларың гына булсын!
Күңелле яшәп була,
Үсеп һәм ныгып була,
Дошманны егып була –
Дусларың гына булсын!

(Кичә «Дуслык турында җыр» (М. Т. Миңһаҗев көе. Р.Корбанов сүзләре) белән тәмамлана).